ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN
№10 (393)
ОКТЯБРЬ 2024
1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

БРИКС: АЛГА – АКБҮЗ АТТА!

СМУ-88
БӨЕК ЕЛГА ЯРЫНДАГЫ
ЗАТЛЫЛЫК ҺӘМ ЗИННӘТЛЕЛЕК
smu88.group сайтында фатир сайлагыз
Реклама

ЯНАЛИФ
Идел ярындагы торак комплекс
КАЗАНЫШ
архитектура-төзелеш форумы
2022, 2023
PROESTATE & TOBY AWARDS 2023
ПОБЕДИТЕЛЬ
ПОБЕДИТЕЛЬ
U
2023
GOOD
INNOVATIONS
2023
РЕКЛАМА: ООО «ПРОДВИЖЕНИЕ». ИНН: 1655495557. Представленная информация носит исключительно ознакомительный характер, ни при каких обстоятельствах не является публичной офертой, определяемой положениями статьи 437 ГК РФ. Построенные объекты могут отличаться от представленных 3D-визуализаций, изображений. Все представленные материалы, изображения являются ориентировочными, в них могут быть внесены любые изменения и дополнения. Застройщик: ООО СЗ «ПСК СМУ88». Срок завершения строительства 1 этапа: 4 кв. 2025 г., 2 этапа: 4 кв. 2026 г. Проектная декларация на сайте наш.дом.рф

№10 (393)
ОКТЯБРЬ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Әдәби мөхәррир: Луиза Шарова
Авторлар: Олеся Бондаревская, Венера Вольская,
Әхмәт Шакиров
Фотограф: Александр Ефремов, Ната Смирнова,
Анастасия Вәлиева
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Ләйлә Сафина. Анастасия Алашеева фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-2215
Басарга кул куелды: 18.10.2024
Чыгу көне: 24.10.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

БРИКС: ДӨНЬЯНЫ ЯХШЫГА ҮЗГӘРТҮ ЮНӘЛЕШЕНДӘ...

Казан дөньякүләм масштабтагы вакыйгаларга инде ияләште кебек, алай гына да түгел, гадәттә ул үзе – аларның үзәге.

Универсиада – 2013,
футбол буенча 2018 елгы дөнья чемпионаты,
ел саен уздырыла торган Ислам форумы,
Киләчәк Уеннары...

2024 елның октябрендә Казанда «БРИКС рухы» хөкем сөрә. БРИКС дәүләтләренең чит илләр эшләре министрлары сүзенә караганда, әлеге рух нигезендә түбәндәгеләр ята: «үзара хөрмәт, һәр илнең мәнфәгатен һәм омтылышларын аңлау, суверен тигезлек, теләктәшлек, ачыклык, интеграция, хезмәттәшлекне ныгыту һәм консенсус».

Саммитның югары дәрәҗәдәге затларының максаты бер – «дөньяны яхшыга үзгәртү». Саммитны кабул итүчеләр без: 2024 елның 1 гыйнварыннан БРИКСта Россия Федерациясе рәислек итә. Безнең рәислектәге ел «гадел глобаль үсеш һәм куркынычсызлык хакына күпкырлылыкны ныгыту» девизы астында үтә. Без бүгенге күпполярлы дөнья шартларында БРИКС илләренең эшчәнлеге «дөньяны яхшыга үзгәртү»дә нигез һәм таяныч була ала, дип ышанабыз.

Кунаклар инде – бусагада. БРИКС, Казанга рәхим ит!

Сезнең кунакчыл редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп бирешле,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп бирешле,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» 103 ЯШЬ
ЖУРНАЛЫНА

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА

САБЫННАН САРАЙЛАР КАЛЫККАНДА...

1909 елдагы Халыкара күргәзмәгә керү капкасы.

Җир йөзендә төсле сабыннан төзелгән бердәнбер «сарай»
көннәрдән бер көнне Казанда пәйда була. Бу архитектура
могҗизасы белән шәһәрлеләр йөз унбиш ел элек «Рус Швей-
цариясе»ндә хозурлана. Халыкара сәнәгать күргәзмәсе ачыл-
ган чак була ул. Әлеге җәүһәр һәм, беррәттән, даһи реклама
ысулы белән барысын да шаккатыручы кем, дисезме? «Исхак
Арсланов исемендәге Сабын ясау һәм глицерин җитештерү
заводы»! Үз кулы белән ясаган «төзелеш материалы»ннан
алар күргәзмә павильоны торгызып куя. 63 корылма арасын-
да кабатланмаслары җитәрлек була. Мәсәлән, Петцольд сыра
ясау заводы павильоны 17 метрлы бик зур шешә рәвешендә
эшләнә. Ә төп керү капкасы күп ярусль агач манараны хә-
терләтә.
Казанда 1909 елда узган күргәзмәдә 2 316 катнашучы үз про-
дукциясен тәкъдим итә. Алар Россиянең 30 губернасыннан
җыела, болардан тыш, 40 чит ил фирмасы да кушыла. Сәйран
кылып йөрүче халык өчен кафешантан эшләп тора, күз йом-
ганчы төшереп алып фотография ясала, бильярд, кегельбан,
цирк һәм кинематограф – җаның ни тели, барысы да була.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

8. Тигезләр галәме
Дөнья эчке тулай продуктында БРИКС илләренең өлеше нинди

10. БРИКСның көче нәрсәдә
Оешма чит ил эшләре министрлары күзлегеннән караганда

16. Идеяләр үзәге һәм абсолют тигезлек
БРИКС+ илләре шәһәрләре ассоциациясе кая атлый

22. Кайдзен-фәлсәфә серләре
Сакчыл җитештерүдә камиллеккә кемнәр ирешә?

26. Эшлекле элемтәләр
Кытай партнёрлары белән ничек бизнес төзергә

34. Базар яссылыгында уңыш исәбе
Татарстан ашлыгын кайсы илләр ала

игелекле эшләр

48. Бөтен гомергә сузылган уку
Татарстанның төп мөгаллиме балалардан нәрсәгә өйрәнә

49. Белем көч бирә
«Инженерлар республикасы» ничек үсә

53. Акыллы булу шәп
Тормышта үзеңне ничек табарга

66. Дипломат? Мөгаллим? Менеджер?
Бүгенге көн мәктәп директоры кем ул?

67. Аңлашуга бер адым
Кытай теле ни өчен модада

71. Өлкәннәрнең актив тормышы
Сиксәндә ничек форманы сакларга

мәңгелек кыйммәтләр

76. Тарихи сәхифә
Мәгариф өлкәсенең реформаторы кем?

80. «Кара урман» ни турында шаулый
Радик Кудояров җәлилчеләрне һәм аларның катыйльләрен нинди күз белән күргән

86. Пилмәннең фәлсәфәсе бармы
Василий Демьянов Кытай кухнясын ничек үз иткән

92. Китап киштәсе
Әдәби маршрутлар кая сузыла

98. Авыллар тормышыннан
Дуслык һәм тигезлек кайда яши

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: history-kazan.ru

Акыллы гамәлләр



26.09

Владимир Путин, Россия Федерациясе Президенты, – Россия энергетика атнасындагы чыгышында:

– БРИКС илләре белән хезмәттәшлек кысаларында без үзебезнең түләү-исәп-хисап системасын булдыру юнәлешендә эшлибез. Бу бөтен тышкы сәүдәгә нәтиҗәле һәм бәйсез хезмәт күрсәтү шартларын тудырачак.

Игелекле эшләр

27.09

Максут Шадаев, РФ цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры, – Иннополиста, БРИКС илләре элемтә министрлары очрашуында:

– Безнең очрашу – цифрлы технологияләр өлкәсендә инновацияләрне бергәләп алга этәрү, үзара хезмәттәшлекне үстерү, глобаль цифрлы икътисад төзү максатында үзара тәҗрибә уртаклашу турында сөйләшү өчен бер дигән мөмкинлек. БРИКС оешмасының киңәя һәм үзгәрә баруын күрү бигрәк тә шатландыра.

Мәңгелек кыйммәтләр



27.09

Рөстәм Миңнеханов, ТР Рәисе, – Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында:

– Бүгенге дөнья өчен БРИКС саммитының әһәмияте бик зур. Чит илләрдәге партнёрлар Россия белән хезмәттәшлеккә әзер. Кытай белән бәйләнешләрне киңәйтү, ислам дөньясы илләре белән элемтәләрне ныгыту мөһим. Болар уртак проектларны тормышка ашырырга һәм яңа инвестицияләр җәлеп итәргә булышачак.

Фотолар: rais.tatarstan.ru, tatar-inform.ru, РФ Президентының рәсми сайтыннан

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

БРИКСның көче **нәрсәдә**

БРИКС+ илләре шәһәрләре ассоциациясе **кая** атлый

Татарстан ашлыгын **кайсы** илләр ала

Россия эшмәкәрләре **ни өчен** атлар ярата

Фото: kzn.ru

БРИКС САММИТЫ

Казан 22–24 октябрь 2024

22–24 октябрь көннәрендә Казанда әһәмиятле халыкара чара – дәүләт башлыклары Саммиты уза. Саммит – БРИКС буенча Россия рәислек иткән 2024 елның төп вакыйгасы. БРИКС «торган саен күбрәк илләрне – үз эшчәнлегенең нигезенә салынган төп принципларны уртаклашучы тарафдарларын һәм фикердәшләрен үзенә җәлеп итә. Бу – суверен тигезлек, үз үсеш юлыңны сайлауга хөрмәт, үзара мәнфәгатьләрне исәпкә алу, ачыклык, консенсус, глобаль финанс һәм сәүдә системасының гадел моделен һәм күпполярлы дөнья корылышын формалаштырырга омтылу, хәзерге заманның иң кискен проблемаларын бергәләп хәл итү юлларын эзләү», – дип билгеләп үтте Россия Президенты Владимир Путин,

БРИКС ҺӘМ G7 ИЛЛӘРЕНЕҢ



* *G7 һәм БРИКС илләренең сатып алу сәләте буенча дөнья эчке тулай продуктындагы өлеше.*
Чыганак: IMF World Economic Outlook

ДӨНЬЯ ЭТП* ӨЛЕШЕ

BRICS

- Бразилия
- Россия
- Һиндстан
- Кытай
- КАР

01.01.2024 елдан BRICSка кергән яңа илләр

- Берләшкән Гарәп Әмирлекләре
- Согыд Гарәбстаны
- Иран
- Мисыр
- Эфиопия

G7

- АКШ
- Канада
- Бөекбритания
- Германия
- Италия
- Франция
- Япония

БРИКС оешмасының көче нәрсәдә? Әлеге дәүләтләр берлегеннән илләр һәм халыклар нәрсә көтә? БРИКСның кайсы проектлары якын киләчәктә үк тормышка ашырылырга мөмкин? Ниһаять, Казандагы БРИКС саммитында нинди мәсьәләләр тикшереләчәк? Әлеге сорауларга БРИКС илләре һәм аның партнёр-илләре тышкы эшләр министрларыннан да яхшырак җавап бирүче булмастыр. Сүзне аларга бирик.

ТЫШКЫ ЭШЛӘР МИНИСТРЛАРЫ БРИКС ТУРЫНДА

Фото: photo.brics-russia2024.ru, mid.ru, fmprc.gov.cn, ru.wikipedia.org, International Maritime Organization, mfa.gov.by

Сергей Лавров,
Россия Федерациясе
тышкы эшләр министры:

«БРИКС чыннан да күпкырлы хезмәттәшлекнең тиңдәшсез механизмы ул. Төрле цивилизацияләр, диннәр һәм макротөбәкләрдән булган илләр аның кысаларында инде шактый еллар дәвамында үзара уңышлы хезмәттәшлек итә. Тигезлек, үзара хөрмәт принциплары һәм мәнфәгатьләр балансы тулы куәтендә саклана. Безнең бердәмлек күз алдыбызда формалашып яткан күпполярлы җиһанның төп терәкләреннән берсе булып тора.

Дөньядагы күпчелек илләрнең БРИКС белән кызыксынуы артуны канәгатьләнеп күзәтәбез. 2023 елның августында Йоханнесбургта үткән берләшү саммитында оешмага кергән илләр «бишлеге» лидерлары Мисыр, Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Согыд Гарәбстаны һәм Эфиопияне дә берләшмәгә чакырырга карар кылды. БРИКСка кушылуга кагылышлы тагын утызлап мөрәҗәгатьне бүген белгечләр өйрәнә, алар Казанда октябрьдә узачак саммитка бу турыда доклад әзерли.

2024 елның 1 гыйнварыннан БРИКС белән безнең илебез җитәкчелек итә. Россия рәислеге «Гадел глобаль үсеш һәм куркынычсызлык хакына күпкырлылыкны ныгыту» девизы астында бара».

Россия Федерациясе тышкы эшләр министры Сергей Лавровның БРИКС медиасаммитын ачу тантанасында катнашучыларга видеомөрәҗәгатеннән, Мәскәү, 2024 елның 14 сентябре.

Мауро Виейра,
Бразилия
тышкы эшләр министры:

«Бүген Берләшкән Милләтләр Оешмасы һәм башка халыкара структураларның мөмкинлекләре чикләнде яки тупикка килеп терәлде. Халыкара хокук нормалары, шул исәптән гуманизмның төп принциплары бозыла, моны без Газа секторы мисалында күрә алабыз. Бразилия һәр ил белән ике яклы мөнәсәбәтләрен ихтирам итә, халыкара оешмалар кысаларында, шулай ук G20 платформасында хезмәттәшлек яклы. Үз эшчәнлеге кысаларында глобаль Көньякның халыкара эшләргә йогынтысы көчәюен раслаган БРИКС оешмасы да чыгарылма түгел. География үзенчәлекләре, мәдәниятләр һәм сәясәтләр төрлелеге генә илләргә берләшү өчен киртә була алмый. Кыенлыкларга карамастан, безнең илләрнең инде байтак еллар дәвамында үзара якынаюы да моңа дәлил. Аерымлыкларыбыз булса да, без күп өлкәдә уртак тел таба һәм хезмәттәшлек урнаштыра алдык.

Бүген дөньяда тиз арада диалог урнаштыру таләп ителә. Күп илләрнең, бигрәк тә безгә кушылырга җыенучыларның, оешмабыз белән кызыксынуы моңа ачык мисал булып тора. Бу – БРИКСның уңышын күрсәтә торган чын дәлил. Һәм биредә бердәмлегебезне саклау бик мөһим. Нигезендә үзара хөрмәт, һәр илнең мәнфәгатен һәм омтылышларын аңлау, суверен тигезлек, теләктәшлек, ачыклык, интеграция, хезмәттәшлекне ныгыту һәм консенсус яткан «БРИКС рухын» саклау бигрәк тә зарур. БРИКСның Йоханнесбургта үткән саммиты йомгаклары буенча кабул ителгән БРИКС илләренең Икенче Йоханнесбург декларациясе үсеш өчен нык нигез булып тора. Минем иманым камил, Казандагы саммит та өч төп юнәлеш (иминлек сәясәте, финанс һәм икътисад өлкәләрендә хезмәттәшлек, мәдәни хезмәттәшлек һәм шәхесләрнең үзара аралашуы) кысаларында безнең уртак эшебез принципларын кабат раслаячак.

БРИКС гаиләсенә кушылырга теләүче яңа илләр дә аның рухын кабул итәргә әзер. Безнең гаиләбез ишәйде, һәм күп сорауларны хәл итүдә бар илләр дә тырышлыкларын берләштерергә тиеш. Ике мәсьәләне аерып күрсәтәсе килә. Беренчедән, безнең җитәкчеләр финанс министрларын һәм үзәк банк идарәчеләрен сәүдәдә җирле валюталардан файдалану, милли валюталар нигезендә түләү инструментларын һәм платформаларын эшләтеп җибәрү мәсьәләсен карарга өндәде. Исегезгә төшерәм, әлеге теманы президент Лула Йоханнесбургта күтәргән иде, һәм Бразилия, оешманың яңа әгъзалары аны гамәлгә ашыруга актив кушылыр, дип өметләнә. Икенчедән, без инде күп еллардан бирле халыкара институтлар дәрәҗәсендә күпьяклы мөнәсәбәтләрне камилләштерү зарурлыгы хакында бертавыштан белдерәбез. БМОны һәм аның Иминлек советын тамырдан реформалау мәсьәләсендәге уртак фикеребез, мәсәлән, Йоханнесбургтагы Икенче декларациядә тәфсилләп формалаштырылган иде. Бу – БРИКС илләренең төп таләбе. Без, әлеге теманы БМОда күтәрү өчен, хезмәттәшлек итү чараларын табарга тиеш.

Илләребез лидерлары безгә оешманың партнёр илләре өчен модель эшләүне йөкләде. Бу глобаль Көньякның күп илләре тарафыннан БРИКС белән кызыксынуның артуын ачык күрсәтә. Җитәкчелек принциплары, стандартлары, критерийлары, керү һәм катнашу процедуралары безнең илләр җитәкчелеге дәрәҗәсендә тикшерелә. Без Казандагы саммитта әлеге мәсьәләдә уртак фикергә ирешербез, дип саныйбыз».

БРИКС илләре тышкы эшләр министрлары очрашуының беренче сессиясендә ясаган чыгышыннан. Түбән Новгород, 2024 елның 10 июне.

Ван И, Кытай Халык Республикасы тышкы эшләр министры:

«Бүген дөнья үзендәге тәртипне, үсеш темпларын һәм балансларын, идарә фокусларын югалта. Глобаль Көньякның беренче фронты буларак, БРИКС илләре «дөньяны яхшы якка үзгәртергә һәм үзләре турында гына түгел, башкалар турында да кайгыртырга», җир йөзендә тигез хокукка нигезләнгән һәм тәртипкә салынган күппольярлылыкны һәм инклюзив икътисадый глобальләшүне алга этәрүгә үз өлешен кертергә тиеш.

Тулаем иминлеккә һәм ныклы тынычлыкка өндәү зарур. Кешелек – иминлекнең бүленмәс бергәлеге ул. Бер генә илнең дә куркынычсызлык өлкәсендә глобаль үзгәрешләр кертергә, бигрәк тә башкаларга зыян китерү хисабына үз иминлеген кайгыртырга хакы юк. Украинага килгәндә, сугыш кыры ил чиген үтеп чыкмаска, сугыш хәрәкәтләре кискенләшмәскә, кризис диалог һәм сөйләшүләр юлы белән хәл ителергә тиеш. Палестинага килгәндә, ничек булса да, мөмкин кадәр тиз арада Газа секторын утка тотуны бөтенләйгә туктату, «ике халык өчен ике дәүләт» планын гамәлгә ашыру һәм Якын Көнчыгышта тынычлык урнаштыру таләп ителә.

Үсешкә игътибарны арттыру, шул юнәлештәге проблемаларны хәл итү зарур. Үсеш, алгарыш – кешелекнең мәңгелек темасы. БРИКС, үз өстенлекләреннән тулысынча файдаланып, БМОны үсеш мәсьәләләрен үз эшенең үзәгенә куярга этәрергә, игътибар үсеп килүче илләрдәге кыенлыкларга юнәлтергә һәм алга киткән илләрне 2030 елга кадәр планлаштырылган тотрыклы үсеш бурычларын гадел үтәргә өндәргә тиеш. БРИКС оешмасына үсеп килүче илләрдәге хәерчелекне киметүне, үсешне финанслауны, энергетика һәм азык-төлек иминлеге мәсьәләләренә игътибарны арттыруны, фәнни-техник революция мөмкинлекләреннән һәм сәнагатьтәге үзгәртеп корулардан файдалануны, югары сыйфатлы үсешнең яңа драйверларын булдыруны кайгырту мөһим.

Күпкырлылыкны тормышка ашыру һәм глобаль идарәне камилләштерү таләп ителә. БМО химаясе астында халыкара системаны уяу саклауны, БМО Уставының максат һәм принциплары үтәлүен, һәр илгә бертигез мөнәсәбәт күрсәтүне тәэмин итү зарур. Саммит нәтиҗәләрен гамәлгә ашыру контекстында халыкара финанс архитектурасы реформасын үткәрүне дәгъвалау, Көньяк илләренең халыкара икътисадый карарлар кабул итүдә, идарәдә һәм законнар чыгаруда тулыканлы катнашуына ирешү, аларның тавышын һәм вәкиллеген арттыру мөһим. Безнең ил Ясалма интеллект мөмкинлекләрен ныгыту өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек турындагы БМО Генераль Ассамблеясенең Кытай резолюциясен тормышка ашыруда БРИКС илләренең катнашуын хуплый.

БРИКС тиздән киңәйгәннән соңгы беренче саммитын үткәрәчәк, бу бөтен дөньяның игътибарын җәлеп итә һәм гаять зур әһәмияткә ия. Намус һәм гаделлекне саклау, уртак үсешкә ярдәм итү турында көчле сигнал җибәрү, БРИКС белән хезмәттәшлеккә тагын да уңайрак шартлар тудыру өчен әлеге мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк».

БРИКС илләре тышкы эшләр министрларының Нью-Йоркта БМО штаб-квартирасында очрашуындагы чыгышыннан. 2024 елның 26 сентябре.

Субраманьям Джайшанкар, **Һиндстан** тышкы эшләр министры:

«Дөнья буйлап сәяхәт иткәндә, мин БРИКС оешмасы белән теге яки бу формада хезмәттәшлек итүгә кагылышлы энтузиазм, кызыксынуның артуын күрәм... Сүз дә юк, БРИКСның эволюциясе күз алдында, Яңа үсеш банкы булдырылды, хезмәттәшлекнең башка юнәлешләре дә үстерелә... Безнең уртак фикерләребез күп, әмма кайбер сорауларда аерма да бар. Мин шуны күздә тотам: Һиндстан һәм Россия, Кытай һәм Бразилия, Көньяк Африка Республикасы барлык мәсьәләләр буенча да тулысынча килешеп бетә алмый, кайбер очракларда безнең позицияләребезнең шактый төрле булуы да ихтимал».

Женева иминлек сәясәте үзәгендәге чыгышыннан, 2014 елның 12 сентябре.

Максим Рыженков,
Беларусь Республикасы
тышкы эшләр министры:

«БРИКС – глобаль күпчелекнең иң динамик үсештәге оешмаларыннан берсе ул. Беларусь үз гаризасын бирде, һәм без якын арада аның каралуын көтәбез. Бүген инде БРИКСның тулы хокуклы әгъзалары бар, ә киңәюнең киләсе дулкынында кайбер дәүләтләргә партнёр ил статусы биреләчәк. Бу әлеге илләрнең БРИКС идеяләренә никадәр тугры икәнен һәм аларның билгеле бер критерийларга тәңгәл килүкилмәвен тикшерү өчен эшләнә.

Нәкъ менә хәзер БРИКС кысаларында партнёр илләргә карата кулланылачак критерийлар эшләнә. Киңәюнең беренче дулкыны нәкъ менә Казандагы саммитта булачак. Бу арада Россия рәислеге киңәюнең беренче дулкынына керәчәк илләр исемлеген төзи. Инсайдер мәгълүматлары буенча, аларның саны бер дистә чамасы булыр, дип көтелә».

Нью-Йоркта БМО Генассамблеясе кысаларында «Новости» РМА журналистларына биргән интервьюдан, 2014 елның 28 сентябре.

Фото: kzn.ru

БРИКС+ ШӘҺӘРЛӘРЕ АССОЦИАЦИЯСЕ: ИДЕЯЛӘР ҮЗӘГЕ ҺӘМ АБСОЛЮТ ТИГЕЗЛЕК

Дмитрий Сивков

Июньдә Кытай, Һиндстан, Бразилия, Көньяк Африка Республикасы һәм Россиядәге 200дән артыграк мэр, муниципаль берәмлекләр вәкилләре Казанда БРИКС+ шәһәрләре ассоциациясен оештырды. Әлеге оешманың беренче адымнары хакында «Татарстан» журналына аның рәисе, Татарстан башкаласы мэры Илсур Рәис улы Метшин сөйләде.

– Илсур Рәисович, БРИКС+ шәһәрләре ассоциациясе оештырылуга әле ярты ел да юк. Нәрсәләр эшләргә өлгердегез? Әллә бу турыда сөйләргә иртәрәкме?

– Иртә түгел инде, без шактый актив эшли башладык һәм дүрт ай эчендә берничә кызыклы проектны гамәлгә ашыра алдык. Исегезгә төшерәм, июньдә БРИКС+ илләре шәһәрләренең халыкара форумына егерме илдән 200дән артыграк мэр, вице-мэр һәм җирле хакимиятләр ассоциацияләре җитәкчеләре килде. Ягъни ассоциация төзү идеясе шунда ук актив хупланды, һәм без гамәлгә кертә башлаган проектлар да тиз арада популярлык казанды.

Мәсәлән, ассоциация төзелүнең икенче көнендә үк без БРИКС китапханәсен туплауга керештек. Аны БРИКС+ илләренең формалаша башлаган инфраструктурасының бер өлеше, күпполярлы дөнья идеологиясе белән берләштерелгән дәүләтләрнең үзара хезмәттәшлеге һәм якынаюы урыны, мәдәниятләр алмашу үзәге булыр, дип ниятләдек. Шәһәр мэрлары үз халыкларының, илләренең иң яхшы китапларын алып килде һәм әлеге китапханәгә тапшырды.

Сентябрьдә әлеге традицияне БРИКСның Беренче әдәби форумына чакырылган авторлар дәвам итте. Анда 3 меңнән артыграк кеше килде. Бразилия, Кытай, Һиндстан, Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, шулай ук үзебезнең Россия һәм Татарстан язучылары һәм шагыйрьләре катнашты. Без түгәрәк өстәлләр, иҗади очрашулар, дискуссияләр үткәрдек, шулар вакытында катнашучыларда аралашуны инде яңа БРИКС+ илләре әдипләре ассоциациясе кысаларында дәвам итү идеясе туды. Ул язучылар арасында ныклы элемтәләр урнаштырырга мөмкинлек бирәчәк һәм һәр катнашучы илнең мәдәни

мирасын баетачак. Бу безнең талантларыбызны берләштерүдә мөһим адым булачак.

Җәй азагында Казан өч көнгә дөньякүләм джаз башкаласына әйләнде – шәһәребездә Халыкара «БРИКС илләре диксилендлары һәм этно-джаз ансамбльләре съезды» фестивале узды. Әлеге чарада Һиндстан, Эфиопия, Бразилия, Кытай, Иран, Куба һәм Төркиядән 22 коллектив катнашты. Музыкантлар безнең парк һәм скверларыбызда чыгыш ясады, ә бер концертта оркестрга берләшеп уйнады. Иманым камил, бу һәр башкаручы һәм тыңлаучы өчен бәһасез тәҗрибә булгандыр – бергәләп иҗат итү һәрвакытта да күңелне баета бит ул.

Былтыр Халыкара «Казаныш: тәңгәллек чагылышы» архитектура-төзелеш форумында, иң яхшы тәҗрибәләрне уртаклашу, алмашу өчен, БРИКС илләре архитекторлары ассоциациясен төзергә карар кылынган иде. Бу архитектура проектларының сәнгать һәм инженерлык-техник сыйфатларын яхшырту өчен кирәк. Планда студентлар белән алмашу, укучылар һәм яшь архитекторлар өчен стажировкалар оештыру каралган. Декабрьдә архитекторлар, иң яхшы проектлары белән уртаклашу һәм яңа проектларын тәкъдим итү өчен, кабат форумда очрашачак. Инде килергә теләүчеләр исемлегеннән генә дә «Казаныш»ның илебездә иң абруйлы һөнәри мәйданчыкларның берсенә әйләнә баруын күрергә мөмкин.

Сентябрьдә узган Kazan Digital Week халыкара форумында Мәскәү вәкилләре Smart City БРИКС төркемен төзергә тәкъдим итте. Бразилиядән килгән коллегаларыбыз «БРИКС илләре шәһәрләре хатын-кызлары» трегы кирәклеген белдерде. Бу идеяләрне без башка шәһәрләрдән килгән коллегаларыбыз белән киләсе очрашуыбызда тикшерәчәкбез.

Шуңа күрә ассоциация төрле юнәлешләр буенча шактый актив эш башлады, дияргә була. Төрле илләрдәге шәһәрләрнең бер-берсенә таба ясаган адымы безнең үзара кызыклы булуыбызны күрсәтә. Безнең өйрәнәсе нәрсәләр дә, өйрәтәсе нәрсәләребез дә бар. Һәм тагын.

Ассоциация дустанә ил шәһәрләренең халыкара аренада үз тавышын булдыру максатында да төзелгән иде. Үз шәһәреңнең вәкиле булу һәм аның исеменнән сөйләү – ассоциация каршында мондый бурыч та тора.

– Сез мэрларның бурычларын яхшы хуҗабикәнең рецептлары белән чагыштырган идегез – кирәкле микъдарларны санауга продуктлар һәм вакыт әрәм иткәнче, инде әзерне алу яхшырак бит. Ә менә үзегезнең нинди «рецептларыгызны» коллегаларыгызга тәкъдим итәр, кемнәрнекен үзегез файдаланыр идегез?

– Алар күп, проектлар төрле өлкәләргә карый. Мәктәптә туклануны оештыру, уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру, җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү һәм башка проектларыбызны коллегаларыбыз өйрәнә, ә без алардан өйрәнәбез.

Без шундый заманда яшибез ки, изоляциядә килеш берничек тә уңышка ирешә алмаячакбыз. Башкалар өчен ачык булып һәм иң яхшы эшләребез белән уртаклашып кына, үсә һәм шәһәр халкы өчен дә, кунаклар өчен дә көндәшлеккә сәләтле була алабыз. Бүген халык тормышын тагын да уңайландыру өчен иң яхшы идеяләрдән файдалана белү бик мөһим. Шунлыктан без Казанда sharedcity.org. сайтын булдырдык, анда бөтен дөнья шәһәрләрендәге иң яхшы тәҗрибәләр тупланган. Хәзер сайттагы мәгълүмат базасында 600дән артыграк мисал бар, иң популярлары – экология, шәһәр мохите, җәмәгать киңлекләре, шәһәр идарәсен цифрлаштыру. Әлеге мәгълүматлар күп муниципалитетларга файда китерәчәк, база даими тулыландырылачак.

– Ассоциациянең муниципаль хакимиятләре планетадагы 2,6 миллиард кешенең мәнфәгатен кайгырта булып чыга. ТР башкаласы һәм аның башлыгы яңа орбитада үзен уңайлы хис итәме?

– Бик уңайлы хис итәбез, чөнки без, форумда катнашучылар һәм ассоциацияне оештыручылар, иң баштан ук шулай хәл иттек: эшчәнлегебез барлык шәһәрләрнең тигезлеге принцибында барачак. Барлык тавышлар да бердәй мөһим. Һәркемнең үзен ишеттерү, үз кыйммәтләрен саклап калу, үз тиңдәшсезлеген, мәдәни үзенчәлеген яклау хокукы бар. Без барыбыз да бертигез, һәм бу безнең барыбызга да уңайлы шартларда эшләү мөмкинлеген бирә.

– Сезнеңчә, идарә дилбегәсен үзегезнең варисыгызга кайчан тапшыра алырсыз икән?

– Оешма белән җитәкчелек итүнең менә хәзерге БРИКС саммитындагы сыман бер катнашучыдан икенчесенә тапшырылуы миңа ошый. Әлбәттә, катнашучылар күп булганда, бу модельне шул килеш кулланып булмый, әмма без адекват карар кабул итәргә тырышачакбыз. Без бу теманы БРИКС дәүләтләре башлыклары саммитыннан соң ук, 31 октябрьдә узачак директорлар советында тикшерәчәкбез. Анда ассоциациянең эш планын расларга, эшкә кагылышлы төрле мәсьәләләрне хәл итәргә җыенабыз. БРИКС илләре шәһәрләренең барысына да кирәкле проектларның кайсыларын якын киләчәктә гамәлгә ашырырга тиешлегебезне дә шунда билгеләячәкбез.

- **Компания 1С** – идарә итүне автоматлаштыру буенча Россия базары лидеры
- **«Алкоторг» ҖЧҖ** – «Татспиртпром» АҖ продукциясенең эксклюзив дистрибьюторы
- **«ИБР» ҖЧҖ** – 1С франчайзи-партнёры, 1С-Идел буе ИТ-базары лидерларының берсе, «1С: Ел проекты» федераль бәйгесенең берничә мәртәбә җиңүчесе

BRICS FUTURE SKILLS & TECH CHALLENGE 2024*

ИҢ ШӘП ТӘҖРИБӘ ҮРНӘГЕ БУЛАРАК, ХАЛЫКАРА ЧЕМПИОНАТ ҺӘМ 1С:ERP ТУРЫНДА

Сентябрь аенда Казанда BRICS Future Skills & Tech Challenge 2024 Перспективалы технологияләр һәм күнекмәләр буенча халыкара чемпионат узды. Аның бер чарасы турында «Мәгълүмати бизнес-карарлар» ҖЧҖнең оешманы үстерү буенча директоры Юлия Лунина сөйли.

– Татарстан башкаласы үзендә BRICS Future Skills & Tech Challenge 2024 чемпионатының финалын кабул итте. Аның төрле этаплары, халыкара сессияләре, белем бирү интенсивлары, турыдантуры ярышлары ел дәвамында уздырылды. Казанда суперкубокны кемнең алачагы хәл ителде. 13 илдән 500 вәкил һәм 1000 катнашучы җыелган иде.

Финалдагы ярышлар 12 компетенция буенча узды, шулар арасында иң мәртәбәлесе «Бизнес-процессларны автоматлаштыру» булды. Монда Россия, Беларусь, Колумбия, Вьетнам, Филиппин, Сальвадор, Кытай һәм Марокко командалары көч сынашты. Катнашучылар «1С: Предприятие» платформасы нигезендә бизнес-процессларны автоматлаштыру өчен программа продуктлары җитештерде.

Бурычларның катлаулы булуына карамастан, барлык катнашучылар да (финалистлар гына түгел) компетенцияләр ягыннан гаять югары дәрәҗә күрсәтте, 1С программа продуктлары белән яхшы идарә итүләрен раслады. Бу очраклылык була алмый, командаларны әзерләү нәкъ менә 1С компаниясе җитәкчелегендә алып барылды. Бер ел дәвамында катнашучылар «1С: Предприятие» платформасын өйрәнде, 1С мобиль платформасын һәм 1С: Company Management типлаштырылган чишелешне үзләштерде. Шулай ук беркетелгән программалаштыру телен, төп объектларны да, моннан тыш, программа кушымталарын да эшләделәр.

Чемпионатның финалында катнашучылар предприятие ресурслары белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасын кертүнең гамәлдәге проекты белән танышу мөмкинлегенә ия булды. Мисал рәвешендә безнең «Алкоторг» ҖЧҖнә 1С: ERP системасын кертү проектын сайлап алдылар.

* «Киләчәк технологияләре һәм күнекмәләре буенча чемпионат» (инглиз теленнән тәрҗемә)

Фото: «Мәгълүмати бизнес-карарлар» ҖЧҖ нән алынды, Илья Воронцов. РЕКЛАМА

НИГӘ АЛКОТОРГ?

«Алкоторг» компаниясе «Татспиртпром» компанияләре төркеменә карый. Ул – Россия Федерациясендәге иң зур хәмер җитештерү компанияләренең берсе, күпсанлы вәкиллекләре булган, куәтле логистика комплексларына ия, Россия базарында алдынгылыкны тотып торган лидер. Предприятиенең мәгълүмат системасы белән танышу – әле эшен башлап кына җибәргән белгечләр өчен дә, профессионаллар өчен дә зур табыш. Оешмада яңартылган автоматлаштыру системасы эшли, әлеге проектны кертеп җибәрү 2023 елда «Россия Федерациясенең Идел буе федераль округындагы иң яхшы проект» номинациясенә ия булган.

Очрашу кысаларында чемпионатта катнашучыларга предприятие, ул кулланган мәгълүмат системалары турында да, ИТ-өлкәдәге оештыру һәм идарә итү процесслары хакында да сөйләделәр. 1С: ERP системасы ярдәмендә автоматлаштырылган логистика процесслары белән таныштырдылар: «маршрутны билгеләү һәм клиент заказын сайлаудан алып, махсус геосервис ярдәмендә маршрутны чыгымын киметерлек итеп үзгәртүгә кадәр» бар монда, складтагы операторның эшчәнлегенә килсәк, «складта клиентлардан алынган заказларны эшкәртүдән алып машина йөртүчегә документлар комплектын әзерләүгә кадәр» җайлаштыру да.

Очрашу түгәрәк өстәл форматында узды, берьюлы инглиз һәм кытай телләренә тәрҗемә ителеп барды. Фикер алышу бик актив булды.

НИ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНДЫЛАР?

Кунаклар ИТ-чишелешләрнең техник ягын да белеште, оештыру-идарә итү якларын да. Яңа мәгълүмат системасын кертүнең төп сәбәбен ИТ-система принциплары – үтә күренмәлелек, масштаблаштыру, сыгылмалылыкның эшләмәве белән аңлаттылар. 2022 елда «Алкоторг» компаниясе үз мәгълүмат системасының корбанына әверелә язган: бер-берсенең ничек эшләгәнен күрми башлаганнар, предприятиедәге теләсә нинди кечкенә генә үзгәреш тә колач җитмәслек яңа эш күләменә әверелгән, ИТ-хезмәт инде боларны күтәрә алмас хәлгә җиткән. Ахыр чиктә, ИТ-система компаниянең эшчәнлеген тоткарлый башлаган.

Кунаклар уйланылып кертелгән әлеге яңа системаның нәтиҗәләрен аермачык күрәләр. 80 проценттан артык процессны 1С: ERP ның стандарт-типлаштырылган чаралары ярдәмендә уңайлы итеп автоматлаштыра алганнар, бу, үз чиратында, югары технологик куәткә, озатып йөртүнең арзанаюына һәм системаның киңәюенә дә китергән. Бүген, бер ел узгач, «Алкоторг» компаниясе яңа система белән тыныч яши: эшчәнлеген дә алып бара, бизнесны да киңәйтә һәм үстерә, куәтләрен дә арттыра. Профессионалларның кечкенә генә төркеме ярдәмендә дә шундый зур холдингның ИТ-системасын яхшыртырга, үстерергә була икән.

«Алкоторг» вәкилләре подрядчыны ничек сайлаулары турында сөйләде, аңа нинди таләпләр куелганын аңлатты. Ә без, «ИБР» компаниясе, заказчы белән сыйфатлы хезмәттәшлек коруның ни дәрәҗәдә кыйммәтле икәнлегенә басым ясадык. Безнең берләшкән проект командасының яңа ИТ-системаны ничек эшләтеп җибәрү тәҗрибәсе белән уртаклаштык: 30 декабрьдән 5 гыйнварга кадәр, тәүлек буе йокламый, һәр эшне контрольдә тотып, складларның эш куәтен, продукцияне кабул итү һәм төяп җибәрү процессын туктатмыйча.

Хуҗалар белән кунаклар проектны үстерүнең перспективалары турында фикер алышты, 1С инновацияле программа продуктларын кертеп җибәрү юлларын уйлашты – сүз ясалма интеллект, программа роботлары, чат-ботлар турында барды. 1С ның халыкара базарлардагы перспективалары турында да сөйләшенде.

НӘТИҖӘЛӘР НИНДИ?

Фикер алышулар һәм нәтиҗәләр нигезендә катнашучылар бер карарга килде: 1С системалары кечкенә предприятиеләрдә кулланыр өчен дә, эре бизнеста да яраклы һәм кулай. Чемпионатның халыкара масштабын исәптә тотып, 1С системаларының үсеше дөнья базарында тизләтелгән темплар алыр, дип фаразларга мөмкинлек бар.



Мозес Малулеке, КАР командасы, инженер-программалаштыручы, Йоханнесбург университеты:

– «Татспиртпром» предприятиесенә экскурсия «1С: Предприятие» ярдәмендә бизнес-процесслар белән ничек автоматлаштырып идарә итеп булуын ачык күрсәтте. Бу системаны кулланып корылган эш рәвеше гаҗәеп нәтиҗәле. Без гамәлдә платформаның ничек эшләгәнен күрә алдык, аның ышанычлы икәнлегенә инандык. Ул сыгылмалы, масштаблаштырыла торган. Уртача куәте булган оешмалар да, эре компанияләр дә «1С: Предприятие» базасында булдырылган мәгълүмат системасыннан бик яхшы файдалана алачак, дип уйлыйм.

УҢЫШНЫҢ КӨМЕШ АЧКЫЧЫ

Тойота T-TPS Гомуми җитештерү системасы критерийлары буенча сакчыл җитештерү тармагында һәм предприятие белән халыкара TMS стандартлары буенча идарә итү системасында «Челтәр компаниясе» Россиядә беренче булып көмеш дәрәҗәгә ирешкән. Моны Toyota Engineering Corporation президенты һәм хезмәтне дөрес оештыру фәлсәфәсенә нигез салучы Тосио Хорикири әфәнде белән «Кайдзэн» Үзәге» коммерциячел булмаган автономияле оешма белгечләре Татарстан Республикасында үткәргән аудит күрсәткән.

– Халыкара TMS стандартлары буенча идарә итү системасы дөньяда нәтиҗәле менеджмент эталоны булып тора, – дип сөйли «Челтәр компаниясе»-нең сакчыл җитештерүне оештыру һәм үстерү бүлеге җитәкчесе Гөлүсә Борһанова. – «Кайдзэн» Үзәге аудиторларыннан әлеге системаны безнең компаниядә диагностикалау һәм үзләренең карарын чыгару таләп ителде.

МАКСАТ – БЕРТУКТАУСЫЗ КАМИЛЛӘШҮ

Сакчыл җитештерү принципларын урнаштырганда, әлеге процесска җәлеп ителгән персоналның мөмкин кадәр күбрәк булуы хуплана: һәр хезмәткәргә үзенең мөһимлеген тоярга биргән саен, компания күрсәткечләре дә яхшыра бара. Toyota компаниясенең иң мөһим кагыйдәсе мондый: «Уңыш ачкычы – бертуктаусыз камилләшүдә».

Toyota Engineering Corporation президенты Тосио Хорикири белән «Кайдзэн» Үзәге» коммерциячел булмаган автономияле оешма белгечләре әлеге кагыйдәнең ничек гамәлгә ашырылуын иң әүвәл компаниянең Чистайдагы филиалында тикшерергә була. Эш шунда ки, чөнки нәкъ менә биредә, Чистай электр челтәрләрендә, 2018 елда беренче аудит үткәрелә, һәм ул чакта компания бронза дәрәҗәгә әле ирешмәгән, дип табыла. Ә менә өч елдан соң инде бронза дәрәҗәне алалар.

Ә хәзер хәлләр ничегрәк икән? Аксубай район электр челтәрләрендә һәм Чистай электр челтәрләренең җитештерү базасында аудиторлар үз күзләре белән менә нәрсәгә инана: сакчыл җитештерү чаралары электр белән тәэмин итүдәге өзеклекләрне киметүдә чыннан да булыша, электр энергиясенең бушка сарыф ителүен һәм персонал өчен хәвефләрне киметә, шулай ук электр энергетикасындагы башка мөһим бурычларны

Фото: «Челтәр компаниясе» АҖ, tatar-inform.ru. РЕКЛАМА

САКЧЫЛ ҖИТЕШТЕРҮ – япон автоконцернындагы идарә итү принциплары системасы, ул барлык артык һәм файдасыз нәрсәдән котылырга булыша. Инновацияле фәлсәфә чыгымнарны киметүгә һәм шул ук вакытта продукциянең сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән. Бөтен дөньядагы сакчыл җитештерү чараларын үзләштергән компанияләр аудит нәтиҗәләре буенча бронза, көмеш, алтын дәрәҗәгә ирешә ала. «Челтәр компаниясе»ндә система (Татарстан электр энергетикасында ул «Энергия» җитештерү системасы дип йөртелә) 2014 елдан бирле файдаланыла. Аны көйләүдә Toyota Engineering Corporation президенты Тосио Хорикири булыша. 2021 елда «Челтәр компаниясе» Россиядә беренче (һәм бердәнбер!) булып бронза дәрәҗәгә ирешә. Көмеш дәрәҗәгә татарстанлылар өч елдан соң ия була.

хәл итә... Сүз уңаеннан, аудит үзе дә бу очракта профессионаллар диалогын хәтерләтә. Хезмәтне дөрес оештыру өлкәсендә бәһасез тәҗрибәгә ия Тосио Хорикири әфәнде структура бүлекчәләре вәкилләренә үз сорауларын биреп кенә калмыйча, аларга киләчәктә кирәге чыгачак конкрет киңәшләрен дә бирә. Киңәшләрне бик игътибар белән тыңлыйлар: компаниянең эшләре уңышлы икән, димәк, киләчәктә тагын да югарырак үрләргә омтылырга кирәк.

КАЙДЗЕН-ФӘЛСӘФӘНЕҢ БЕР ӨЛЕШЕ БУЛАРАК ҖИМЕШ БАКЧАСЫ

«Камиллеккә чикләр юк...», – дип төгәлләде үзләренең һәр чыгышын Идел буе электр челтәрләре филиалы хезмәткәрләре дә, чөнки аудиторлар «Энергия» җитештерү системасының Тойотаның T-TPS гомуми җитештерү системасы критерийларына никадәр тәңгәл килүен бәяләүне нәкъ шунда дәвам итте. Биредә Тосио Хорикири әфәндегә һәм экспертларга адреслы саклауның ничек башкарылуын, үзәк складта товарматди кыйммәтләрнең ничек кабул ителүен һәм җибәрелүен аңлаттылар. Стрим-трансляция исә җибәрелгән һәм илтеп җиткерелгән йөкнең район электр челтәрләренең берсендәге складта ничек кабул ителүен ачык күрсәтте. Лабораторияне һәм СИиЗП җиһазларын кабул иткәндәге функция һәм процессларны күрсәтү исә экспертларда бигрәк тә зур кызыксыну уятты.

Аудиторларны җимеш бакчасына да чакырдылар, чөнки ул да кайдзенның, ягъни эш процессларын һәм практиканы бертуктаусыз яхшырту буенча биредә гамәлгә ашырыла торган концепциянең бер өлеше һәм компания алып барган корпоратив сәясәтнең чагылышы бит. Аудиторлар килеп киткәннән соң бакчада тагын бер куак артты. Аны утырткан Тосио Хорикири үз куагының ничек үсүен бераз вакыттан соң килеп күрергә вәгъдә бирде.

ЦИФРЛЫ ТРАНСФОРМАЦИЯ ҺӘМ «ҖЫЛЫЛЫК КАРТАСЫ» ТУРЫНДА

«Челтәр компаниясе»нең инновацияләр эшчәнлегендәге казанышлары белән яңа техника һәм технологияләр бүлеге лабораториясендә танышырга мөмкин иде. Аудиторга интеллектуаль исәп өлкәсендәге, цифрлы подстанцияләр һәм коммутацион җиһазларга кагылышлы инновацион проектлар турында сөйләделәр, алар хезмәткәрләр эшенең нәтиҗәлелеген дә арттыра, объектлар төзегәндә капиталь чыгымнарны да киметергә мөмкинлек бирә.

Лаборатория кысаларында төрле техник мәсьәләләр тикшерелә, алар компаниянең барлык филиалларында куллану өчен уртак. Җиһазларны уйлап табу, проектлау һәм әзерләү процесслары белән үзе шөгыльләнгән идарәче Тосио Хорикирига иң гади функциональны күрсәтү бик ошады, ә цифрлы трансформация тармагындагы күрсәткечләр аны таң калдырды. Аны тагын компаниянең электр кору станцияләрен төзү программасында актив катнашуы да бик тәэсирләндерде.

Компаниянең дөньядагы иң яңа трендлардан хәбәрдар булуында да япон аудиторы Казан электр челтәрләрендә дә инанды. Биредә хезмәткәрләрнең җитештерү эшчәнлегендәге күрсәткечләрен «җылылык картасы» ярдәмендә билгелиләр. Гадәттә фонд базарларында файдаланыла торган әлеге чара зур күләмле эшләрне җайлырак һәм нәтиҗәлерәк итәргә мөмкинлек бирә. Яшел шакмаклар планны арттырып үтәүне күрсәтә, кызыллары артта калуны аңлата, сарылары күрсәткечләрнең нормага туры килүен белдерә.

Бүлекчәләр эше сыйфатын Казандагы кебек күрсәтү форматы Тосио Хорикирига ошады. Докладчыны мактап, ул үз киңәшен дә бирде: проблемалы бурычларны хәл итү буенча биремнәрнең үтәлешен дә шундый таблица ярдәмендә күрсәтергә кирәк. Компаниянең идарәне визуальләштерү өлкәсендәге алгарышы җитештерү эшчәнлеген камилләштерү өчен бик мөһим бит, «Тойота» моңа һәрвакыт бик игътибарлы. Һәм иң мөһиме, бу компаниянең һәр филиалында һәм бүлекчәсендә һәм барлык хезмәткәрләр тарафыннан башкарыла.

БҮГЕНГЕДӘН КИЛӘЧӘККӘ

Аудиторлар өч көн эчендә «Челтәр компаниясе» эшчәнлегенең бөтен юнәлешләре белән танышып өлгерергә тиеш иде. Башкаладагы филиалда бигрәк тә «бүгенге киләчәккә» – республикада актив кертелә торган цифрлы технологияләргә басым ясалды. Филиал җитәкчеләре тарату челтәрләрен автоматлаштыру өлкәсендәге уңышлары, җиһазларны цифрлаштыру хакында сөйләде. Хөрмәтле остазлары Тосио Хорикири бар нәрсәнең асылына төшенә алсын өчен, презентацияләрдә файдаланыла торган специфик терминнарны бергә япон теленә махсус тәрҗемә иткәннәр.

Бүген инде ачык күренә: сакчыл җитештерү принципларын 10 ел буена өйрәнү һәм кертүнең нәтиҗәләре бик яхшы. Хәзер алар җитештерү процессында уңышлы файдаланыла, һәр хезмәткәр өчен диярлек нормага әйләнгән. Нәкъ менә һәрберсенә, чөнки сакчыл җитештерүдә даими камилләшү процессына бөтен персоналны җәлеп итү иң мөһим юнәлеш бит. Белгечләр телендә бу «кайдзен» дип атала.

«Челтәр компаниясе» хезмәткәрләренең һәркайсы «кайдзен» төшенчәсен бик яхшы аңлый, кайдзен-тәкъдимнәрнең күплеге моңа дәлил булып тора. Мәсәлән, тарату челтәрләренә хезмәт күрсәтә торган бригада автомобильләрен караганда япон аудиторы моны үз күзе белән күргән. Чистай электр челтәрләрендә Газель 21057 машинасына махсус конструкция куйганнар, ә Казан электр челтәрләре филиалында аны камилләштергәннәр, алай гына да түгел, яхшырту процессы әле һаман дәвам итә. Һәм барлык структура бүлекчәсендә диярлек шундый хәл күзәтелә. Аерым алганда, Көньяк район электр челтәрләре бригадасы гына да соңгы елларда 27 камилләштерүне гамәлгә керткән.

КИЛӘСЕ БАСКЫЧ – АЛТЫН

Камиллеккә чикләр бармы? Япониядән килгән кунакны суперзаманча объект – «Азино» цифрлы подстанциясе белән таныштыру моның өчен резервларның җитәрлек булуын раслый. «Энергия» җитештерү системасы электр энергетикасы белән бергә үсә! Нәкъ менә бердә тиңдәшсез техник бурычлар хәл ителә һәм, гадәтигә әйләнеп, аннары компаниянең башка объектларында да гамәлгә ашырыла.

Аудиторларны урыннардагы хезмәткәрләр инициативасы нәтиҗәсендә тормышка ашырылган үзгәрешләр белән Кулланучыларга хезмәт күрсәтү дирекциясендә дә таныштырдылар. Камилләштерүләрнең «элек - хәзер» форматындагы презентациясе Тосио



Хорикирида сораулар тудырды. Эшнең асылын яхшы белүе белән дирекция персоналын таң калдырып, остаз шундук кулланучыларга хезмәт күрсәтү системасын камилләштерү буенча берничә кирәкле киңәш тә бирергә өлгерде. Һәм гел шуны искәртүдән туктамады: барыннан да бигрәк персоналны активлаштыру зарур. Аның әйтүенчә, эш белән янып йөрүче хезмәткәр үзе өчен дә, компания өчен дә күпкә файдалырак.

Аудит нәтиҗәләрен игълан иткәнче, Тосио Хорикири әфәнде урыннарда күргәннәренә тәфсилле анализ ясады. Нәтиҗә күз алдында: күп күрсәткечләрнең уңай динамикасы сөендерә. «Сез – җитештерү системасы һәм идарә итү системасына тәңгәллекнең көмеш дәрәҗәсенә лаек булган Россиядә беренче компания, һәм дөньяда бик аз санлы шундый югары дәрәҗәле компанияләр арасына керәсез. Бу бик шәп нәтиҗә», – дип йомгак ясады Тосио Хорикири.

«Челтәр компаниясе» генераль директоры Илшат Фәрдиев, югары бәясе өчен Тосио Хорикирига рәхмәтен белдереп, шуны искәртте: бу – компания коллективының ун еллык эшчәнлеге казанышы, ул бик күп вак адымнан һәм җитештерү процессын яхшыртулардан гыйбарәт. «Бу экономия, безнең эшчәнлегебезнең барлык участокларында югалтулардан котылу мөмкинлеге, һәм бу эш дәвам иттереләчәк. Сакчыл җитештерү безгә барлык күрсәткечләребезне яхшыртырга сәләтле үзгәрешләр кертергә ярдәм итә», – дип басым ясады компания башлыгы.



ИЛШАТ ФӘРДИЕВ,
«Челтәр компаниясе» генераль директоры:

– Үзенең кайдзен-эшчәнлегенә ясалган аудитта безнең компания яңа югары бәя алды. Моннан өч ел элек без бронза дәрәҗәгә ирешкән дөньяда беренче электр челтәрләре компаниясе булган идек, ә менә хәзер исә безне Toyota Engineering Corporation Гомуми җитештерү системасы принципларына тәңгәллекнең көмеш дәрәҗәсенә лаек дип таптылар. Алай гына да түгел, компания япон аудиторларының берьюлы ике бүләген алды: сакчыл җитештерү системасы өчен дә, система белән идарә итү дәрәҗәсе өчен дә. Асылда, бу җитештерү эшчәнлегенә дә, идарә итү эшчәнлегенә дә югары бәя.

Моңа ничек ирешелде соң? Дистә ел буе бертуктаусыз без сакчыл җитештерү элементларын көндәлек эшчәнлегебезгә керттек. 138 661 кайдзен-тәкъдим кертүнең һәм 791 кайдзен-проектны гамәлгә ашыруның икътисадый файдасы якынча 1,7 миллиард сум тәшкил итте. Һәм, минемчә, иң мөһиме – идарә итү моделен сизелерлек үзгәртү һәм гади хезмәткәрләрне дә җитештерү белән идарә процессына җәлеп итү. Бездә һәркем үзенең эш процессларын яхшыртуны кайгырта, һәм һәркем үз инициативасының шундук гамәлгә ашырылуын күрә.

Бу елларда системаның парадигмасы, аның статусы шактый үзгәрде һәм «Челтәр компаниясе»нең инновацион үсеш модельләрен кертүче лидер буларак үз позицияләрен ныгытуы нәкъ менә сакчыл җитештерү системасын үстерү нәтиҗәсендә мөмкин булды. Бу безнең компания ДНКсының бер өлешенә әйләнде. Кризислы икътисад шартларында кайдзен инструментларыннан башка көндәшлеккә сәләтлелекне тиешле дәрәҗәдә саклап булмый.

Без даими үзгәрәбез һәм үзебезнең әйләнә-тирәне дә үзгәртәбез. Үзебезнең тәэминатчыларны, подрядчыларны, үзебез эшләгән район һәм шәһәр хакимиятләрен кайдзен прининипларына өйрәтәбез. Кайдзен безнең һәркайсыбыз өчен яңарыш, рационализация, алга бару фәлсәфәсенә әйләнде.

Бурычыбыз – ирешелгәннәрдә генә туктап калмау. Алда – яңа офыклар һәм яңа чикләр. Без трансформацияләр һәм үсешнең юнәлешләрен күрәбез, үз принципларыбызда нык торабыз. Без һәр хезмәткәребезнең, үзенең эш урынын һәм янәшәдәге дөньяны матурайтып, компания белән бергә эшләргә һәм үсәргә омтылуын телибез. Компаниянең «Һәркемне кайгыртып, һәркемгә энергия биреп!» дигән девизы белән без «Тойота» җитештерү системасы принципларына тәңгәллекнең алтын дәрәҗәсенә дә һичшиксез ирешәчәкбез!

ГУАНЬСИ* НИГЕЗЕНДӘ – АҢЛАШУ

Россия бизнесменнары атларны ни өчен ярата дип уйлыйсыз? Чөнки ат томырылып алга баруны, тизлекне символлаштыра, ә бу бизнеска да хас сыйфатлар.

– Тагын ат күп кенә аңлатмаларда җиңү, көч һәм үҗәтлек, хөрмәт һәм тынычлык төшенчәләре белән тыгыз бәйләнгән, – дип өсти эшмәкәр, Sign Group** җитештерү компаниясенә һәм маркетплейсларда ир-ат киемнәрен сату буенча сәүдә компаниясенә нигез салучы Ләйлә Сафина.

Ләкин бүген без Ләйлә ханым белән атлар турында түгел, ә аның Кытай белән тыгыз бәйләнгән бизнесы хакында сөйләшәбез.

РЕКЛАМА

** Гуаньси — Кытайда ярдәм, булышу, хезмәт күрсәтүне аңлата торган термин. Гуаньси нигезендә үзара ышаныч ята.*
*** Sign Group** компаниясе - реклама-мәгълүмат конструкцияләрен һәм кече архитектура формаларын җитештерү.*
**** e-commerce – электрон коммерция (инглиз теленнән)*

КӨН САЕН ЭЛЕМТӘДӘ

– Беренче тапкыр Кытайга 2014 елда күргәзмәгә дип бардым. Ул вакытта Пекинга турист буларак баруымны эш сәфәремә туры китердем. Аннары ешрак йөри башладым: күргәзмәләргә, тәэминатчылар, җитештерүчеләр белән танышырга бардым, фабрикаларга йөреп, эшлекле элемтәләр урнаштырдым. 2020 елга кадәр үземнең реклама-җитештерү компаниясе өчен зур булмаган партияләр белән материаллар сатып алдым. Пандемия вакытында чикләр ябылды, сәфәрләр дә туктатылды. Бөтен игътибар яңа шартларда бизнесны ничек тә саклап калуга юнәлтелде.

Шул ук вакытта безнең сатып алуларда зур өлешне Европа яки Россия материаллары тәшкил итте, ә станокларны Япониядән яки АКШтан сатып алдык.

2023 елда, пандемиядән соң чикләр ачылгач, Кытай ягына борылдык. 2023 һәм 2024 елларда бу илдә сигез тапкыр булырга туры килде. Кытай белән көн саен диярлек элемтәдә тордым. Соңгы елда төрле шәһәрләрдәге биш профильле күргәзмәдә булырга туры килде.

Минем ике бизнесым бар – e-commerce*** өлкәсендә сәүдә һәм җитештерү компанияләре. Җитештерү бизнесы өчен без Кытайдан станоклар, материаллар алып кайтабыз, технологияләр, яңа чишелеш һәм продуктларны өйрәнәбез. Типография өчен станокларның соңгы партиясе шушы көннәрдә генә килде: бу – тукымаларга ике яклы туры басу станогы һәм сувенир продукциясе өчен УФ-станоклар. Быел без дүрт яңа буын станогы сатып алдык һәм реклама, сувенир продукциясе исемлеген сизелерлек киңәйттек.

Сәүдә бизнесы өчен (маркетплейсларда ир-ат киемнәре сатабыз) үз продукциямне килешү буенча Кытайда тегәм, шулай ук профильле күргәзмәләрдә булам, тукымалар, фабрикалар, модельләр сайлыйм.

ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ҮЗЕМ АРАЛАШЫРГА ТЫРЫШАМ

– Сезнең өчен тел проблемасы бармы, әйтик, Кытай бизнесы вәкилләре белән аралашуны, документларны тәрҗемә итүдә? Бу Кытай белән бизнес алып барганда ниндидер өстәмә җитди чыгымнар таләп итәме?

– Тәрҗемә проблемасы бар, чөнки кытайларның күбесе инглиз телен белми. Бу очраклар өчен һәрвакыт рус һәм кытай телләрен белүче һәм ярдәм итә алучы җирле тәрҗемәчеләр бар, шулай ук интернет-тәрҗемәчеләр ярдәм итә.

Статистика буенча бүген инглиз телен Кытай халкының 14% тан артыгы гына белә, нигездә, бу – яшь буын.

Тәрҗемәче хезмәте көненә уртача 150–300 доллар белән бәяләнә, тәрҗемә дәрәҗәсенә һәм катлаулылыгына бәйле рәвештә үзгәреп тора. Инглиз телен яхшы белгәнгә, күргәзмәләрдә, хәтта тәрҗемәчем булса да, җитештерүчеләр белән үзем аралашырга тырышам.

ТЕЛӘСӘ НИНДИ АҢЛАЕШСЫЗ ВАЗГЫЯТЬТӘ – ЫШАНЫЧ

– Еш кына башка милләт (ил) вәкилләре белән сөйләшкәндә, без куллана торган ишарәләр, сүзләр бөтенләй капма-каршы мәгънә йөртергә, икенче як исә, киресенчә, безнең тараф дөрес аңламаска мөмкин. Тәҗрибәле эшмәкәр буларак, әйтегез әле: Кытай бизнесы вәкилләре белән аралашу вакытында туган аңлаешсыз вазгыятьтә үзеңне ничек тотарга?

– Кытайлар белән төгәл, аңлаешлы бурычлар куеп, шунда ук килешүнең барлык шартларын әйтеп сөйләшергә кирәк. Безнең өчен гадәти булган нәрсәләр икенче як тарафыннан башкача кабул ителергә мөмкин, чөнки мәдәни һәм милли үзенчәлекләр төрле. Аларны исәпкә алу зарур.

Мәсәлән, кытайларның иң зур кешесе бүлмәгә беренче булып керә. Димәк, сезнең төркемнең иң беренче кергән әгъзасы да алар тарафыннан делегация башлыгы буларак кабул ителәчәк.

Визит карточкасын ике кул белән дә бирү кабул ителгән: бу – партнёрга хөрмәт күрсәтү билгесе.

Сөйләшүләрнең мәҗбүри өлеше – бүләкләр. Кытайда алар һичшиксез кунак килгән илдән булырга тиеш. Кунакларга шулай ук Кытай чәе, җирле кызыл хөрмә, сувенирлар бүләк итәргә дә ярый. Гадәттә бүләкләр сөйләшү ахырында бирелә. Һәм килешү никадәр зуррак булса, бүләкләр дә шулкадәр кыйммәтлерәк булырга тиеш.

Кытайда – «ризык культы». Төшке аш зур түгәрәк өстәл артында уза, анда күптөрле милли ризык куела. Монда ризыкның тәменә сокланып, авызыңны чапылдатып ашау гадәте бар. Әгәр Кытай вәкиле сезнең белән бергә ашый икән, димәк, ул сезгә ышана. Шуңа күрә сөйләшүләр уңышлы тәмамланганнан соң, сезгә, мөгаен, бергә ашарга тәкъдим итәчәкләр. Моннан баш тартырга кирәкми. Кытайлар еш кына нәкъ менә төшке аш вакытында эшлекле мәсьәләләрне хәл итә, үзегез дә моның белән чакырган якка хөрмәтегезне күрсәтәсез.

Әгәр дә сез төшке ашны алдан әзерләнгән урында түгел, ресторанда ашыйсыз икән, акчаны үзегез өчен үзегез түләргә тәкъдим итегез. Әгәр рөхсәт итмиләр икән, китәр алдыннан аларны кичке ашка чакырыгыз һәм ашау өчен үзегез түләгез. Бу сезгә партнёр белән тигез хокукларда калырга ярдәм итәчәк, һәм сез бизнеста ниндидер ташламаларга барырга тиеш булмаячаксыз.

Кытай кешесенә исем буенча якын дуслары гына мөрәҗәгать итә ала, шуңа күрә сөйләшүләр вакытында партнёрыгызның фамилиясен яки рәсми вазыйфасы атамасын кулланыгыз.

Кытай мәдәнияте нигезендә гаиләдән тыш мөнәсәбәтләр һәм бәйләнешләр төшенчәсе ята. Үзара ярдәмләшү, хөрмәт итешү, уртак максатлар һәм проектлар, уртак ял, уртак төшке ашлар, кичке ашлар – бу «гуаньси» дип атала. Кытайлар өчен уртак бизнесны башлаганчы кешенең үзе белән танышу мөһим. Эшлекле мәсьәләләрнең ничек, ни өчен һәм кайчан хәл ителәчәге мөнәсәбәтләрнең ничек корылуыннан тора. Мөнәсәбәтләр никадәр тирән һәм ышанычлы булса, үзара килешүләр күләме дә зуррак булачак. «Гуаньси» процессында кабул ителгән йөкләмәләр бик мөһим һәм берсүзсез үтәлә.

Тулаем алганда, минем партнёрлар белән мөнәсәбәтем җайлы урнашты, күпләр белән дуслар кебек аралашабыз, безнең «гуаньси» уңай.

СТАНОКЛАР – КҮК АСТЫ ИЛЕННӘН

– Сезнеңчә, Кытайның алга китешенә нәрсә шундый көчле этәргеч бирде?

– Беренчедән, Кытай компанияләренең көндәшлекле өстенлеге – анда җитештерүнең үзкыйммәте арзан булу, бу исә күп очракта хезмәт хакларының

ЛӘЙЛӘ САФИНАДАН КЫТАЙ БАЗАРЫНА КЕРҮНЕҢ

5 КАГЫЙДӘСЕ:

1 Илнең мәдәни һәм милли үзенчәлекләрен өйрәнегез.

2 Үзегез эшләргә теләгән юнәлешне, кирәкле товарны ачыклагыз. Тәэминатчыларны өйрәнү, танышу, элемтәләрне җайга салу өчен профильле күргәзмәләргә барыгыз. Күргәзмәдә Кытай фабрикасы вәкилләре белән очрашырга, продукция үрнәкләрен карарга һәм барлык нечкәлекләр турында фикер алышырга мөмкин. Продукциягә заказ биргәнче, һичшиксез, алдан сөйләшеп, фабрикага шәхсән үзегезгә барып кайтырга кирәк. Кытайда агентлар аша эшләү алга киткән, шуңа күрә хәтта күргәзмәдә дә сез җитештерүченең үзен түгел, ә арадашчыны очрата аласыз. Һәм ул вакытта бәя белән гарантияләр сез көткәнчә булмаска мөмкин.

3 Кытайда производстволарны урнаштыруның кластер системасы кабул ителгән. Бер төбәктә бер үк типтагы продукция җитештерү белән шөгыльләнә яки чиктәш тармакларда эшли торган дистәләгән, йөзләгән предприятие туплана. Алар барысы бергә эшлиләр, берберсенә ярдәм итәләр һәм базарда үз позицияләрен ныгыталар. Мондый кластерлар – эре предприятиеләр тәэминатчылар, логистика компанияләре һәм хәтта фәнни институтлар белән тыгыз бәйләнештә эшли торган тулы бер экосистема.

4 Фабрикада булып, продукциягә заказ биргәннән соң, логистика буенча партнёрны ачыкларга кирәк. Салым үзенчәлекләрен, таможня кагыйдәләрен, иминиятләштерүне, илтеп җиткерү шартларын һәм төрләрен исәпкә алырга.

5 Кытай компаниясе белән эш башлаганда ук акча күчерү һәм товар һәм хезмәтләр өчен түләү мәсьәләсен шунда ук хәл итегез.

түбәнлегенә бәйле. Һәм чит илләргә Кытай базарына юл ачылгач, күп кенә компанияләр тиз генә үз производстволарын шунда күчерде. Барысы да арзанлы киң куллану товарларыннан (уенчыклар, кием-салым һ.б.) башланды, ләкин аннары яхшы сыйфатлы һәм югары технологияле продукцияләр (автомобильләр, көнкүреш электроникасы, яктылык диодлары, IT-товарлар) җитештерү торган саен күбрәк була башлады. Җитештерү дә үсте, җирле базарда, экспорт юнәлешендә товарлар куллану да артты.

Икенчедән, дәүләт предприятиеләре сәнәгатьнең оборона, энергетика, машина төзелеше һәм башка стратегик әһәмияткә ия тармакларын технологик яктан үстерүгә инвестицияләрне актив кертте. Шулай ук фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренә дә. Кытай бүген НИОКРга гомуми чыгымнар буенча АКШтан кала дөньяда икенче урында. Хакимият шулай ук фундаменталь һәм гамәли фәннәр кисешкән урында коммерция структураларын үстерүне стимуллаштыра – технопарклар тибындагы ирекле икътисади зоналар, венчур-инвестиция институтлары һәм фонд биржаларында фән сыйдырышлы кече компанияләр өчен мәйданчыклар төзелә.

Өченчедән, салым салу. КХРның салым сәясәте – уңай икътисади һәм инвестицияле климат булдыру, капитал салуны киңәйтү, чит ил инвестицияләрен җәлеп итү. Хакимият тиз үзгәрә торган бизнес-мохиттә эшлекле активлык шартларын даими яхшыртып тора, шуңа күрә бу илдә салым салу кагыйдәләре һәм салым ставкалары еш үзгәрә.

Дүртенчедән, технологияләр. Көнбатыш компанияләренең үз производстволарын Кытай базарына күчерүе нәтиҗәсендә җирле җитештерүчеләр аларның технологик яңалыкларына ия булу мөмкинлеген алды. Бу компанияләрнең кушылуына яки хәтта Азия сәнәгать лидерлары тарафыннан йотылуына китерә башлады.

Мәсәлән, әле ун ел элек машина төзелеше секторында Европа, Япония, Тайвань һәм берничә Америка компаниясе өстенлек итә иде. Ә бүген Кытай станоклар төзү тармагы предприятиеләре өчен иң эре сату базарына ия, аңа дөньякүләм ихтыяҗның 40 процентка якыны туры килә. Һәм әгәр биш ел элек мин Кытай станокларына шикләнеп карап, япон һәм Американыкын сатып алуны өстен күрсәм, хәзер аларның сыйфаты шулкадәр яхшырды ки, без үзебезгә бу ил станокларын сатып алабыз.

БИЗНЕСНЫҢ КАТЛАУЛЫЛЫГЫ

– Санкцияләр нәтиҗәсендә Кытай белән бизнеста нинди кыенлыклар өстәлде?

– 2024 елның март – апрелендә Россия импортёрлары, АКШ керткән икенчел санкцияләр аркасында, Кытайга түләүләргә бәйле вазгыятьнең кискенләшүенә юлыкты. Фактта Кытай Россиядән килгән түләүләрнең 80 процентын туктатты.

Хәзерге вакытта барлык банклар да диярлек Россия банкларыннан халыкара түләүләрне кабул итүдән баш тартты. Беренче чиратта бу санкциягә эләккән банклардан күчерүләргә, санкцион товарлар һәм икеләтә билгеләнештәге товарлар өчен түләүләргә кагыла.

Кытайда Россиядән күпчелек түләүләр уза торган бердәнбер банк –

«ВТБ Шанхай»*. Ләкин аңа йөкләнеш бик зур, еш кына өзеклекләр була, счет ачылуны да 3-6 ай көтәргә туры килә.

Alipay** янчыклары белән тагын бер проблема – исәп-хисапны тулыландыру. Элек эшмәкәрләр Россия банклары карталарын бәйләп, товар өчен түли ала иде. Әмма кагыйдәләр үзгәрде: түләү системасы РФ территориясендә ачылган теләсә нинди картаны бәйләүне тыйды.

Бүген россиялеләр өчен янчыкны тулыландыруның бердәнбер ысулы – турыдан-туры башка янчыктан күчерү яки Кытай банк картасын бәйләү. Вазгыятьтән чыгу өчен, эшмәкәрләр агент схемаларыннан файдалана – Кытайда счетны тулыландырырга ярдәм итүчеләрне эзли. Мондый хезмәтләр, әлбәттә, өстәмә чыгымлы. Моннан тыш, әгәр система операцияне шикле дип санаса, янчыкка блок куя.

БЕРДӘМ ВАЛЮТАМЫ ЯКИ РОССИЯ АКЧАСЫ?

– Бу вазгыятьтән чыгу юлы бармы?

– Экспертлар вакыйгалар үсешенең берничә вариантын күрә:

– эре Кытай банклары санкцияләргә эләгүдән шикләнә, шуңа күрә проблемалы транзакцияләрдән качуны дәвам итәчәк. Ә менә вак төбәк банклары россиялеләр белән хезмәттәшлек итәргә әзер булырга мөмкин;

– илләр арасында исәп-хисап ясау өчен яңа валюта барлыкка киләчәк. Күпләр БРИКС илләре өчен бердәм валюта булдыруга зур өметләр баглый. Ул Кытай һәм Россия партнёрлары арасындагы исәп-хисапларда доллар һәм юаньга бик яхшы альтернатива була алыр иде. Әмма әлегә проект эшләнә генә;

– үзара исәп-хисап ясаганда рубльгә күчәчәкләр. Эре компанияләр инде безнең акчада исәп-хисап алып бара;

Хәзер күпләр куллана торган эш схемасы – өченче илләр (БГӘ, Кыргызстан, Казахстан) аша акча күчерү.

Әмма ул товарларның үзкыйммәтен 6-10% ка арттыра, бу, әлбәттә, товарның ахыргы бәясендә чагылыш таба.

АКБҮЗ АТТА – АЛГА!

– БРИКС саммитыннан бизнесыгызны үстерү юнәлешендә нәрсәләр көтәсез (һәм, ихтимал, Кытай белән генә дә түгел)?

– Эшмәкәр буларак, беренче чиратта, мин илләр арасында түләү операцияләре буенча карарлар көтәм.

Россия ССП советының Финанс һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы комиссиясе рәисе Тимур Аитов сүзләренчә, системалы яклау чаралары кирәк: чит ил көйләүчеләре һәм трансмилли банклар кертелмәгән үзара исәп-хисапларның ябык контурын булдыру. Мондый схема буенча совет чорында Үзара икътисади ярдәм советына (СЭВ) кергән социалистик илләрдә түләүләр рубльдә башкарылган.

Иң ачык вариант булып цифрлы финанс активларын куллану тора. Россия Банкы 1 сентябрьдән халыкара исәп-хисаплар тәҗрибәсенә цифрлы рубльләрне тест режимында кертү хокукы алды. Моның ничек эшләячәген аңлау өчен, ким дигәндә, бер квартал узарга тиеш. Димәк, 2025 елны көтәчәкбез. Барысы да әйбәт килеп чыкса, мин ышанам, акбүз атка атланып алга очарбыз!

** Шанхай ш. (Кытай) ВТБ Банкы (ГАЖ) филиалы. **Alipay – акчалата түләү.*

Фототөшерүләр режиссёры: wonderpeoplegroup. Фотограф: Анастасия Алашеева. Стиль: Нәргизә Солтан. Мейк: Елена Жукова

RSI GARANT*



* Эр-Эс-Ай Гарант

ҖИҢҮГӘ ЙӨЗ ТОТА

Дмитрий Сивков

Түләү агенты халыкара исәп-хисапларны оптимальләштерү хисабына илебез импортёрларына һәм экспортёрларына чит илләрдәге партнёрларына түләүләрне үткәрү белән бәйле проблемаларны хәл итәргә булыша.

КЫТАЙ: ПЛЮСЛАРДАН ТЫШ МИНУСЛАР ДА БАР

Кытай җитештерүчеләре белән икътисади хезмәттәшлек арткан-нан-арта бара. Бигрәк тә соңгы өч елда, Россия катгый санкцияләргә дучар булганнан соң. Ләкин хезмәттәшлек арту белән бергә моның үз кыенлыклары да килеп чыкты. Төп проблема – түләүләрне үткәрә алмау, һәм ул һәркемгә – импортёрларга да, экспортёрларга да кагыла. Ә бу, үз чиратында, товарларны вакытында җибәрә алмауга һәм билгеле бер очракларда аның ахыргы бәясе үзгәрүгә китерә.

Шулай да була: еллар буена җайга салынган сәүдә чылбыры өзелә. Россиянең күп кенә компанияләре, шул исәптән зурлары да, Кытайдагы партнёрларга акчаны ничек күчерү чарасын таба алмыйча, үзебездә җитештерелгән чималга күчәргә мәҗбүр. Бер яктан, бу яхшы, үзебездә җитештерелгән продуктка сорау туа, ә икенче яктан, продукциянең сыйфаты тиешенчә булмаска мөмкин. Россия банклары өчен мультивалюталы операцияләрне хуплау, исәп-хисапны юаньнарда ясауны арттыру һәм финанс-техник чишелешләр хәлиткеч адым булып торыр иде. RSI GARANT кебек финанс сервислары чын-чынлап тотрыклы һәм сыгылмалы халыкара системалар булдырырга ярдәм итә. Мондый платформалар шактый мөһим роль уйный, алар клиентка партнёрлык структуралары аша глобаль исәп-хисапларга юл ача.

RSI GARANT, транзакцияләрдә арадашчы буларак, ышанычлы юллар тәкъдим итә, валюта белән бәйле төрле көтелмәгән хәлләрне киметергә булыша, клиентларның катлаулы сорауларына җавап бирә, яңа икътисади чынбарлыкта халыкара бизнес алып баруны җиңеллләштерә.

Әлеге югалтулар товарның бәясендә дә, сыйфатында да чагылыш тапмасын өчен нишләргә кирәклеге хакында RSI GARANT Халыкара акча күчерү һәм алмашу сервисына нигез салучы һәм аның генераль директоры Ярослав Салеев белән сөйләшәбез.

– Ярослав Станиславович, Кытай банкларының Россия акчасы белән эшләүдәге үзгәрешләре халыкара транзакцияләрдә ничек чагылыш тапты?

– Әйе, хәзер чынлап та халыкара транзакцияләр белән җитди кыенлыклар бар. Бу кыенлыклар бер Кытай белән ике арадагы исәп-хисапка гына кагылмый, санкцияләр аркасында, Россиянең финанс оешмалары белән эшчәнлекне киметкән башка илләргә дә кагыла.

Кытай банкларына килсәк, аларның Россия акчасын кабул итүдән баш тартулары илебез компанияләре белән Кытай партнёрлары арасында исәп-хисап ясауны сизелерлек катлауландырды. Бу транзакцияләр чылбырының озынаюына һәм бизнес өчен чыгымнарның артуына китерә, бигрәк тә импортка нык бәйле булган сфераларда. Бизнеска боларны урап узу юлларын табарга туры килә, моңа вакыт сарыф ителә һәм фокус югала. Кайбер бизнеслар үзебездә җитештерелгән продуктларга күчә, чөнки түләү өчен даими һәм тотрыклы булган шлюзлар таба алмый.

– Кытай банкларына Россия акчасын кабул итәргә нәрсә комачаулый, һәм бу проблеманы чишү мөмкинлеге бармы?

– Монда төп фактор булып Кытай банкларының Көнбатыш илләре тарафыннан икенчел санкцияләргә эләгүдән куркуы тора. Кытай тарафыннан рәсми санкцияләр булмаса да, күп кенә финанс оешмалары халыкара базарга йөз тота һәм Көнбатыш партнёрлар белән хезмәттәшлекнең чикләнүеннән куркалар.

GARANTКА АКЦЕНТ

– Әлеге проблеманы хәл итү юлларын ничек күрәсез?

– Проблеманы хәл итү юллары Кытайның түләү системалары белән тагын да ныграк якынаю, Россия белән хезмәттәшлеккә йөз тоткан банкларның эшен җайлау юнәлешендә булырга мөмкин. Тагын бер юл – исәп-хисапларның халыкара көйләүчеләр тарафыннан янаган куркынычка азрак дучар булырлык яңа механизмнарын булдыру. Мәсәлән, БРИКС илләренең исәп-хисап берәмлеге кебек.

GARANT КУРКЫНЫЧСЫЗ ҺӘМ НӘТИҖӘЛЕ ХАЛЫКАРА ИСӘП-ХИСАПЛАРГА МОХТАҖЛЫК КИЧЕРӘ ТОРГАН КОМПАНИЯЛӘРГӘ АРАДАШЧЫ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТӘ. ИҢ МӨҺИМЕ – КОМПАНИЯ ҺӘРБЕР КИЛЕШҮНЕҢ ЮРИДИК ЧИСТАЛЫГЫН ТӘЭМИН ИТӘ.
GARANT ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ДӨРЕС ИТЕП ТУТЫРЫЛУЫ ҺӘМ БАНК ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮЕНЕҢ НИКАДӘР МӨҺИМ БУЛУЫН АҢЛЫЙ, ШУҢА ДА ҺӘРБЕР ТРАНЗАКЦИЯНЕҢ ЫШАНЫЧЛЫ ҺӘМ ҮТӘ КҮРЕНМӘЛЕ БУЛУЫ – БЕЗНЕҢ ӨЧЕН БЕРЕНЧЕ УРЫНДА. ЮРИСТЛАР ҺӘМ САЛЫМ БЕЛГЕЧЛӘРЕ ДОКУМЕНТАЦИЯНЕ ҺӘМ БАРЛЫК НОРМАЛАРНЫҢ САКЛАНУЫН КОНТРОЛЬДӘ ТОТА, БУ ИСӘ СЕРВИСТАН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАРГА, ХАЛЫКАРА ТҮЛӘҮЛӘРНЕҢ ИҢ КАТЛАУЛЫ ЯКЛАРЫН GARANTКА ЫШАНЫП, БАНКЛАР БЕЛӘН ТЫНЫЧ КЫНА ЭШЛӘРГӘ ҺӘМ ТӨП ИГЪТИБАРНЫ БИЗНЕСНЫ ҮСТЕРҮГӘ ЮНӘЛТЕРГӘ МӨМКИНЛЕК БИРӘ.



RSI GARANT – халыкара түләүләр белән 2020 елдан бирле уңышлы эшлибез. Без тышкы икътисади эшчәнлеккә комплекслы ярдәм күрсәтәбез. Бу экспертизага һәм әлеге тармакны тирәнтен белүгә нигезләнгән. Безнең тәҗрибәдә – **40 ил белән 35 000 нән артык уңышлы башкарылган килешүләр һәм 15 000 нән артык клиент базасы**, болар безнең һәртөрле катлаулы мәсьәләне хәл итә алуыбызны раслый.

Юридик затларга ярдәм:

- ВЭД буенча операцияләр үткәрү (төрле юрисдикциядәге компанияләр арасында, шул исәптән Россия Федерациясе белән дә, легаль түләүләр үткәрүдә ярдәм)
- Клиентларының финанс мәсьәләләрен хәл итү буенча куәчемсез милек агентлыклары һәм банк оешмалары белән хезмәттәшлек
- Финанс транзакцияләрен оптимальләштерү белән ярдәм итү (иң файдалы юлларны эзләү)
- Халыкара килешүләрдә документаль ярдәм күрсәтү

Безнең арсеналда һәртөрле бурычларны капларга ярдәм итүче бик күп оешмалар бар: сәүдә компанияләре, чимал компанияләре, судно компанияләре, кыйммәтле кәгазьләр брокеры лицензияләре, алтын белән сату итүче компанияләр, сәнәгать компанияләре, финанс агентлары. Юристлар һәм салым белгечләре килешүнең үтә күренмәлелеген тикшерәчәк.

– Россия компанияләре һәм шәхси затлар чит илләр белән исәп-хисап ясар өчен нинди альтернатив чаралар эзли?

– Компанияләр һәм шәхси затлар чикләүләрне урап узар өчен төрле юллар эзли. Альтернатив вариантлар буларак, хәзер түбәндәгеләр актив кулланыла:

- Исәп-хисапны өченче илләр аша ясау. Болар нигездә БДБ илләре.
- Кара-каршы җаваплылык йөкләмәләре схемасы, гадиләштереп әйтсәк – очрашу. Бу туры халыкара түләүләр ихтыяҗын киметә, срокларны кыскарта, шулай ук Россия белән турыдан-туры түләү элемтәсеннән качарга булыша.

Һәр ысулның үз плюслары бар. Түләү агенты буларак, без кара-каршы җаваплылык йөкләмәләре белән эшләү схемасына ныграк акцент ясыйбыз. Практикадан күренгәнчә, һәм бу хакта клиентларыбыз да әйтә, мондый ысул белән түләнгән акча тизрәк һәм яхшырак барып җитә, аннары банклар да бу ысулга лояльрәк карый.

ТҮЛӘҮ АГЕНТЫ ЯРДӘМГӘ КИЛӘ

– Клиентларның халыкара исәп-хисап ясау мөмкинлеген арттыру өчен, Россия банклары нинди адымнар ясый ала?

– Россия банклары мондый адымны ясый һәм үз клиентларының исәп-хисаплары өчен түләү агентларын актив куллана. Әлеге этапта бу көтелмәгән хәлләрне киметергә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, цифрлы акча белән эшләү өчен инфраструктураны үстерү дә өстенлекле юнәлеш була ала. Ул киләчәктә түләүләрне гадиләштерер иде. БРИКС илләре өчен бердәм исәп-хисап берәмлеге булдыру инициативасы да мөһим адым булып тора.

– Сезнең кебек финанс сервисларының һәм платформаларының әлеге проблеманы хәл итүдәге роле?

– Безнең сервис түләү агенты вазыйфасын башкара һәм йөкләмә, зачет, цессия кебек инструментлар аша халыкара исәп-хисапларны оптимальләштерүдә мөһим роль уйный. Бу туры халыкара түләүләргә бәйлелекне һәм кирәкле түләүләрне башкаруны киметергә булыша. Шушы сервис ярдәмендә без үз клиентларыбыз өчен Кытай белән генә түгел, илебезнең икътисады өчен мөһим булган күп кенә башка илләр белән дә көн саен исәп-хисап ясыйбыз. Без шулай ук альтернатив түләү системаларын куллануны арттыру өчен булган мөмкинлекләрне тикшерәбез. Бу киләчәктә Россиянең күп кенә компанияләренә, хәзерге чикләүләргә карамастан, бизнесны тагын да уңышлырак итәргә булышыр иде. Шулай булгач, без җиңүгә йөз тотабыз һәм инде үз адымыбызны ясадык. Чират – клиентларыбызда.

GARANT
СЕЗНЕҢ ЙӨРЕШ!
RSI GARANT БЕЛӘН
ҖИҢӘР ӨЧЕН УЙНАГЫЗ!
ХАЛЫКАРА ТҮЛӘҮЛӘР БУЕНЧА КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘРДӘН
АЛЫП ВЭД-ЮНӘЛЕШ БУЕНЧА ОПЕРАЦИЯЛӘР
ҮТКӘРҮГӘ КАДӘР
garantbit.com
«ЭР-ЭС-АЙ Капитал» ЖЧҖ. РЕКЛАМА

МАРАТ ҖӘББАРОВ: МАКСАТ – ИДЕЛ БУЕ ТӨБӘГЕНДӘ АШЛЫК ХАБЫНА ӘЙЛӘНҮ

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынды

Татарстан ашлыгын кайсы илләр сатып ала? Кыраулар һәм корылык җилләре уңышның күпме өлешен «йоткан»? Татарстанлыларга бәрәңге һәм яшелчәләр җитәрме? Россия Федерациясендә кем күбрәк сөт җитештерә? «Татарстан»ның әлеге һәм башка сорауларына Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров җавап бирә.

Әхмәт Шакиров

УРЫП-ҖЫЮ, УҢЫШ ҺӘМ ЮГАЛТУЛАР ТУРЫНДА

– Марат Азатович, быел игенчеләр 3,8 миллион тонна ашлык җыеп алыр, дип көтелә. Һава торышының сюрпризларын исәпкә алсак, бу күпме, әллә азмы?

– Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре үстергән продукция халыкны азык-төлек продуктлары белән тәэмин итүгә дә, аның шактый күләмен республикадан читкә чыгару өчен дә җитәрлек. Сүз уңаеннан, Татарстан Рәисе күптән түгел Дәүләт Советына Юлламасында моңа басым ясап, авыл халкына авыр хезмәте өчен рәхмәт белдерде. Җыелган уңыш күләме әйбәт, бигрәк тә игенчеләргә быел нинди сынаулар аша узарга туры килгәнен исәпкә алгандә. Исебезгә төшерик әле, май аенда көчле кыраулар булды, шуның аркасында өч мең гектар уҗымнар зыян күрде, сигез мең гектар рапс һәм шикәр чөгендерен кире чәчәргә туры килде. Июльдә кырларда коры җил котырды. Ә август башында, урып-җыю алдыннан, ике атна буе коеп яуган яңгырлар нәтиҗәсендә игеннәр башакта шыта башлады һәм ашлыклар җиргә ауды. Нәтиҗәдә, уңайсыз һава торышы аркасында уңышның 10 проценттан артыгын югалттык.

– Шуңа да карамастан, бөртеклеләрнең уртача уңышы гектардан 28 центнер чамасы булды…

– Ә Тәтеш районында гектарыннан - 38,9, Кукмара районында – 37,8, Әтнә районында – 34,4, Кайбыч районында 32,9 центнерны тәшкил итте. Шул ук вакытта Баулы районында бөртеклеләрнең уңышы 17 центнердан чак кына артык, Ютазы районында 20 центнердан азрак. Әгерҗе һәм Азнакай районнарында бер гектардан алынган уңыш 21 центнердан артмый. Алдынгы районнарда уңайсыз һава шартларына алдынгы технологияләрне һәм оешканлыкны каршы куя беләләр, нәтиҗәсе дә шуннан.

Әлбәттә, кыраулар, яңгырлар һәм коры җилләр төрле районнарда төрле дәрәҗәдә зыян итте, кайбер районнарга алар күбрәк, икенчеләренә азрак кагылды. Тулаем алганда, һава торышы начар булу сәбәпле, игенчеләр 300 мең тоннага якын ашлыктан мәхрүм калды, чынлыкта алар дүрт миллион 120 мең тонна җыеп алырга ниятләгән иде. Димәк, килограммын 10 сумнан исәпләсәк тә, өч миллиард сумнан артык акча югалттык булып чыга. Ләкин шунысы да бар: игенчелек тармагына былтыргыдан да күбрәк акча кертелгән иде.

АШЛЫК БӘЯЛӘРЕ ҺӘМ САТУ БАЗАРЛАРЫ ТУРЫНДА

– Ашлыкның сатып алу бәясе түбән булуы – авыр тема. Аның үзкыйммәте базардагы бәяләргә караганда югарырак булса, нишләргә?

– Без һәрвакыт игенчеләргә ашлыкны тиз генә сатмаска, мөмкинлек булганда, бераз тотып торырга киңәш итәбез. Башка еллар тәҗрибәсе күрсәткәнчә, урып-җыю чорында, ул тәмамланган гына вакытта бәяләр түбән була, аннары гадәттә алар үсә төшә. Үзкыйммәт тә даими зурлык түгел, аны киметергә омтылу зарур. Сүз уңаеннан, быел республикада ашлыкның үзкыйммәте тоннасына 10,7 мең сум чамасы тәшкил итте, былтыр бу сан 10,9 мең иде. Исегезгә төшерәм, Россия Хөкүмәте җитештерүчеләргә чыгымнарны каплауга субсидияне сатылган ашлык хисабыннан бирә. Былтыр, мәсәлән, Татарстан игенчеләренә 762,65 мең тонна сатылган ашлык өчен федераль бюджеттан 981,96 миллион сум түләнгән иде. Быел инде 363,05 мең тонна сатылган ашлык субсидияләнгән. Дәүләт интервенция фонды турында да онытмагыз. Быел аңа уртачадан кыйбатрак хакка 56,77 мең тонна ашлык сатып алынган.

– Аңлавымча, дәүләт ашлык җитештерүгә киткән чыгымнарны капласын өчен, аны башта сатарга кирәк. Алучылар күпме соң?

– Татарстан предприятиеләреннән бу көнгә (сентябрь ахырына – ред. иск.) илнең төрле төбәкләренә 375 мең тоннага якын ашлык җибәрелгән. Тагын 64,4 мең тонна бөртекле ашлык экспортка киткән. Болар – арпа, бодай, кукуруз. Татарстан ашлыгын, аерым алганда, Кытай, Һиндстан, Иран һәм Таможня берлеге илләре сатып ала. Күптән түгел билгеле бер компания чит илгә

ашлык төялгән 43 вагон җибәрде – 2024 елгы өч мең тонна бодайны Новороссийск порты аша Төркиягә алып баралар. Моннан тыш, август уртасында Казаннан тимер юл белән Кытайга 76 контейнер бодай озатылды. 1,9 мең тонна ашлык тизләтелгән состав белән китте, өстәвенә беренче тапкыр – лайнер-бэгларда (контейнерларга махсус өстәлмәләр). Элек бу максатлар өчен ашлык вагоннары гына кулланыла иде. Татарстан Рәисе Дәүләт Советына Юлламасында билгеләп үткәнчә, республика халыкара сәүдә оештырырлык дәрәҗәдә Идел буеның ашлык хабына әйләнсен өчен, барлык шартлар да тудырылган. Бу юнәлештә күп кенә колачлы проектлар гамәлгә ашырыла.

БАЗАРГА ҖАЙЛАШУ ҺӘМ «ИКЕНЧЕ ИКМӘК» ТУРЫНДА

– Шулай да, базарда ашлык артык күп булса, иген үстерүнең мәгънәсе бармы?

– Әгәр сез чәчүлек мәйданнары структурасына карасагыз, быел аның үзгәрүен күрерсез. Күп хуҗалыклар, ашлык базарындагы вазгыятьне аек акыл белән бәяләп, югары керемле культураларны күбрәк игәргә кереште. Бөртекле культуралар 145 мең гектарга кимеде, үз чиратында рапс, көнбагыш, соя, майлы җитен, шикәр чөгендере һәм азык культуралары өчен күбрәк мәйдан бирделәр. Сүз уңаеннан, майлы культураларның уңышы начар түгел. Якынча 650 мең тонна җыеп алу көздә тотыла, бер ел элек бу сан 488 мең тонна иде. Мәсәлән, рапс уңышы гектарыннан 20 центнер чамасы тәшкил итә, былтыр ул 12 центнерга якын булды. Быел һәр гектардан 440 центнер шикәр чөгендере алалар – бу былтыргыга караганда 100 центнерга күбрәк. Чөгендернең тулаем җыемы ике миллион тоннадан артып китәр, дип фаразлана. Республиканың шикәр заводларында 240 мең тонна шикәр җитештереләчәк.

– Ә «икенче икмәк» белән эш ничегрәк тора? Җитәчәкме?

– Халкыбызга 360 мең тонна бәрәңге кирәк. Шәхси бакчаларны да исәпкә алып санаганда, хуҗалыклар ике тапкырга күбрәк – 800 мең тоннага якын бәрәңге җыеп алырга тиеш. Бәрәңге уңышы – гектарыннан 343 центнерны тәшкил итә. 210 мең тоннага якын яшелчә, моңа әле ябык грунтта үстерелгәннәр дә өстәлә. Бу безгә кирәкле күләмнең яртысы чамасы. Калганы исә башка төбәкләрдән кирәк кадәр китереләчәк.

– Үсемлекчелек тармагында нинди эре проектлар тормышка ашырыла?

– Октябрьдә Яшел Үзән районында 122 мең тоннага кадәр бөртекле һәм майлы культуралар сакларга сәләтле элеваторны тулысынча файдалануга тапшыру планлаштырыла. Бу проектка инвестицияләр 2,7 миллиард сум тәшкил итә. 2026 елда Бөгелмә районында килү-китү юллары көйләнгән шундый ук комплексны аякка бастыру каралган – монда инвестицияләрнең гомуми күләме 3,7 миллиардка җитә. Ниһаять, тагын бер колачлы проект – Лаеш районының Нармонка авылында яшелчәләрне кабул итү, саклау, өстәмә эшкәртү, тутыру-төрү һәм төяп җибәрү өчен сыйдырышлылыгы 43 800 тонна булган комплекс. Бүгенгә монда продукцияне кабул итү һәм төяп җибәрү цехы һәм дүрт мең тоннага исәпләнгән складлар төзелеше тәмамланган, технологик җайланмалар көйләнгән. Ел ахырына кадәр 4,5 мең тонналык бәрәңге саклау урынын кулланышка тапшыру көздә тотыла.

– ХАЛКЫБЫЗГА 360 МЕҢ ТОННА БӘРӘҢГЕ КИРӘК. ШӘХСИ БАКЧАЛАРНЫ ДА ИСӘПКӘ АЛЫП САНАГАНДА, ХУҖАЛЫКЛАР ИКЕ ТАПКЫРГА КҮБРӘК – 800 МЕҢ ТОННАГА ЯКЫН БӘРӘҢГЕ ҖЫЕП АЛЫРГА ТИЕШ. БӘРӘҢГЕ УҢЫШЫ – ГЕКТАРЫННАН 343 ЦЕНТНЕРНЫ ТӘШКИЛ ИТӘ. 210 МЕҢ ТОННАГА ЯКЫН ЯШЕЛЧӘ, МОҢА ӘЛЕ ЯБЫК ГРУНТТА ҮСТЕРЕЛГӘННӘР ДӘ ӨСТӘЛӘ. БУ БЕЗГӘ КИРӘКЛЕ КҮЛӘМНЕҢ ЯРТЫСЫ ЧАМАСЫ. КАЛГАНЫ ИСӘ БАШКА ТӨБӘКЛӘРДӘН КИРӘК КАДӘР КИТЕРЕЛӘЧӘК.

СӨТ ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ СТИМУЛЛАР ТУРЫНДА

– Былтыр республика Россиядәге барлык сөтнең 6,5 процентын җитештерде. Ә бүген хәлләр ничек?

– Республика сөт җитештерү буенча Россия Федерациясендә беренче баскычта нык басып тора һәм быел тагын да югарырак үрне яуларга – 2 миллион 263 мең тонна сөт савып алырга ниятли. Бу елның 8 аенда барлык категория хуҗалыкларда 1 миллион 537,9 мең тонна сөт җитештерелгән. Узган елның шушы чорына карата үсеш 59,6 мең тонна тәшкил итте.

– Дәүләт терлекчеләргә ничек ярдәм итә?

– Сөт җитештерүне стимуллаштыру һәм сөт терлекчелеген үстерү өчен ярдәмне күздә тоткан ике дәүләт программасы бар. Болар – сатылган һәр килограмм сөт өчен субсидияләр (федераль бюджет белән бергә финанслана) һәм нәселле терлекчелеккә булышлык субсидияләре. Беренче программа буенча авыл хуҗалыгы оешмаларына 2024 елда 1 миллиард 329 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Икенчесенә, нәселле сөт терлекчелегенә булышлык өчен – 743,5 миллион.

– Фермер хуҗалыкларына да ярдәм әләгәме?

– Крестьян-фермер хуҗалыгында бүген Татарстан сөтенең 9 процентка якыны җитештерелә. Фермер хуҗалыклары һәм кооперативлары продукциясе күләменең артуы да төрле ярдәм программалары аша инвестицияләр кертү нәтиҗәсе булып тора. Сүз уңаеннан, бездә кече төр хуҗалыкларга дәүләт ярдәменең 51 юнәлеше гамәлдә.

– Савым сыерларының баш саны кимү, ни кызганыч, илнең күп кенә төбәкләрендә күзәтелә. Татарстанда бу тенденциягә ничек каршы торалар?

– Бездә заманча терлекчелек комплекслары актив төзелә, үрчемне яхшырту өчен бердәм идентификацияләү системасы, терлек көтүе һәм ашату режимы белән идарә итү программалары гамәлгә кертелә, сыерларга оптималь рационны тәэмин итәрлек азык үзәкләре оештырыла. Заманча сөт комплексларын сафка бастыру – сөт җитештерүне ел саен 2–3 процент дәрәҗәсендә арттыру өчен нигез ул. Ниһаять, цифрлаштыру да күп нәрсә бирә. Цифрлы система куллана торган 188 хуҗалыкта барлык савым сыерларының 76 проценты тупланган. Шул ук вакытта монда сөтнең 79 проценты җитештерелә, беренче яртыеллыкта сөт җитештерү күләме 69,8 мең тоннага артты.

Владимир Алин, «АВГУСТ-ПОЛИМЕР»: «БЕЗ ТОВАР САТМЫЙБЫЗ – БЕЗ ФАЙДА САТАБЫЗ»

«Август-Полимер» ЖЧЖ – «Август» компанияләр төркеменең аерым оешмасы, «Алабуга» МИЗ резиденты. 2024 елның маеннан авыл хуҗалыгы өчен полимер продукция җитештерү белән шөгыльләнә – ашлык җиңсәләре һәм плёнка материаллар.

«Август-Алабуга» ЖЧЖ – саннарда һәм фактларда

- Җитештерү куәте – 10 мең тонна полимер материал.
- Проектка инвестицияләр күләме – 2,2 миллиард сум.
- Заводның продукциясе: ашлык җиңсәләре, силос җиңсәләре, силос плёнкалары, теплицалар өчен пленка.

Ашлык җиңсәләре аграрийларга җитештерүнең рентабельлеген арттырырга ярдәм итә, шул рәвешле элеватор хезмәтендә 35% ка кадәр экономияләргә мөмкинлек туа. «Август-Полимер» – биш катламлы җиңсәләрне үзебездә җитештерүче предприятие.

Моңа кадәр илебезгә чит илләрдән китерелә торган эшләнмәләрне «Август-Полимер» май аенда җитештерергә кереште. Беренче продукция – озынлыгы 60 һәм 75 метр булган, биш катламлы плёнкадан эшләнеп, калынлыгы 210 мкм га җиткән ашлык җиңсәләре. Шундый бер данә эшләнмәгә, эшли торган материалының тибына һәм тыгызлыгына бәйле рәвештә, 200–250 тонна ашлык сыя. Заказ буенча 125 метр озынлыктагы җиңсәләрне дә эшләп була. «Август»та җитештерелгән беренче җиңсәләр Россия һәм Казахстандагы заказчыларга инде барып ирешә.

Завод, үзе өчен таныш булмаган технологияне үзләштереп, өр-яңа продукция җитештерүне җайга сала алды. Дөрес, «Август» компаниясенең инде моңа кадәр дә полимерлар белән эш иткәнен беләбез. Канистралар әзерләгәндә зур тәҗрибә һәм белем туплады алар, моннан тыш полимерларның сыйфатын да, чимал белән тәэмин итүчеләрне дә өйрәнделәр. Болар барысы да яңа җитештерүне җайга салганда булышмый калмады, билгеле.

«Август-Полимер» оешмасы биш катламлы ашлык җиңсәләре әзерләү буенча үзебезнең җитештерүче – шуны да онытмыйк. Моңа кадәр аларны безгә чит илдән кертәләр иде. Әлеге төр продукциягә ихтыяҗ зур, ул Россиядә ашлыкны полиэтилен җиңсәләрдә сакларга мөмкинлек бирә. Димәк ки, аграрийлар, элеватор һәм складларга дефицит шартларында, җитештерүнең рентабельлеген дә арттыра ала, элеватор хезмәтендә 35% акчаны да янга калдыра. Полимер җиңсәләрне саклау һәм эксплуатацияләү вакыты, аграрийларның тәҗрибәсенә карaганда, 18 айны тәшкил итә. Продукция түбән тыгызлыктагы полиэтиленның стандарт маркаларыннан ясала, икенче төрле әйткәндә – термопластлардан. Ул, халык хуҗалыгы өлкәсендә кирәкле булган ихтыяҗларны исәптә тотып, икенче кабат эшкәртү өчен дә яраклы.

– «Август-Полимер» җитештергән эшләнмәләр – катламлап дифференцияләнгән модификация белән биш агымлы экструзия методы кулланып җитештерелгән, югары чыдамлыкка ия продукт дип исәпләнә, – дип аңлатты «Август-Полимер» ЖЧЖ генераль директоры Владимир Алин. – Катламнар таркалмый, һәрберсе төрле кушылмалар һәм стабилизаторлар кертеп, шулар белән катнаштырып эшкәртелгән. Соңгылары полиэтиленның чыдамлыгын, сыгылмалылыгын, яктылык үткәрү, УФ-нурланышка һәм температура тирбәлешләренә каршы тору сәләтен көчәйтә. Моннан тыш, продуктның экологик яктан чиста булуы да мөһим роль уйный. Аркылыга һәм буйга таба өзелгәндә, якынча озыная күрсәткече (материалның чыдамлыгы буенча төп күрсәткеч шул) 900%ны тәшкил итә. Бу – иң яхшы Европа аналоглары дәрәҗәсе, ә без әле, алардан аермалы буларак, конкурентлык ягыннан күпкә кулайрак бәяләр белән логистика да тәкъдим итә алабыз.

«Август-Полимер»ның алдагы планнарында полимер продукция линейкасын киңәйтү дә каралган: бу аграрийларның саклау һәм силоска әйләндерү буенча иң алдынгы, заманча технологияләр куллануга йөз тоткан бөтен ихтыяҗларын канәгатьләндерү дә булыр иде. Теплицалар һәм силос өчен каплый торган күп катламлы һәм киң форматлы авыл хуҗалыгы, техник юнәлешле плёнкалар җитештерү оештырылачак.

avgust
с нами расти легче
«Август-Алабуга» ЖЧЖ
423601, Татарстан Республикасы,
Алабуга районы,
Алабуга шәһәре, «Алабуга»
МИЗ территориясе, Ш-2 урамы,
6/5 корпусы, 1 нче офис.
Сату бүлеге телефоны:
+7 (927) 400–74–44

Фото «Август-Алабуга» ЖЧЖ тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

АГРОПРОДУКЦИЯ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕҢ ЫШАНЫЧЛЫ ЮНӘЛЕШЕ

Дмитрий Сивков

«Зерновые линии» компаниясе бөртекле һәм кузаклы культуралар трейдингы, экспорты белән шөгыльләнә. Баштарак алар бу культураларны Омск өлкәсендә сатып ала торган була, әмма, вакыт узу белән, игътибарны Россиянең башка төбәкләренә дә юнәлтә. Предприятиенең бүгенгесе турында генераль директор Серик Кунакбаев белән сөйләшәбез.

– Серик Абаевич, «Зерновые линии» чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә Россиядә үз сегментында иң эре компанияләрнең берсенә әверелде. Сезгә Идел буе төбәге, шул исәптән Татарстан, кай ягы белән кызыклы?

– Идел буе аграрийлары төрледән-төрле авыл хуҗалыгы культуралары җитештерә – әнә шуның белән. Ясмык белән ногыт – без бу культураларны бөтен Россия буйлап сатып алабыз һәм дөньяга таратабыз. Бу культураларның күпчелек өлеше нәкъ менә Идел буе төбәгендә үстерелә.

– Сез дистрибьютер гына түгел, дип уйлыйм, авыл хуҗалыгы базарын формалаштыруга да йогынтыгыз зурдыр...

– Без – сәүдә компаниясе, җайга салынган бизнесыбыз бар. Ләкин базарларга үз ихтыяҗыбыз аша йогынты ясауны максат итеп куймыйбыз. Безнең стратегия – Россия агропродукциясенең тышкы базарларга чыгуын логистик яктан мөмкин булган кадәр яхшырак итеп оештыру.

– Сату күләмнәрегезнең күпме өлеше эчке сатуларга корылган, күпмесе – тышкы сатуларга?

– Эчке базар буенча сатулар барлыгы 10 процентны тәшкил итсә, 90 процент тышкы базарга карый. Безнең компания нигездә Россия өчен традицион булган культуралар белән эш итә: бодай, ясмык, кукуруз. Кызыл һәм яшел ясмык буенча экспорт күләмен арттырырга омтылабыз.

– Соңгы ике ел эчендә халыкара аренада барган хәлләр экспортка ни дәрәҗәдә йогынты ясады?

– Әлбәттә, без хәзер югары дәрәҗәдәге хәрби киеренкелек шартларында эш итәбез, ләкин базар инде ияләште, дияргә була, ул артык «тетрәнми». Экспорт буенча операцияләр, билгеле, катлаулана төште, күпсанлы киртәләр барлыкка килде. Әмма бу киртәләр «Зерновые линии» компаниясен ныгытты гына, без тагын да бердәмрәк эшләргә өйрәндек. Тулаем алганда, предприятиедә авыл хуҗалыгы продукциясе буенча экспорт темплары төшмәде, дип әйтә алабыз.

– Кайсы илләрдә нинди агрокультураларга ихтыяҗ зуррак? Алар, билгеле, аерыладыр?

– Россия бөртекле культураларын илтеп җиткерү урыннарын алсак, география шактый киң: Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Һиндстан, Кыргызстан, Казахстан, Азәрбайҗан, Иран, Кытай... Компания кузаклыларны Һиндстан белән Пакыстанга илтү дәрәҗәсен арттыра хәзер. Нигездә кузаклыларны Кытай белән Африка илләре сатып ала.

Ничек кенә булмасын, «Зерновые линии» авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең агропродукциясен эшкәртүчеләргә кадәр илтеп җиткерү буенча иң ышанычлы юнәлешләрнең берсе булып кала бирә.

«ЗЕРНОВЫЕ ЛИНИИ» – ДАИМИ НИГЕЗГӘ КОРЫЛГАН САТЫП АЛУ УЛ:

- БӨРТЕКЛЕ КУЛЬТУРАЛАРНЫ: бодай, ясмык, кукуруз, солы, арыш
- МАЙЛЫ КУЛЬТУРАЛАРНЫ: көнбагыш, җитен, рапс, сафлор, соя
- КУЗАКЛЫЛАРНЫ: ясмык, ногыт, борчак
- АЕРЫМ КУЛЬТУРАЛАРНЫ: тары, горчица, кориандр
- МАЙЛЫ КУЛЬТУРАЛАРНЫ ЭШКӘРТҮ КАЛДЫКЛАРЫН: үсемлек майлары, шрот
- БӨРТЕКЛЕ КУЛЬТУРАЛАРНЫ ЭШКӘРТҮ КАЛДЫКЛАРЫН: он, көрпә, комбиазык

Сайт: **zl-ltd.com**

Коммерция тәкъдиме алыр өчен сату бүлегенә мөрәҗәгать итәргә:
+7 3812 79 0389

Фото «Зерновые линии» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

СМУ-88

БЕЗНЕҢ БЕЛӘН
БАРЫСЫН ДА ТӨЗЕП БУЛА!

РОССИЯНЕҢ ЫШАНЫЧЛЫ ТӨЗҮЧЕСЕ*

ФАТИР САЙЛАУ –
SMU88.GROUP САЙТЫНДА

*по версии Единого ресурса застройщиков. РЕКЛАМА: ООО «ПРОДВИЖЕНИЕ». ИНН: 1655495557. Представленная информация носит исключительно ознакомительный характер, ни при каких обстоятельствах не является публичной офертой, определяемой положениями статьи 437 ГК РФ. Построенные объекты могут отличаться от представленных 3D-визуализаций, изображений. Все представленные материалы, изображения являются ориентировочными, в них могут быть внесены любые изменения и дополнения. Застройщики: ООО СЗ «ПСК СМУ88», ООО СЗ «СМУ88 Девелопмент», ООО СЗ «СК АЙ КЬЮ ДЕВЕЛОПМЕНТ», ООО СЗ «СМУ 88». Проектные декларации на сайте наш.дом.рф

яратам
торак комплексы



КРЫЛОВКА ПАРК торак комплексы

ВОЗНЕСЕНСКИЙ КВАРТАЛ торак комплексы

АЛЬБЕРТ МӨХӘММӘТШИН: «ШӘҺӘР ҺӘМ КЕШЕЛӘР ЯЗМЫШЫ – БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ»

Алар 41 шәһәр маршрутын һәм 5 сезонлы маршрутны тәэмин итә. Һәр көнне 450 автобус 400 меңнән артык пассажирны йөртә. 1900 кешенең көндәлек көче һәм хезмәте бу, шуларның 760ы – машина йөртүчеләр.

«2 нче ПАТП» МУП Татарстан Республикасында пассажирлар ташый торган иң зур автотранспорт предприятиеләренең берсе. Ул күптән инде ышанычлылык, сыйфат һәм куркынычсызлык ягыннан шәһәр халкының ихтирамын казанды һәм эше югары бәяләнде. 1976 елда үзенә нигез салынган көннән башлап, предприятие шәһәр эчендә пассажирлар ташу белән шөгыльләнә.

КАЯН ҺӘМ НӘРСӘДӘН БАШЛАНА

Предприятие тарихы ПАТ-5 КПБ нан башланып китә. Беренче җитәкчеләре – А.М. Зельцер. 1986 елдан оешма Крылов урамында урнашып эшли башлый. Җитештерү базасының төзелеше киң колачлы һәм шаккаткыч дәрәҗәдә була, халык телендә аны «Гараж-400» дип йөртәләр. Чөнки аңарга 400 берәмлектәге хәрәкәтчән состав сыярга тиеш була. 1997 елда ул «2 нче номерлы Казан коммуналь пассажирлар йөртү автотранспорт предприятиесе» дип үзгәртелә, 2002 елда – Казан шәһәренең «2 нче номерлы пассажирлар ташу автотранспорт предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесенә әверелә.

Тора-бара бай тарихы булган оешма өч эре муниципаль пассажирлар ташу предприятиесен (2006 елда – «3 нче ПАТП» МУП, ә 2022 елда «4 нче ПАТП» МУП) берләштерә. Төрле елларда предприятие белән төрле холык-фигыльле, әмма бердәй көчле һәм нык ихтыярлы шәхесләр идарә итә. Һәркайсы үз эшен энәсеннән җебенә тикле белә. Болар – И.И. Сабитов, Е.А. Балмасов, М.И. Зорюков, А.М. Рамазанов, Р.Я. Фәйзетдинов, А.Г. Галәвов. 2001 елдан 2 нче номерлы пассажирларны йөртү автотранспорт предприятисен А.А. Мөхәммәтшин җитәкли.

ХӘВЕФСЕЗЛЕК ҺӘМ УҢАЙЛЫЛЫК ӨСТЕНЛЕКТӘ

– Шәһәр һәм аның кешеләре язмышын уртаклашып, үзебез дә аның бер өлешенә әвереләдек, – ди Альберт Әхәт улы Мөхәммәтшин. Ул хезмәт юлын гап-гади эксплуатация бүлеге инженеры булып башлап җибәрә. Хәзер инде Альберт Әхәт улы – Казан шәһәре «2 нче ПАТП» МУП генераль директоры гына түгел, ә ТР атказанган транспорт хезмәткәре һәм Россиянең почётлы транспорт хезмәткәре дә.

– Безнең эшебез бөтен шәһәр өчен искиткеч дәрәҗәдә әһәмиятле, – ди Альберт Әхәт улы. – Без бер урында гына тормыйбыз, заман белән бергә үсәбез, камилләшәбез, алдынгы технологияләрне үзләштерәбез, һөнәри яктан мөстәкыйльлегебезне раслыйбыз. Предприятие һәрвакытта да пассажирларның уңайлыгы белән хәвефсез йөри алуын үзенә төп өстенлек итеп куя иде, алга таба да шулай булачак.

Менә инде 35 елдан артык Альберт Әхәт улы бөтен көчен һәм белемен Казан шәһәрен транспорт белән тәэмин итүгә, әлеге тармакны тагын да камилләштерүгә багышлый. Күп елларга сузылган хезмәт дәверендә автотранспорт предприятиеләренең ничек итеп бар куәтенә, файда китереп эшли алуын өйрәнә. Планлаштыру, техник эксплуатация, өзеклекләргә дучар итмичә хезмәтне көйли алу – боларны ул үз тәҗрибәсе аша белә һәм җайга сала ала.

Фотолар «2 нче ПАТП» МУП тарафыннан бирелде, kazantransport.ru сайтыннан. РЕКЛАМА

Альберт Мөхәммәтшин өчен тагын бер өстенлекле эш юнәлеше – техник сәясәт. Ягъни җайланмаларны үз вакытында алыштыра, яңарта белү, модернизацияләү, энергияне саклый торган яңа һәм уңышлы технологияләр кертү.

Транспорт чаралары паркына түбән идәнле, күпсыйдырышлы МАЗ белән НЕФАЗ автобуслары керә, барлыгы – 487 берәмлек. Газ-мотор ягулыгында эшли торган автобуслар паркы 276 берәмлектән гыйбарәт. Бу машиналар барысы да экологияне саклый торган двигательле, алар заманча таләпләргә тулаем туры килә. Предприятиедә үзләрен техник яктан дөрес итеп куллану өчен дә барлык шартлар тудырылган.

– Татарстан Республикасы Рәисе һәм шәһәребез мэры ярдәме белән без 2024 елда автопаркны, ниһаять, яңарттык. 100 данә газ-мотор ягулыгында эшли торган НЕФАЗ автобусларын үзебездә булдыра алдык, – дип сөйли предприятие җитәкчесе.

Җитәкчеләрне һәм предприятие хезмәткәрләрен комплекслы һәм сыйфатлы мәгълүмат белән реаль вакытта, хәзер үк, шушында тәэмин итеп торыр өчен, Альберт Әхәт улы инициативасы белән биредә «Галактика» радионавигация күзәтү системасы кертелгән. Бу система юллардагы хәлне тиз арада бәяләргә, күреп-күзәтеп торырга, транспорт хәрәкәтен куркынычсызрак итәргә булыша.

Бүген Казан транспорт тармагында шактый проблемалар тупланды. Аларны хәл итмичә торып, әлбәттә, алга таба атлап булмый. Беренче чиратта, предприятиеләр һәм гомумән транспорт тармагындагы иң зур бәла – кадрлар кытлыгы. Аеруча машина йөртүчеләр һәм кондукторлар җитми.

Хезмәтнең авыр шартлары, көндәшлеккә ия булмаган эш хакы әлеге һөнәри өлкәдән кадрларның такси хезмәте, йөк ташу, әйберләрне илтеп тапшыру һ.б. кебек чиктәш тармакларга китүенә сәбәп булган. Әлбәттә, бу башка урыннарда эш хакларының югарырак булуы белән аңлатыла. Эшчеләр өчен хезмәт хакы төп кызыктыргыч күрсәткеч санала. Шуңа да «2 нче ПАТП» МУП эш хакларын арттыруга китерә ала торган үтемле ысулларны да эзли, сынап карый.

– Вазгыятьнең җитди икәнлеген истә тотып, – диде Альберт Мөхәммәтшин, – безнең предприятие эшчеләрне персональ рәвештә табуга, туплауга һәм өйрәтүгә зур игътибар бирә. Уку үзәгенә даими рәвештә курсантлар җыябыз, вакансияләр турында ММЧнда, мөмкин булган барлык чыганакларда да мәгълүмат бирелеп бара. Без урта һөнәри белем бирү һәм югары һөнәри белем бирү уку йортлары белән тыгыз элемтәдә торабыз, вакансияләр ярминкәсендә актив катнашабыз, эшкә урнаштыру үзәкләре белән хезмәттәшлек итәбез. Шул исәптән, үзебезнең илдәге генә түгел, ә чит илләрнеке белән дә.

БЕРДӘМЛЕК ҺӘМ КОМАНДА РУХЫ

Предприятие коллективы озак еллар дәвамында тотрыклы эшли. Бернинди авырлыкларга карамастан, биредә үз хезмәткәрләре өчен уңайлы эш шартлары тудырырга омтыла. Предприятиедә актив сәламәт яшәү рәвешенә зур игътибар бирелә. Медицина, стоматология һәм массаж кабинетлары эшләп тора. Хезмәткәрләргә бассейнга абонемент бирелә, тренажёр залларына керү мөмкинлеге бар. Җәйләрен ял базасы эшли. Шифаханәләргә дәваланыр өчен ташламалы билетлар белән бару мөмкинлеге каралган, балалар өчен – җәйге лагерьларга ташламалы юлламалар.

Җитәкчелек предприятиенең җитештерү-техник базасын ныгытуга зур игътибар бирә, хәрәкәтчән составны югары әзерлек халәтендә тота. НЕФАЗ автобусларын карап, хәстәрләп тоту өчен махсус сертификациягә ия сервис үзәге булдырылган.

Предприятиедә машина йөртүчеләргә даими рәвештә белемен арттыру өчен барлык мөмкинлекләр дә каралган: махсус җиһазландырылган бүлмәләр, уку класслары, юл куркынычсызлыгы кагыйдәләре буенча уку әсбаплары.

Предприятиедә эшләүчеләр өчен төп принцип булып озак еллар дәвамында пассажирларны ышанычлы рәвештә, югары сыйфат белән тәэмин итү кала бирә. Шуңа алар хәтта иң авыр елларда да җайлы һәм дөрес идарә итү, коллективның бердәмлеге нәтиҗәсендә, үзләренең хезмәт өлкәсендәге ныклы позицияләрен саклап кала алган.

РӘХМӘТЛЕ БУЛА БЕЛҮ ҺӘМ ЯРДӘМ ИТҮ

Монда ветераннарны кайгырталар. Предприятиедә Ветераннар советы эшли. Җиңү көнендә, Өлкәннәр көнендә, традиция буенча, өстәл әзерләп, предприятиенең 400 ләп элеккеге хезмәткәрен чакыралар. Ветераннар өчен табигатькә чыгу, экскурсияләр дә оештырыла. Биредә үсеп килә торган буын турында да онытмыйлар. Хезмәткәрләрнең балаларына Яңа ел бүләкләре тапшырыла, беренче сыйныфка баручы балаларга – портфельләр. Балаларны яклау һәм Белем көнендә күркәм чаралар оештырыла.

«Безнең хезмәткәрләр бүген махсус операция барган урыннарда ватан алдында үз патриотик бурычын үти. Эшчеләребезгә һәм махсус операциядә катнашучыларга ярдәм йөзеннән, актив рәвештә гуманитар акцияләр оештырабыз яки аларда катнашабыз. Хәрби хезмәт үтәүчеләргә йөкләрне илтеп тапшырырга булышабыз», – дип басым ясыйлар оешмада.

Предприятие – күпсанлы республика һәм россиякүләм бәйгеләр җиңүчесе, һөнәри осталык өчен дипломнар, рәхмәт хатлары белән даими бүләкләнеп тора алар. Мисал өчен, «Золотая колесница» Бөтенроссия бәйгесендә «Россия җәмәгатьчелек пассажир транспорты лидерлары» номинациясендә җиңү. «2 нче ПАТП» МУПнең беренчел профсоюз оешмасы да Россия күләмендә иң яхшылардан берсе буларак танылган.

– Барлык коллегаларымны һәм шушы тармакта эшләгән ветераннарны һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйм! Чын күңелдән сезгә нык сәламәтлек, күңел көрлеге, һөнәри өлкәдә яңаданяңа казанышлар, игелек һәм гаилә иминлеге телим! Сукмагыгыз иң мөһим тормыш максатына илтсен, сезгә һәрчак уңыш һәм бәхет юлдаш булсын!

Альберт Мөхәммәтшин,
«2 нче ПАТП» МУП генераль директоры

«БУРЕВЕСТНИК»: ЫШАНЫЧЛЫЛЫК, СЫЙФАТ, УҢАЙЛЫЛЫК

150 уңайлы автобус, микроавтобус һәм җиңел автомобиль, 250 югары квалификацияле хезмәткәр һәм Татарстан Республикасының әйдәп баручы транспорт компанияләренең берсе дигән исем. Сүзебез – «Буревестник» ЖЧЖ турында. Предприятиенең пассажирлар ташу буенча хезмәт базарындагы дәрәҗәсе бирәүдә дә шик уятмый.

Төгәллек, ышанычлылык һәм уңайлылык – компанияне күпсанлы заказчылар әнә шуңа югары бәяли һәм сайлый. Автобуслар һәм автомобильләр паркы, йөртүчеләрнең профессиональлеге, осталыгы ягыннан «Буревестник» иң таләпчән клиентларны да канәгатьләндерә ала.

Ә иң башында, әле аякка гына басып килгән чорында, ягъни 20 ел элек, «Буревестник» ЖЧЖ барысын да нульдән башлый: инде кулланылышта булган ике автобус белән биш кешелек штат. Хәзер исә бу – зур транспорт компаниясе, ә хезмәт күрсәтүенең сыйфатын нинди заказчылар белән эш итүе билгели. «Буревестник»ка гадәттә шәһәр белән республика масштабындагы гына түгел, ә федераль, дөнья күләмендәге чараларны тәэмин итү бурычы да йөкләнә. Күрсәткән хезмәтләре, министрлыкларга, ведомстволарга транспорт ягыннан ярдәме өчен, Вячеслав Улитин җитәкләгән «Буревестник» ЖЧЖ дәүләт органнары тарафыннан күп мәртәбә дипломнар, рәхмәт хатлары белән бүләкләнде.

«Буревестник»ның бай хезмәт исемлегендә – 2013 елда Казанда узган Халыкара җәйге Универсиада, Сочида узган XXII Кышкы Олимпия уеннары һәм XI Паралимпия уеннары, 2015 елдагы Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты. 2017 елда «Буревестник» ЖЧЖ FIFA

Фото «Буревестник» ЖЧЖнән алынды. РЕКЛАМА

Конфедерацияләр кубогын транспорт белән тәэмин итә, 2018 елда – футбол буенча дөнья чемпионатын, ә 2019 елда – Worldskills стандартлары буенча һөнәри осталык дөнья чемпионатын һ.б. күпсанлы бәйгеләрне. Күптән түгел генә булып узган халыкара вакыйгаларның берсе – БРИКС илләре Уеннары һәм Киләчәк Уеннары. Барлык чараларда да транспорт белән тәэмин ителеш – югары дәрәҗәдә.

Нульдән булдырылган «Буревестник» ҖЧҖ бүгенге көндә бик куәтле җитештерү-техник базага һәм заманча технологик җиһазланышка ия. Автопарк үзләренең ремонт цехларында тәэмин ителә, территориядә юа торган комплекс урнашкан, калай-ябыштыру һәм буяу цехлары да – үзләрендә. Автобусны парктан чыгарырга әзерләү, юл кәгазе алудан башлап транспортны стоянкага куюга кадәр – барлык технологик чылбыр автомат рәвештә идарә ителә. Диспетчерлар, механиклар, эксплуатация һәм финанс хезмәтен, шулай ук хәрәкәт итү составын карауны, ремонтлауны бердәм программа аша көйләү-җайлау вакытны экономияләп кенә калмый, бәлки дөрес эшләү системасын булдыруга да мөмкинлек бирә. Барлык транспорт чаралары да машина йөртүчеләрнең эш вакытын терки торган система (тахографлар) белән тәэмин ителгән, шулай ук – видеорегистраторлар, ГЛОНАСС навигация системалары, салон эчендәге камералар белән дә. Куелган җиһазлар һәм җайланмалар транспорт чарасының кайда икәнен онлайн-режимда күреп торырга мөмкинлек бирә.

Әлбәттә, 20 ел дәвамында уңышлар, казанышлар гына түгел, ә авырлыклар да булмый түгел. COVID-19 вирусы таралган һәм чикләүләр кертелгән елларда «Буревестник» ҖЧҖ эшчәнлеген туктатып торырга мәҗбүр була: йөртүләр рөхсәт ителми, автобуслар автопаркта тора, эшчеләрнең эш урыннарын һәм гомумән предприятиене саклап калу өчен, хәрәкәт итү составының бер өлешен сатарга туры килә.

Шуңа да карамастан, эш потенциалы сакланып кала, бу авыр вакытлардан компания тагын да ныгып чыга. Предприятиенең 20 еллыгына менә дигән күрсәткечләр белән керә алар. Алга таба да «Буревестник» ҖЧҖ ватандашларыбыз белән кунакларны җайга салынган һәм югары сыйфатлы эше белән сөендереп торыр, дип ышанып калабыз.

«Буревестник» транспорт компаниясе 2004 елның 4 ноябрендә гамәлгә куела. Төп эшчәнлеге – заказ буенча пассажирлар һәм йөк ташу. «Буревестник» ҖЧҖ оештыручы һәм гамәлгә куючы – **Вячеслав Улитин**.

«КАМСКАЯ МЕХАНИКА»: СЕЗНЕҢ МОТОР ЫШАНЫЧЛЫ КУЛЛАРДА

Дмитрий Сивков

Казандагы мотор-техник үзәгенә һәр төрдәге техниканың «йөрәген» ышанып тапшырырга була. Монда аларны мотоциклдан башлап, бульдозерныкына кадәр төзәтәләр.

– Руслан Маратович, быел Яр Чаллыдагы төп предприятиегә 20 ел тулган. Ә сез кайсы датаны билгеләп үттегез? – «Камская механика – Казань» мотор-техника үзәгенең филиалын җитәкләгән Руслан Садри улы белән әңгәмәбез әнә шундый сораудан башланып китте.

– Тулы көчебезгә әле бер генә ел эшлибез. Шулай да җиңел автомобильләр, коммерция, йөк һәм авыл хуҗалыгы техникаларындагы эчке янулы теләсә кайсы двигательләрнең детальләрен торгызу һәм механик эшкәртү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең тулы спектрын диярлек без инде колачлап алдык. Бүген бездә 16 хезмәткәр эшли. Җиһазларга килсәк, төзекләндерү эшләрен үзебезнең илдә җитештерелгән җиһазларда башкарабыз. Шулай ук АКШ, Италия, Һиндстан һәм Төркиядә җитештерелгән станокларыбыз да бар.

– Казанда да филиал ачу ник кирәк булды?

– Двигательләрне торгызу белән шөгыльләнүче предприятиеләр аз. Һәм төзәтергә кирәкле агрегатларны Чаллыга бер Идел буеннан гына түгел, Көньяк федераль округтан да китерәләр. Күп кенә детальләр транспорт компанияләре белән дә килә, Чечнядан башлап, Якутия һәм Владивостоктан ук җибәрәләр. Менә шуның өчен дә компания җитәкчелеге Казанда филиал ачу карарын кабул итте. Безнең сервис Ульяновск өлкәсе, Чувашия, Мари Эл кебек якын регионнардагы һәм хәтта үзебезнең Татарстандагы Арча районыннан булган клиентларыбызга да уңайлырак булсын өчен шулай эшләнде.

– Сез күрсәткән хезмәтләр төп предприятиедә күрсәтелгәннәре белән тәңгәлме?

– Әйе, без эчке янулы двигательләрнең детальләрен механик эшкәртүдән тыш, аларга капиталь ремонт та ясыйбыз. Ул нәрсәсе белән файдалымы? Безгә моторны сүтелмәгән килеш китерәләр, ә без аны башыннан ахырына кадәр тулысынча карыйбыз: юдырабыз, дефектларын ачыклыйбыз, аннары цилиндрлар блогын – махсуслаштырылган бер цехка, коленвалны – икенчесенә, цилиндр башын өченчесенә җибәрәбез. Торгызу эшләреннән соң мотор цехында двигательне кабаттан җыялар һәм эшләтеп-сынап карау стендына җибәрәләр.

Барлык эшләр дә үзебездә эшләнә. Ә бит еш кына ничек була: ниндидер бер операцияне башкалардан эшләтәләр дә, ватылган очракта гаепләне таба да алмыйлар. Ә без ярты елга гарантия бирәбез.

– «Торгызу эшләре» дигән сүз яңгырап үтте...

– Әйе, соңгы вакытта аның роле артты. Бездә, шул исәптән авыл хуҗалыгында да Европада җитештерелгән техника күп кулланыла. Ә аларга запас частьлар хәзер кыйммәт, аларны табуы да кыен, оригиналлары юк дип әйтерлек. Шуңа күрә дә детальләрне алмаштырырга түгел, ә булганын торгызырга тырышабыз. Чәчү һәм урып-җыю вакытында авыл хуҗалыгы техникаларын чиратсыз гына рәтлибез, чөнки игенчеләр өчен бу чорда һәр көннең кадерле булуын барыбыз да аңлый. Юл хезмәте техникасына да кагыла бу. Шунысын аерып әйтсәсем килә: без, социаль юнәлештә эшләүчеләр, Татарстан Республикасы алдында торган бурычларның мөһимлеген аңлыйбыз.

– Төп предприятиегә караганда, филиалның мөмкинлекләре чикледер?

– Торгызу эше авыр булган очракта, әйтик: турбокомпрессорлар, рульнең гидрокөчәйткечен, кардан, распредвалларны төзәтү, терсәкле валны торгызу өчен без Чаллыга җибәрәбез. Клиентлар өчен логистика бушлай.

– Сезнең клиентларыгыз фәкать авыр йөк машиналары һәм авыл хуҗалыгы транспорты хуҗалары гынамы?

– Юк, без җиңел техниканың цилиндр башларын да төзәтәбез. Моның өчен кирәкле барлык җиһазлар да бар. Дүрт хезмәткәребез шушы юнәлештә эшли.

– Сез төзәтә торган техника линейкасын ничек тасвирларга була?

– Мотоциклдан башлап, бульдозерга кадәр. Мөрәҗәгать итегез.

Фото «Камская механика – Казань» мотор-техника үзәге тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр /

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Инженерлар республикасын» **ничек** төзергә

Киләчәккә ишекне **ничек** ачарга

Тылсымлы фән дөньясына **ничек** элəгергә

Сиксәндә **ничек** форманы сакларга

КЕЧКЕНӘ КАЛАЛАРДАН –

ЗУР КИЛӘЧӘККӘ

Фото: Кадыбаш УББМ, mon.tatarstan.ru. РЕКЛАМА

«Инженерлар республикасы» проекты технологик белем алуга юл ачып кына калмый, аннан мөмкин кадәр күбрәк файда алырга да өйрәтә.

«Чынга ашкан хыял», «Тормыш этабы», «Фикерләү мантыйгы», «Технологик алгарыш» – җөмһүриятебездәге «Инженерлар республикасы»на керә торган мәктәпләр директорлары проектны һәркайсы үзенчә тасвирлый. Әмма бер сүз һәр гыйбарәдә диярлек очрый, һәм бу сүз – мөмкинлек. «Инженерлар республикасы» моннан җиде ел элек зур шәһәрләрдә яшәүче балалар белән беррәттән Татарстан районнары мәктәп укучыларына да инновацияле һәм ихтыяҗ зур булган күнекмәләр үзләштерү мөмкинлеген бирү максатыннан башланган да иде.

Инженерлык белеменең абруен күтәрү идеясе белән мавыккан авторлар: Казандагы Лицей – инженерлык үзәге җитәкчеләре, методист һәм педагоглары, республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, КИТТУ-КАИ мөгаллим һәм галимнәре – техник фәннәр укытучы инглиз телле белгеч-педагоглар тарафыннан урыннарга барып укытыла торган дәресләр системасын төзеде, шулай ук проектка кергән мәктәпләргә инженерлык белеменең нигезен тәшкил иткән дәресләрне үткәрү өчен үз базасын булдырырга ярдәм итте.

Хәзер «Инженерлар республикасы» программалары буенча Татарстанның тугыз муниципаль районы мәктәпләрендә һәм Казандагы дүрт мәктәптә укытыла, аларда укучылар саны исә мең кешедән арта. Башлангыч мәктәп укучыларына роботлар техникасы, инженерлык эше, инглиз теле, хореография, хәтта лингвистик театр дәресләре керә. Урта һәм өлкән сыйныфларда лингвистика һәм иҗат юнәлешләре катлаулана, 3-D модельләштерү, программалаштыру, әйберләр интернеты, математика буенча махсус курс өстәлә. Моның нәтиҗәсендә балалар бүгенгенең һәм киләчәкнең югары технологияле һөнәрләре өчен кирәкле белем нигезләрен үзләштереп кенә калмыйча, үзләрен төрле юнәлешләрдә сынап, үз сәләтләрен эзлекле үстерү, куйган максатларына ирешү мөмкинлеген бирәчәк юлны сайларга өйрәнә. Алар иң катлаулы мәсьәләләрне дә чишә ала, җәмгыять үсешенең нигезен фән һәм технологияләр тәшкил итәчәк дөнья төзү турында хыяллана.

Минзәлия Закирова,
Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары:

– Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, яңа сыйфатлы технологик белем бирүгә һәм проект эшләнмәләренең яңа дәрәҗәсенә нигезләнгән инженер мәктәпләрен үстереп, инженерлык белеме бирүне яңа дәрәҗәгә күтәрү бурычын куйды. Безнең эшебезнең төп юнәлешләреннән берсе – авыл җирлегендә һәм кечкенә шәһәрләрдә мондый мәктәпләр санын арттыру һәм, заманча җиһазлардан файдаланып, мөмкин кадәр күбрәк кешегә сыйфатлы техник белем бирү. «Инженерлар республикасы» проекты әлеге юлдагы уңышка ачык мисал булып тора. Биредә талантлы егеткызлар үз сәләтләрен ача һәм аңлы һөнәри траектория төзи ала. Бу белем бирү генә түгел, бәлки бөтен яктан камил булган һәм киләчәк лидерларына әйләнергә сәләтле шәхесләр формалаштыру да.

Венера Хәйретдинова,
Казандагы Лицей – инженерлык үзәге директоры, «Инженерлар республикасы» проекты авторларыннан берсе:

– Моннан җиде ел элек, проект башланган чакта, мәктәптә өстәмә техник белем бирүне күпләр кирәксез, файдасыз гамәлгә саный иде. Бүген исә бу – заман таләбе. Без инде аны канәгатьләндерә алабыз, әмма технологияләр гел камилләшә бара, димәк, «Инженерлар республикасы» да үсешен дәвам итәчәк. Бүген технологик белем бирү – үткән һәм киләчәк, мәктәп, югары уку йорты һәм предприятиеләр арасында, мәктәп, укучылар һәм ата-аналар арасындагы күпкырлы арадашчы ул. Без әлеге бәйләнешнең ныгуын, ә белемле, фикерле, зирәк «инженериклар» бергәлегенең үсүен телибез. «Инженерлар республикасы» проектында катнашучыларның барысы өчен дә уртак казанышлар – әлеге максатка ирешү өчен ышанычлы нигез. Ә проектның төп этәргече – Илсур Гәрәй улы Һадиуллин җитәкләгән Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы. Хөрмәтле Илсур Гәрәевич, бөтен «Инженерлар республикасы» проекты исеменнән гаять зур ярдәмегез өчен рәхмәтемне җиткерәм һәм юбилеегыз белән тәбрик итәм! Сезгә бетмәс-төкәнмәс энергия, уңышлар, яңа казанышлар телим!

ИЛСУР ҺАДИУЛЛИН: «МИН ГОМЕРЕМ БУЕ БАШКАЛАРДАН ӨЙРӘНӘМ»

Фото: Алсу Шакирова

Евгения Чеснокова

2024/25 уку елы республика педагогларына нинди яңалыклар алып килгән, ТР мәгариф системасыннан нинди алгарыш көтәләр һәм Татарстанның баш педагогы балалардан нәрсәгә өйрәнә?..

Болар һәм тагын бик күп башка нәрсәләр турында без ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Һадиуллин белән сөйләштек.

МАКСАТЫБЫЗ – АЛГАРЫШ

– Илсур Гәрәевич, мәгариф иң консерватив системалардан санала, тик шулай да һәр уку елы ниндидер яңалыклар алып килә. Быелгысы нәрсә белән аерылып тора?

– Татарстанда мәгарифкә шундый зур игътибар бирелүгә һәм безнең инфраструктурабызның ел саен яңартылуына мин бик сөенәм. Быел, мәсәлән, унбер яңа мәктәп һәм ун балалар бакчасы файдалануга тапшырылды.

Яңа дәресләр – хезмәт (технология), ватанны саклау һәм иминлек нигезләре пәйда булды. Әлбәттә, алар буш урында барлыкка килмәде, безнең инде хезмәт дәресләре дә, тормыш иминлеге нигезләре дә бар иде, әмма, аларның эчтәлеге яңартылгач, без укытучыларга квалификацияләрен күтәрү мөмкинлеген бирдек һәм яңа методик әсбаплар белән тәэмин иттек.

Мәктәпләрдә тәрбия эше куәтләнә, һәм былтыргы яңалыклар – мөһим нәрсәләр турында сөйләшү, гаилә нигезләре курсы – дәвам иттерелә. Биредә мәктәпкәчә тәрбия турында да әйтеп үтәргә кирәктер, дип уйлыйм. Мәсәлән, бездә инде 160 балалар бакчасы «Беренчеләр хәрәкәте»ндә катнаша.

Без хәзер тагын бер зур яңа проект белән шөгыльләнәбез – ул «Физика-математика алгарышы» дип атала. Республика укытучыларының август киңәшмәсендә чыгыш ясаганда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов хәзер безгә квалификацияле инженер кадрларның бик тә кирәк булуына тукталды. Шунлыктан мәктәпләрдә физика, математика укытуга күбрәк игътибар бирәчәкбез. Безнең икътисадыбыз өчен инженерлар әзерләү нәкъ менә шуннан башлана бит. Математика һәм физиканы тирәнтен өйрәтү сыйныфлары, өстәмә белем бирү системасында инженерлар түгәрәкләре ачу планлаштырыла. Түгәрәкләрне алып баручы укытучыларга финанс ярдәме күрсәтәчәкбез.

Бу проектта безнең белән бергә Иннополис Университетының да эшләвенә бик шатмын. Аның ректоры Александр Гасников – үзе дә математик һәм илдә математикадан белем бирү сыйфатын яхшырту өчен армый-талмый эшләргә әзер.

Билгеле инде, бер ел эчендә генә без әллә ни алга китә алмабыз, әмма шундый алгарышка омтылырга кирәк.

– Әлеге процесста Иннополис Университетының роле нидән гыйбарәт?

– Алар педагоглар белән эшли, дәрес һәм түгәрәкләрне ничек кызыклы итеп үткәрергә өйрәтә. Балаларның өстәмә дәресләрдән кайтып китәсе килмәслек итеп. Әле балаларның яшен дә исәпкә алырга кирәк: төгәл фәннәрне бишенче сыйныф укучылары һәм чыгарылыш сыйныф укучыларына берничек тә бер үк төрле укытып булмый бит.

Моннан тыш, университет педагоглар һәм балалар белән эшкә видеоэлемтә аша илдәге иң яхшы яшь галимнәрне дә җәлеп итә.

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕНӘ ДӘГЪВАЛАР ЮК, ӘММА ПРОФИЛЬГӘ ЯКЫНАЮ КИРӘК

– Әйтегез әле, «Физика-математика алгарышы» проекты – соңгы вакытта безнең мәктәпләрдә бик күп сөйләнелә торган «Инженерлар республикасы»мы инде ул?

– «Физика-математика алгарышы» «Инженерлар республикасы» проектын тулыландырырга тиеш. Сүз барлык мәктәпләрдә дә табигать фәннәре юнәлешен куәтләндерү турында бара. Физика һәм математика – инженерларга кирәк булган төп предметлар бит. Без моны балаларның да, ата-аналарның да аңлавын телибез. Чөнки әлегә без укучыларның БДИ һәм ТДИ бирү өчен әлеге предметларны сайларга яратмавын яхшы беләбез. Хәзер хәтта югары уку йортына физика укытучысына укырга керү өчен дә физикадан имтихан бирү таләп ителми, җәмгыять белеме дә җитә. Безнең җәмгыять белеменә дәгъваларыбыз юк, әмма шулай да булачак педагогларга профиль предметларыннан имтихан бирергә кирәктер – бу хәзер федераль Фән һәм югары белем бирү министрлыгы дәрәҗәсендә актив тикшерелә.

Ә инде «Инженерлар республикасы» проекты бездә 2018 елдан бирле гамәлгә кертелә. Былтыр аңа – унике, быел инде унбиш мәктәп керә. Һәм бу Казанда гына түгел, ә бөтен республика буенча. Проект КИТТУ-КАИ, Яшьләр инновацион иҗаты үзәге ярдәмендә тормышка ашырыла. Мәктәпкә укучыларга белем бирергә югары

техник уку йортлары мөгаллимнәре килә, анда инженер сыйныфлары һәм роботлар техникасы, авиатөзелеш, машина төзелеше, космик инженерия өлкәләрендә төрле проект эшчәнлеге белән шөгыльләнергә мөмкин булган махсус түгәрәкләр эшли.

Аерым алганда, пилотсыз авиация системалары белән эшләү күнекмәләре бирә торган җиһазлар бар. Сүз уңаеннан, быел җәй Көньяк Сахалин шәһәрендә үткән пилотсыз авиация буенча илкүләм ярышларда безнең мәктәп укучылары 120 медаль һәм 17 кубок яулады. Шул медальләрдән 52сен КИТТУ-КАИ базасындагы Казан Инженерлар лицее укучылары алды – Татарстанда алдынгы инженерлык мәктәпләре ачу хәрәкәте нәкъ менә шул уку йортыннан башланган иде. Бүген бездә республиканың әйдәп баручы техник вузлары базасында биш инженерлар мәктәбе эшли.

КАДРЛАР КЫТЛЫГЫ ҺӘМ СТУДЕНТЛАР РЕЗЕРВЫ

– «Физика-математика алгарышы» турында сөйләшүне дәвам итсәк, мондый сорау туа: әлеге алгарышка укытучылар җитешмәү проблемасы аяк чалмасмы? Безнең мәктәпләрдә физика һәм математика укытучылары болай да җитми бит...

– Мондый проблема чыннан да бар, әмма ул төгәл фәннәргә генә кагылмый. Безнең мәктәпләргә филологлар да, башлангыч сыйныф укытучылары да кирәк... Быелгы уку елы башына бездә барлыгы ике меңнән артык педагог җитми иде. Әмма, басым ясап, шуны әйтәсем килә: республикабызда укытучы булмаганга күрә төп предметлар укытылмаган бер генә мәктәп тә юк. Педагогик югары уку йортларының өлкән курс студентларын җәлеп итәбез – хәзер безнең мәктәпләрдә шундый сигез йөзләп кеше исәпләнә. Алар акча да эшли, кирәкле тәҗрибә дә туплый, безнең мәктәпләрне дә коткара. Димәк, моннан һәркемгә файда булып чыга.

Шулай ук кадрлар кытлыгын мәктәптәге укытучыларга сәгатьләр өстәп тә хәл итәбез. Гәрчә бу педагоглар өчен шактый кыен булса да. Безнең мөгаллимнәрнең өчтән бере чамасы бүген бер ярым ставкага эшли.

УКЫТУЧЫ КАЙГЫРТУГА МОХТАҖ

– Укытучы хезмәте беркайчан да җиңел булмады, әмма бүген аларга бигрәк тә кыен сыман, чөнки җәмгыятьтә аларга карата элеккедәй хөрмәт юк...

– Безнең республика җитәкчеләре яхшы аңлый: укытучылар – ярдәмгә мохтаҗ аерым категория ул. Һәм ярдәм итү чаралары күрелә дә. Шулай да педагогларның хезмәт хакын арттыру бер дә комачауламас иде. Йә булмаса, торак сатып алганда процент ставкасы киметелсә... Укытучыларны әхлакый яктан да, матди яктан да кайгырту зарур.

Сүз дә юк, сез хаклы: укытучының абруе җәмгыятьнең тулаем культура дәрәҗәсенә дә бәйле шул. Әгәр без барыбыз да, ата-аналардан башлап һәм, сүз уңаеннан, гаммәви мәгълүмат чараларына кадәр, педагогларга ихтирамыбызны арттырсак, аларның статусы кабат күтәрелер иде. Укытучыларны сакларга кирәк. Ата-аналар шуны аңласын иде: гаилә һәм мәктәпнең уртак тырышлыгы гына нәтиҗә бирә ала, мәктәп ул үз эшләрең белән шөгыльләнгәндә баланы калдыра торган «саклау камерасы» гына түгел...

Сүз уңаеннан, соңгы елларда гаилә, мәктәп һәм җәмгыятькә кагылышлы уңай үзгәрешләр инде башланды кебек.

– Казанда укытучыга һәйкәл куярга җыенганнар иде. Бу кайчан планлаштырыла?

– Киләсе елда булыр, дип уйлыйм. Әлеге проектны башкала мэриясе гамәлгә ашыра, аны Татарстан Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов та хуплады. Хәзер Казансуның һәйкәл куелачак ярында ремонт эшләре башкарыла.

МӘКТӘПКӘ БАРЫГЫЗ – УКЕНМӘССЕЗ!

– Илсур Гәрәевич, октябрьдә сез гомер бәйрәмегезне билгеләп үтәсез. Бу инде ниндидер нәтиҗәләр ясар чак. Кайчандыр педагоглык юлын сайлавыгызга үкенмисезме?

– Юк, бер дә үкенмим. Мин берара икеләнгән идем – табиб булыргамы, әллә укытучымы дип... Әмма әнием юлыннан китәргә булдым. Ул минем беренче укытучым иде, башлангыч сыйныфларда укытты. Инде күптән бакыйлыкка күчсә дә, минем өчен әни үрнәге дә, педагог үрнәге дә булып калды. Аның ничек эшләвен, дәресләргә ничек әзерләнүен күреп үстем. Бөтен гаилә йокларга ята, әнием исә дәфтәр тикшерә, дәрес планнары яза... Өлкән сыйныфларда мин дә аңа дәфтәр тикшерергә булыша идем.

– Димәк, сез балачактан ук укытучылык хезмәтенә тартылгансыз...

– Әйе. Миңа кешеләр белән эшләү, үзем белгәннәрне аларга аңлату ошый. Ә инде нәрсәнедер белмим икән, мин үзем дә өйрәнәм. Гомер буена укырга, өйрәнергә кирәк. Мин, мәсәлән, хәзерге балалардан алар кебек ирекле булырга, үземне иркен тотарга өйрәнәм. Безнең балачакта андый эчке ирек юк иде, без башка идек... Миңа бүгенге балалар белән бик кызык.

Мин үзем белән эшләүчеләрдән дә күп нәрсәгә өйрәндем. Әгәр минем ниндидер уңышларым бар икән, димәк, бу коллегаларымның да уңышы – алар үзләренең акыллы фикерләре белән бүлешә, бәхәсләшә, үзенең хаклыгын дәлилли – һәм миңа да алга барырга ярдәм итә. Мин үз гомеремдә ярдәм иткән, акыллы киңәш биргән һәркемгә бик рәхмәтлемен.

– Бүген укытучылык юлын сайларга шикләнеп торучы яшьләргә хәзерге тәҗрибәгез югарылыгыннан торып нинди киңәш бирер идегез?

– Үзләренә ышансыннар. Балаларны яраталар икән – педагог булу өчен бу иң мөһиме! Әмма бу бердәнбер сыйфат түгел. Үз фәнеңне бик шәп белү дә таләп ителә, чөнки балаларны бик ярата да, белеме тиешле дәрәҗәдә булмаса, ул уңышка ирешмәячәк.

Әмма сез даими укырга һәм камилләшергә әзер икәнсез, мәктәпкә рәхим итегез, үкенмәссез! Укытучы һөнәре беркайчан да юкка чыкмаячак, мөгаллимне бернинди ясалма интеллект та алыштыра алмый, чөнки тере кеше белән аралашу бәһасез байлык ул.

«Татарстан» журналы редакциясе Илсур Гәрәй улы Һадиуллинны 60 яшьлек юбилее белән тәбрик итә һәм аңа сәламәтлек, рух күтәренкелеге, мәгариф тармагында яңадан-яңа казанышларга ирешерлек көч-куәт тели!

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – ул үз тормышымдагы һәм лицей тормышындагы мөһим этап. Тупланган барлык белемнәребез белән күнекмәләребезне җәмгыятькә файдалы булган инициативаны тормышка ашырыр өчен кулланып була торган этап.

Руфина Дәүләтбаева, Казан шәһәре Совет районы Лицей – инженерлык үзәге директоры урынбасары, «Инженерлар республикасы» проектының автордашы

БЕЗ БУ ПРОЕКТНЫ УЙЛАП ТАПТЫК, ЧӨНКИ...

монннан 7 ел элек лицей базасында инженерлык дисциплиналары буенча зур тәҗрибә тупланды. Без шуны аңладык: әлеге программа Татарстандагы башка мәктәпләр белән дә тәҗрибә уртаклашырга мөмкинлек бирә. Шул рәвешле, бергәләп, алдынгы техник юнәлешле белем бирү ысулы республика күләмендә кулланырга яраклы, кызыклы һәм популяр була алырдай шартлар тудырырга кирәштек.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

әлбәттә, иң беренче чиратта, укучыларыбыз. Безнең лицей ул – «Инженерлар республикасы»ның ресурс үзәге. Нәкъ менә бездә алга таба проектта инде ышанычлы рәвештә кулланыла торган методикалар тәүге мәртәбә сынау, апробация уза. Аларны кулланып, тулы бер лицей буынын тәрбияләп чыгардык. Бу чыгарылыш хәзер Россиянең һәм дөньяның һәртөрле мәртәбәле югары уку йортларында белем ала. Безнең укучылар – халыкара, федераль, төбәкара олимпиадаларның җиңүчеләре, рухлары күтәренке, иҗади, алга таба да һөнәри яктан үсәргә әзер булачак белгечләр. Лицейның һәр укучысы – шәхси проект авторы, һәм бу проектлар инновацияле идеяләргә, төрле өлкәләрдә үсешкә йөз тотуга корылган.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

киләчәккә карап, аны бүген һәм шушында тормышка ашыра белү. 10 ел элек кенә робот техникасы, кулланучы белән инглиз телен өйрәнү, Scratchта программалаштыру һ.б. өстәмә белем бирү блогындагы предмет һәм дисциплиналарның кечкенә шәһәрләр һәм авыл мәктәпләрендә укытылуы башка сыймас хәл санала иде, кирәксез дә... Ә бүген бу – тренд, һәм ул иҗтимагый ихтыяҗ, җәмгыятьнең технологик үсеш-алгарышы белән бәйле.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – яхшы, җитди белем бирү һәм аны үзләштерергә өйрәтү. Безнең чыгарылыш укучыларыбыз хәзер Иннополис Университеты, Бауман исем. МДТУ кебек уку йортларына кереп белем ала. Алар әйтүенчә, программага ияләшү һәм үз үсеш тармагын табу җиңел бирелә. Бу «лингво + техно» укыту ысулын куллану, мәктәп программасы предметларын, ИТ һәм технологияләр өлкәсендә өстәмә предметларны сыйфатлы итеп укыту ярдәмендә кырыс күнекмәләрне (hard skills), шулай ук кечкенә сыйныфлардан ук, индивидуаль һәм команда белән проектлар эшләү ярдәмендә йомшак күнекмәләрне (soft skills) параллель рәвештә үстерү нәтиҗәседер, дип уйлыйм.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ ... «Белем гамәлдә кулланылса, көчкә әверелә». (Д. Карнеги)

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

киләчәктә кем генә булсагыз да – әйтик, лингвист, инженер, табиб, мөгаллим һ.б. – «Инженерлар республикасы» программасын үзләштереп, сез барыбер бүгенге заманда кирәкле белгеч булачаксыз!

Фотолар Лицей – инженерлык үзәге архивыннан

«Иртәгәге көн» инженер мәктәпләре анкетасы

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – зур һәм көчле команданың бер өлеше булу, киләчәкне бүген үз кулларың белән төзү мөмкинлеге!

Гөлнара Галиева, Казан шәһәре Совет районының 187 нче Күппрофильле лицее директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...

Казан Инженерлар лицеенда укыткан педагогларның, укучыларның һәм аны тәмамлаучыларның шәп нәтиҗәләрен күрәбез һәм, әлбәттә, «Инженерлар республикасы» проекты ресурс-методика үзәгенең дә. Бу проект бик вакытлы һәм кирәкле. Техник һәм лингвистик юнәлешләрне берләштерә торган профиль алды һәм профильле белем бирү нәтиҗәсендә, инженер сыйныфында укый торган укучыларның тормыш траекториясе бөтенләй башкача корыла.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

Бездә 10 инженер сыйныфы уңышлы эшләп килә, аларга 248 укучы бала йөри! Техник профильле предметларны яхшы үзләштерү нәтиҗәсендә укучылар SCRATCH-программалаштыру республика бәйгесенең даими призёрлары һәм җиңүчеләре булып килә, «Робот KIDS» робот техникасы буенча шәһәр бәйгеләрендә, Робосабантуйда, WeDo робот техникасы буенча Халыкара олимпиадада гел урыннар яулыйлар. Иң өлкән, 8 нче инженер сыйныфларында укучыларның берсе – «Профессионаллар» һөнәри осталык чемпионаты призёры һәм технология буенча бөтенроссия олимпиадасының төбәкара (йомгаклау) этабы җиңүчесе!

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

- көннең беренче һәм икенче яртысында эшли торган командаларның көйләнгән хезмәте;
- инженер сыйныфларының кураторы тарафыннан программаларны тормышка ашыруны методик яктан күзәтеп тору;
- компетенцияле һәм квалификацияле укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары;
- ата-аналар белән социаль партнёрлар өчен ярты еллык белем бирү коучинг программалары;
- инженер сыйныфларында укырга теләүче балаларның күплеге.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – инженерларча фикер йөртүне үстерер һәм укучылардагы инженерлык потенциалын ачар өчен, мөмкин булган барлык шартларны тудыру, балага һөнәри яктан киләчәген уйлап сайларга булышу.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Акыллы булу – шәп!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

инженер мәктәпләрендә уку – абруйлы!

ПРОЕКТТА – 2021 ЕЛДАН

Фото: 187 нче Күппрофильле лицей архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – балаларга көчле якларын, сәләтләрен ачарга ярдәм итү һәм инновацияле карарлар кабул итү аша аларны киләчәкне төзүчеләр, чын иҗатчылар рухында тәрбияләү.

Динә Абдуллина, Казан шәһәре Совет районының 181 нче Күппрофильле лицее директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...

Россия һәрчак үзенең инженерлары белән дан тоткан, ә фән белән математиканы төрле бурычларны һәм проблемаларны чишү өчен куллану – фәнни ачышларга гамәли кулланыш табу дигән сүз ул. Бүгенге тормыш яңа белемнәр белән күнекмәләр таләп итә. Инженер белеме һөнәр сайлауда да гаять киңкырлы мөмкинлекләр ача, моңа хәзерге вакытта профориентация буенча да зур игътибар күзәтелә. «Инженерлар республикасы» балаларга кече яшьтән үк инженер күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә. Без технологик мәдәният булдыруга, башлангыч инженер белемен бирүгә йөз тотып эшлибез, алга таба бу профильле белем алуга нигез булсын, дибез. «Инженерлар республикасы»нда катнашу – белем алучы балаларның гына түгел, ә гомумән җәмгыятьнең киләчәккә атлавы да ул.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

11 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларыбызның югары нәтиҗәләре: 15 бала мәктәпне медаль белән тәмамлады, 2 укучы профильле математика белән рус телен 100 баллга тапшырды. Безнең укучылар фән һәм технологияләр белән бәйле бөтенроссия конкурс-ярышларында, конференцияләрендә уңышлы чыгыш ясый.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

технологик үзгәрешләр чорында бик тә кыйммәтле булган яңа технологияләр. Балалар, теорияне генә өйрәнеп калмыйча, алган белемнәрен гамәлдә дә куллана ала, чөнки алар команда белән бергә проектлар да эшли бит әле. Безнең мөгаллимнәр – үз эшләренең осталары, үз белемнәрен даими камилләштереп тора, укучыларны да барлык этапларда әйдәп, күзәтеп бара. Югары уку йортлары, һәртөрле оешмалар белән хезмәттәшлек – чылбырдагы мөһим буын, ул укучыларга гамәли нигез бирә, алга таба һөнәр сайларга булыша.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – яңа буын инженерлары белән фән белгечләре әзерли торган мультидисциплинар технологияләрне үстерү. Бу «яңалар» гаять катлаулы бурычларны үтәп, җәмгыятьне алга әйдәүгә үзләреннән зур өлеш кертер, дип ышанабыз. Яшьләргә инженер һөнәренең перспективалы булуын җиткерү зарур: атаклы компаниядә шәп карьера ясау гына түгел, ә яхшы акчалар алып, мул тормышта яшәү мөмкинлеге дә. Моңа ачкыч – әлбәттә, төпле инженер белемнәре алу, андый белгечләр өчен зур компанияләр үзара ярыша.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Кеше акылының көченә ышаныч һәм өмет белән алга – киләчәккә!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

без балаларга белем алырга гына түгел, ә яңа технологияләрне үзләштереп, үз проектларын эшләргә дә шартлар тудырабыз. Безнең мәктәп – һәркемгә үз сәләтләрен ачарга һәм матур киләчәккә атларга мөмкинлек бирә торган урын!

ПРОЕКТТА – 2020 ЕЛДАН

Фото 181 нче Күппрофильле лицей архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – үсеш ысулы һәм яңалыкка ишек ачу мөмкинлеге ул.

Айгиз Миңнемуллин, Татарстан Республикасы Балтач районының Балтач гимназиясе директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...
безнең укучылар инженер булырга хыяллана, ә бу проект аларга һөнәр белән танышырга һәм үз көчләрен гамәлдә сынап карарга мөмкинлек бирә.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...
«Инженерлар республикасы» кысаларында алган белем ярдәмендә укучыларның профильле бәйгеләрдә катнашуы, мисал өчен, робот техникасы буенча олимпиадаларда. Мондый бәйгеләрдә катнашу югары уку йортларына укырга кергәндә баллар өсти. Моннан тыш, без тикшеренүләргә, ягъни проект эшләренә дә зур игътибар бирәбез. Балалар теорияне гамәлдә кулланып карый, үз сызымнарын, схемаларын, макетларын, модельләрен ясый.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...
идеяне тормышка ашыру. Бала гамәлдә чынга ашырып була торган бурычка алынып, нәкъ өлкән белгечләр кебек эшли башлаганда, аның үз-үзенә, көченә ышанычы бермә-бер арта. Без балаларны яңа нәрсә уйлап чыгарырга гына өндәп калмыйбыз, ә үз проектларын оста итеп тәкъдим итәргә, башкаларга күрсәтә белергә дә өйрәтәбез. Ягъни безнең заман өчен гаять кирәкле коммуникатив күнекмәләрне дә ныгытабыз.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – мөстәкыйль фәнни-тикшеренү эшләре өчен шартлар тудыру һәм шул рәвешле балаларга беренче булып дөньяны ачучылар халәтен тоеп карарга ярдәм итү. Ә бу тәҗрибә онытылмый...

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Язмышны үз кулларыбыз белән төзибез!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...
монда сез тормышның нинди күпкырлы һәм кызыклы икәнен күрә аласыз! Монда үзең кебек үк уйлый белә торган иптәшләр табарга мөмкин, шулай ук – үз көчеңә һәм уңышыңа ышанырга да!

ПРОЕКТТА – 2018 ЕЛДАН

Фото Балтач гимназиясе архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – үсеш мөмкинлеге! Барыбыз өчен дә: балаларга да, әти-әниләргә дә, педагогларга да. Шулай итеп, без үзебезнең офыкларны уку әсбапларыннан киңрәк итеп ача алабыз. Бу мәктәп кысаларыннан иркенрәк мохиткә чыгып аралашу, яңа кешеләр белән очрашу һәм... яңа перспективалар да!

Елена Гыйльманова, Татарстан Республикасы Биектау районының 1 нче Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...

инженерлык юнәлешендәге белгечләргә ихтыяҗ бик зур, бигрәк тә яңа технологияләр даими кертелгән өлкәләрдә. Биредә профильле белеме һәм белгечлеге булган кешенең дә төп бурычы – нәкъ менә яңа карарларны эшләү һәм гамәлгә кертеп җибәрү. Инженерлык өлкәсенә караган һөнәрләрнең исемлеге гел яңарып тора. Үз юнәлешен эзләгән югары сыйныф укучыларына бу исемлектәге һөнәрләр менә дигән мөмкинлек була ала:

Робот техникы – оча торган аппаратлар, пилотсыз идарә ителә торган автомобильләр, роботлар һ.б. ны проектлаучы һәм җитештерүче белгеч.

Челтәр архитекторы – мәгълүмат системалары архитектурасы белән шөгыльләнүче инженер. Әлеге белгечлеккә зур ихтыяҗ булу бүгенге көндә мәгълүматның зур күләмнәрдә туплануы белән аңлатыла.

Биотехнолог – химия, биология һәм медицина өлкәсендә эш итүче белгеч, аңа бүгенге көндә экология һәм сәламәтлекне саклау юнәлешендә зур өметләр баглана.

Урбанист – киләчәк шәһәрләрен төзүче **архитектор**. Аның төп бурычы – уңайлы һәм имин шәһәр мохитен булдыру.

Визуаль чынбарлык архитекторы – VR -технологияләре тәкъдим иткән чиксез мөмкинлекләрне төрле өлкәләрдә кулланып эш итүче белгеч.

Инженерлык өлкәсенең колачы чиксез, димәк, без инде тагын берничә елдан өр-яңа белгечлекләр белән очрашачакбыз. Алар, әйтерсең, фантастик әсәрләрнең битләреннән сикереп төшеп тора.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

Без эшне ике инженер сыйныфыннан башлап җибәрдек, ә хәзер, биш елдан соң, алар – 12! Башлангыч мәктәп актив тулылана, әти-әниләр «Инженерлар республикасы» проектына кызыксына, аның киләчәк өчен ресурслары зур булуына ышана. Без «Байтик» республика лагере белән актив хезмәттәшлек итәбез, Лицей – инженерлык үзәге мөгаллимнәре белән эшлибез. Үз квалификациябезне дә югары дәрәҗәдә тотарга тырышабыз.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

җылы, уңайлы, өйдәге кебек атмосфера. Тирән белемгә ия булу, гамәли тәҗрибә туплау, һәм, әлбәттә инде, команданың бер йодрык булып эшләве.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – техник базаны ныгыту, балаларга вакыйгалар үзәгендә торырга мөмкинлек бирү, аларга заманча белгечлекләрне, шәһәр балаларыныкы шикелле үк, куллана алырга булышу. Техник белгечлекләргә йөз тоткан профориентация эшен вакытында оештыру.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Илнең киләчәге – безнең кулда!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

безнең мәктәп ул – чын-чынлап укыта һәм өйрәтә торган урын. Без биредә уңышлы, алдынгы карашлы, заманча фикер йөртә торган кешеләр булырга өйрәтәбез!

ПРОЕКТТА – 2019 ЕЛДАН

Фото 1 нче Биектау мәктәбе архивыннан

«Иртәгәге көн» инженер мәктәпләре анкетасы

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – заманча технологияләргә һәм гамәли казанышларга нигезләнгән мәктәп профориентациясенең нәкъ вакытында узуы турындагы хыялның чынга ашуы ул.

Фәнис Нәсруллин, Татарстан Республикасы Биектау районының Бертуган Максудилар исемендәге 5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...

Татарстан зур колачлар һәм адымнар белән үсә, инженер кадрлар бик тә кирәкле була бара. Базарга чын белгечлеккә ия осталар кирәк, ә инженерлар бүген, нәкъ программалаштыручылар кебек үк, һәр эштә кирәкле кешеләр. Бу проектта катнашуыбыз укучыларыбызга киләчәктә үзләрен таба һәм күрсәтә алырдай һөнәрне сайларга булышыр, дип өметләнәбез.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

Әле бер ел элек кенә бездә ике инженер сыйныфы иде, хәзер инде – дүртәү. Укучылар саны 37 дән 67 гә кадәр артты. Балалар проектларны бик мавыгып эшли. Дроннар, робот техникасы, виртуаль чынбарлык – болар барысы да кечкенә сыйныфлардан алып технологияләр дөньясына алып керү өчен менә дигән «ачкычлар».

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

үз эшен һәм укучыларын яратып эшләүче мөгаллимнәр командасы. Без укучылар тулаем инженер дисциплиналарына күмелә алырдай мохит тудырабыз. Ә иң әһәмиятлесе – алар үз эшләренең нәтиҗәсен күрә ала. Без акрынлап проектның матди-техник базасын яхшыртабыз, шулай иткәндә генә дәресләр кызыклы һәм файдалы була. Ата-аналар белән тыгыз элемтәдә торабыз, алар үз балаларының белемнәрен ничек куллана алуын ачык дәресләрдә күрә. Бу, әлбәттә, мәктәпкә ышанычны ныгыта. Хәзер безгә башка мәктәпләрдән дә балаларны китерә башладылар. Бу асылда «Инженерлар республикасы» проекты белән бәйле, чөнки программасында кечкенә сыйныфлардан башлап инглиз телен кулланучы белән өйрәнү дә каралган.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – балаларга һөнәри яктан чын профессиональлеккә юл ачу. Без һәр баланың нинди дә булса юнәлештә үзен табуына йөз тотып эшлибез, проектлау булсынмы ул, программалаштырумы, пилотсыз очкычлар эшләүме, башка темалармы. Безнең бурыч – балаларга белем бирү генә түгел, ә мәктәп эскәмиясеннән үк чын, җитди техник проектларда үзен сынап карарга өндәү.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Бер кеше – бөтен кеше өчен, бөтен кеше – бер кеше өчен, ягъни бергәләп кенә олы максатларга ирешеп була!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

без балалар рәхәтләнеп, яратып укый ала торган мохит булдырдык. Бу аларга киләчәктә бик нык ярдәм итәчәк. «Инженерлар республикасы»нда сез үз һөнәренә чын-чынлап гашыйк мөгаллимнәрне, белем алуга һәм алга баруга кызыксынуы булган укучыларны таба аласыз. Бездә һәр бала белем һәм күнекмәләр алып кына калмый, ә хыялына алып барган сукмакта һәрдаим алга өндәп торуны да тоеп үсә!

Фото 5 нче Биектау мәктәбе архивыннан

ПРОЕКТТА – 2019 ЕЛДАН

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – зур тату гаилә ул!

Руслан Зелинский, Татарстан Республикасы Чистай районы Чистай шәһәренең 2 нче лицее директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...

инженер булу – дәрәҗәле, заманча һәм шәп. Техник белем теләсә кайсы ишекләрне ача, барлык мөмкинлекләрне дә кулланырга ирек бирә. Безнең шәһәрдә Казан авиация институтының (КИТТУ – КАИ) филиалы бар, һәм без алар белән бердәй белем бирү моделе төзергә тырышабыз: балалар бакчасыннан алып, укып чыкканнан соң студентлар эшләргә кала алырлык предприятиегә кадәр. Чистайдагы КАИ филиалында мөмкин кадәр күбрәк студентлар укыса иде, дип тырышабыз, аларның туган шәһәребездә эшләргә калуын телибез.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

Безнең инженер сыйныфлары балалар һәм әти-әниләр арасында зур популярлык казанды. Әгәр безгә элек укырга керергә яшәү урыны буенча гына килә торган булсалар, хәзер – бөтен шәһәрдән. Без КАИ филиалы белән актив хезмәттәшлек алып барабыз, укучыларыбыз Ачык ишекләр көнендә үз проектларын тәкъдим итә. Безнең кунаклар – район оешмалары җитәкчеләре, алар булачак хезмәткәрләрен инде бүген үк күзәтә, барлый.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

бөтен эшләрне үзара ышанычка һәм аңлашуга корып башкаручы тату, бердәм команда. Безгә Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы, КАИ җитәкчелеге, шәһәр оешмалары һәм проектның инициаторы – Казандагы Лицей – инженерлык үзәге бик булыша. Финанс ягыннан мәктәпнең матди-техник базасын ныгытабыз, уку әсбаплары белән робот техникасы буенча җиһазлар сатып алабыз.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – 9 елдан соң хәзерге өченче «И» сыйныфында укый торган барлык 22 укучыбызның да Чистайдагы КАИ филиалына керүе. Әлбәттә, без әле тагын яхшы инженерның дөньяга киң карашлы, күп нәрсәләр белән кызыксынучы кеше булуын да аңлыйбыз. Шуңа да балаларны техник яктан гына түгел, ә лингвистик яктан да, спорт буенча да үстерергә омтылабыз. Аларда рухи-әхлакый сыйфатларны тәрбияләп, патриотизм хисләре сеңдерергә тырышабыз. Мөмкинлекләребез күбрәк булсын өчен, алга таба барлык сыйныфларның да инженер юнәлешенә күчүе хакында хыялланабыз!

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Безне сайлаган заман». Безгә нәкъ менә бүген, шушы заманда яшәү бәхете тиде. Чөнки бүген укырга, уңышка ирешергә һәм төрле өлкәләрдә яңаны тудырырга барлык мөмкинлекләр дә бар!

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

без бу эшне яратабыз һәм яраткан эшебезне эшлибез! «Инженерлар республикасы» – ул инновацияле тиңдәшсез проект, ә безнең анда катнашуыбыз – бергәләп төзи ала торган киләчәккә таба тагын бер адым ул!

ПРОЕКТТА – 2022 ЕЛДАН

Фото: Чистай шәһәренең 2 нче лицее архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – балалар бүгенге заманның иң әһәмиятле сорауларына җавап бирә ала, лингвистик һәм техник күнекмәләрен үстерә торган инновацияле мохит.

Любовь Камалова, ТР Кукмара районы Кукмара шәһәренең А.М. Булатов исем. Күппрофильле лицее директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...
инженерларча фикер йөртүнең һәм балаларны техник юнәлештә тәрбияләүнең кирәклеген тоябыз. Әмма «Инженерлар республикасы» үз эченә бары тик техник юнәлешләрне генә алып калмый. Чит телләр белем алуда һәм карьера буенча үсештә бик күп өстәмә мөмкинлекләр ача, башка мәдәниятләрне тирәнтен аңларга нигез булып тора. «Лингво» белән «техно» симбиозы яшь инженерларга тормышта үз урыннарын табарга, төпләнергә һәм уңышлы, киңкырлы белгечләр булып формалашырга ярдәм итә.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...
Без тәрбияләгән балалар икътисади яктан дәлилләнгән проектлар ясыйлар, аларны керем алыр өчен дә кулланалар. Әйтик, шундый төр проектны икътисади укуларда тәкъдим иттеләр – робот техникасы дәресендә эшләнгән уеннар нигезендә ничек акча эшләп булганын күрсәттеләр. Ә менә җитди экология проблемаларын хәл итүгә юнәлтелгән эшләр укучыларда җәмгыятькә, әйләнә-тирә мохиткә карата җаваплылык тәрбияли. Шундый проектларның берсе «XXI гасыр Кулибиннары» Бөтенроссия олимпиадасының республика этабында 1 нче урынга чыкты.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...
төрлелек. Төрле характерлы һәм төрле планлы белем бирү кейсы. Без «Инженерлар республикасы» химаясендә аны үзебезнең белем бирү программасына кертеп җибәрдек. Ул үз эченә техник, лингвистик, спорт, сәнгати юнәлештәге дисциплиналарны ала. Балаларга берничә түгәрәккә йөрергә кирәк булмый, барысы да үз мәктәбендә оештырыла, хәтта өстәмә туклану да каралган. Әти-әниләр белән еш аралашабыз, алар программаны җайларга, төзәтмәләр кертергә булыша. Шулай итеп, аларның да мәктәпкә, мөгаллимнәргә карата булган ышанычы арта. Укытучыларның кайберләре «Инженерлар республикасы» дисциплиналарын укытырга башка төбәкләрдән килеп йөри.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – «Инженерлар республикасы» проектына үзебезнең төбәктән мөмкин кадәр күбрәк баланы җәлеп итү, аларны үз алларына максат куярга өйрәтү һәм һөнәр сайларга булышу. Без укучыларга дөньяда НӘРСӘ барын күрсәтергә, НИНДИ белемнәрнең кирәклеген ачыкларга, КАЙСЫ белгечлекләргә ихтыяҗ зурлыгын билгеләргә булышабыз, ә аннан соң алар инде үзләре тиешле юнәлешне сайлый. Ахыр чиктә, «Инженерлар республикасы» проекты инженерлар, техник белгечләр һәм укытучылар мөһим роль уйный торган киң төбәкара масштаб алырга тиеш. «Инженерлар республикасы» программасын тәмамлаган укучылар исә югары технологияләрне үстерү һәм инженерлык өлкәләрен тагын да ныгыту нәтиҗәсендә киләчәктә илебезнең тотрыклы икътисади үсешен тәэмин итәр, дип уйлыйбыз.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Киләчәгең хакына инженерия һәм чит телләр дөньясын ач!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...
- техник һәм лингвистик күнекмәләрне үстерү өчен уникаль мөмкинлекләр тәкъдим итәбез;
- безнең программалар темаларның киң спектрын үз эченә ала: робот техникасыннан башлап, экологиягә кадәр;
- проект эшчәнлеген куәтлибез һәм идеяләрне тормышка ашырырга ярдәм итәбез;
- уңайлы, көч һәм илһам бирә торган мохит тудырабыз, монда һәркем үз мөмкинлекләрен ача ала.

ПРОЕКТТА – 2019 ЕЛДАН

Фото: Кукмараның А.М Булатов исемендәге Күппрофильле лицее архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – фән, иҗат һәм перспективаларның тылсымлы дөньясы ул!

Виталий Вегера, Алабуга муниципаль районының Инженер-технология лицее директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...

алгарышка һәм үсешкә йөз тоткан команданың бер өлеше булырга телибез. Биредә һәр бала үсешкә мөмкинлек ала, яңа белемнәр белән күнекмәләр үзләштерә, кызыклы проектларны тормышка ашыра. Шулай ук, үзе кебек фикерле торган яшьтәшләр белән аралаша, остазлык тәҗрибәсенә таяна.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

«Инженерлар республикасы» безнең муниципаль районда көннән-көн популяррак була бара. Бу уку елында без инженер сыйныфларына укырга керергә теләүчеләрдән бик күп гариза алдык, әти-әниләрдән генә түгел, ә безгә беркетелгән районнардан һәм тулаем бөтен шәһәрдән дә. Әле бик яшь булуларына карамастан, безнең балалар – робот техникасы буенча күпсанлы бәйгеләрнең катнашучысы. Алар әти-әниләре һәм лицей алдында бик теләп үзләренең беренче проектларын яклый.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

үз эше белән чын күңелдән мавыккан, димәк ки, балаларны да мавыктырырга сәләтле булган мөгаллимнәр. Белем бирүгә проект аша якын килү балаларны эмпатиягә, хезмәттәшлек итүгә, планлаштыра белүгә, үзлектән генә дә, команда белән дә куелган максатларга ирешә алуга өйрәтә.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – нигездә инженерлык дисциплиналарына һәм фәнгә кызыксыну уяту. Без балаларны алган белемнәрен гамәлдә кулланырга өйрәтәбез, дәресләрдә тәкъдим ителгән мәгълүмат киләчәктә аларга укуда да, карьера төзегәндә дә булышсын, дип тырышабыз. Шул рәвешле дөньяга якты, кешелекле үзгәрешләр кертә алырдай яңа буын инженерларын тәрбияләргә, аларга илһам бирергә өметләнәбез.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Хыяллан! Эшлә! Җиңеп чык! Уңышка иреш!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

монда, җылы һәм уңайлы мохиттә, уникаль белемнәр, күнекмәләр алачаксыз. Алар сезгә югары технологияләр өлкәсендә уңышлы белгечләр булып әверелергә ярдәм итәчәк!

ПРОЕКТТА – 2023 ЕЛДАН

Фото Алабуга районы Инженер-технология лицее архивыннан

«Иртәгәге көн» инженер мәктәпләре анкетасы

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – җәмгыятькә бүген һәм хәзер кирәкле нәрсәләрне тудырырга әзер фикердәшләр командасы хезмәте белән ирешеп була торган ниятләр һәм гамәлләр мантыйгын тәрбияләү.

Надежда Гыйләҗетдинова, Татарстан Республикасы Лаеш районының Комлы Кавал урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ... тарихи яктан шулай килеп чыккан: безнең авыл өчен аны эш белән тәэмин итә торган төп предприятие – «Транснефть Кама алды». Бу – эре сәнәгать холдингы, анда инженерлар бик кирәк. Безнең мәктәп нефтьчеләр белән тыгыз элемтәдә яши һәм эшли. Берничә ел элек алар ярдәмендә математика, химия, биология, физика кабинетлары ремонтланды, аларда лабораторияләр пәйда булды. Теория белән гамәл бәйләнеше бездә – бик күптәннән, ә «Инженерлар республикасы» аны ныгытырга ярдәм итә.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР... Беренче «инженерларыбыз» инде бишенче сыйныфка кадәр үсеп җитте. Алар артыннан дүртенче, өченче, икенче инженер сыйныфлары да өлгереп, үсеп килә. «Инженерларыбыз» күпкә дисциплиналы, җаваплырак булулары белән аерылып тора. Алар өй эшләрен дә бик әйбәт итеп башкара, мәктәпкә килергә дә атлыгып тора. Ата-аналар бу программаны шулай ук югары бәяли, балаларын максатчан рәвештә безгә укырга бирә. Балаларның киләчәктә техник юнәлешләрдә югары белем алып, үз урыннарын табуын телиләр.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ... игътибар һәм укучыларыбызга карата җылы, җаваплы мөнәсәбәт.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – һәрбер «инженерыбыз» мәктәптән белемле кеше булып чыксын, дип телибез. Сүз төгәл фәннәр өлкәсендәге белем турында гына бармый, ә башка юнәлешләр турында да – логик, үзенчәлекле фикер йөртергә өйрәнү, үз максатларыңны анык белү, аларга ничек ирешергә икәнен күзаллау.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Инженер белеме алу – кирәк, әһәмиятле һәм кызыклы!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ... без сезне уңышка илтә торган юлга алып чыгар өчен көтәбез!

ПРОЕКТТА – 2019 ЕЛДАН

Фото Лаеш районының Комлы Кавал урта мәктәбе архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – гимназиябезне үстерү юнәлешендә гаять көчле этәргеч.

Артур Галиәхмәтов, Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Түбән Кама шәһәренең «Адымнар – Түбән Кама» Полилингваль гимназиясе директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...

инженер белемнәрен үстерү – Россия күләмендәге тренд. Һәрбер белем бирү оешмасы илебезнең технологик суверенлыгына үзеннән өлеш кертә ала. «Инженерлар республикасы» проекты аша без укучыларга инженерлык потенциалын формалаштыру өчен мөмкинлек бирәбез. Алар алга таба, биредә алган белемнәргә таянып, икътисадта үзләренә лаек урын табар, дип ышанабыз.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...

«Адымнар – Түбән Кама» – әлеге проектка кергән бердәнбер полилингваль гимназия. Безнең гимназиянең белем бирү концепты «физиклар» белән «лириклар» арасында хезмәттәшлек мәдәниятен үстерүгә корылган. Бу концепциянең иң җете чагылышы – «ФӘН-ФЕСТ» балалар фәнни проектлары традицион фестивале. Монда иң мөһиме – укучылар EduSCRUM («Эдьюскрам») методикасы буенча төркемләп эшли торган проектлар әзерли, бу, үз чиратында, «йомшак» күнекмәләрне (soft skills) яхшыртырга ярдәм итә.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...

үзенчәлекле фикер йөртүче, үз эшенең остасы булган мөгаллимнәр командасы, алар барысы да югары нәтиҗәгә ирешүне максат итеп куя. Безнең эшчәнлек рухи кыйммәтләргә йөз тотып укытуга юнәлтелгән. Дисциплина, үзара ихтирам, әхлаклылык һәм бердәмлек –белем бирү системасы әнә шуларга нигезләнә.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – миссиябезгә турыдан-туры бәйле. Без бөек буын тәрбияләп үстерергә омтылабыз, ул буын дөрес һәм кирәкле кыйммәтләргә таянып тәрбияләнәчәк. Белем бирү программабыз тулы бер төркем Homo faber (латинчадан тәрҗемәдә «тудыручы кеше») формалаштыруны күздә тота. Бу «яңа кешеләр» алга таба тормышны да яхшыга борачак. Һәр яңа туган көнне.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл».

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...

без – балаларының киләчәген кайгырта һәм аларга канат куя белә торган ата-аналарның кызыксынып белем алучы балалары, укучыларга үсеш бүләк итә алырдай мөгаллимнәр эшли торган гимназия. «Инженерлар республикасы» – һәрбер укучының олы киләчәкне күз уңында тоткан юлында уңыш стратегиясе ул!

ПРОЕКТТА – 2022 ЕЛДАН

Фото «Адымнар – Түбән Кама» Полилингваль гимназиясе архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – һәр бала үз потенциалын ачып, чын иҗатчыга әвереләчәк киләчәккә ишек ачу ысулы ул.

Максим Ильясов, Татарстанның Арча районы Арча шәһәренең Г.Курсави исем. Күппрофильле лицее директоры

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, ЧӨНКИ...
технологияләр белән инновацияләрнең киләчәгенә ышанабыз. Хәзерге заман балалары – инде берничә елдан ук дөньяны үзгәртәчәк кешеләр, ә безнең бурыч – аларга төпле нигез бирү. Инженер сыйныфлары тәнкыйди фикерләүне үстерә, техник күнекмәләр белән иҗатка һәвәслекне арттыра. Проект һәр укучыны игътибарын билгеле бер бурычларга юнәлтергә өнди. Без аларны проектларга заман ихтыяҗларына һәм таләпләренә карап җәлеп итәбез. Мондый проектларда катнашу – безнең укучылар өчен алгарышка бер адым ясау ул.

БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК БУЛГАН КАЗАНЫШЛАР...
10 нчы сыйныфта махсуслашкан инженер профильләре булдыру, анда укучылар тирәнтен рәвештә математика, физика, информатика өйрәнәләр, илебезнең әйдәп баручы техник юнәлешле югары уку йортларына укырга керергә әзерләнәләр. Шулай ук 1 нче инженер сыйныфы белән дә горурланабыз. Балалар биредә профильле предметларны өйрәнүгә уен аша кереп китә. Алар робот техникасы, программалаштыру нигезләрен өйрәнә, логика белән иҗади фикерләүне чарлый. Беренче сыйныф инглиз телен кулланучы белән өйрәнә, бу аларга техник терминнарны үзләштерергә ярдәм итә, глобаль дөнья шартларында үзләрен ышанычлы хис итәргә дә күнектерә.

БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯКЛАРЫБЫЗ – УЛ...
укытуга тирәнтен һәм төрле яклап якын килү, ә бу, үз чиратында, реаль бурычларга һәм сынауларга җавап буларак эшләнә. «Инженерлар республикасы»нда без теория генә өйрәнеп калмыйбыз, балаларга гамәли мәсьәләләрне үзлектән чишәргә дә тәкъдим итәбез. Укытучылар командада эшләү күнекмәләрен ныгытырга тырыша, шулай ук – үзенчәлекле фикерләү белән техник грамоталылыкны да. Без һәртөрле югары уку йортлары һәм оешмалар белән актив хезмәттәшлек итәбез, шул чагында гына безнең укучылар һөнәри мохитнең асылда нинди булуын үз күзләре белән күрә ала.

БЕЗНЕҢ МАКСАТ – проектны уйлап таба һәм конструкцияли генә түгел, ә киләчәкнең катлаулы бурычларын да чишә ала торган яңа буын инженерлары тәрбияләү. Без укучыларыбызның үз өлкәсендә әйдәп баручылар булуын телибез: олимпиадаларда җиңүләрен, инновацияле эшләнмәләр башкаруын. Безнең бурыч – балаларга барлык мөмкин булган белемнәр белән күнекмәләрне бирү, ә инде шуларга нигезләнеп, алар үз хыялларын тормышка ашыра алачак.

БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ... «Киләчәкне бүген төзе!»

БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ, ЧӨНКИ...
биредә балаларга сәләтләрен ачарга һәм чып-чын инженерлар булырга ярдәм итәләр. Без үзеңне үстерү һәм тормышта нәрсәгә дә булса ирешү өчен уникаль мөмкинлекләр тәкъдим итәбез! Монда һәркем олы һәм гаять җаваплы эшнең өлеше булып әверелә ала – иң шәп киләчәкне без әнә шулай бергәләп төзибез!

ПРОЕКТТА – 2024 ЕЛДАН

Фото Арча шәһәренең Г.Курсави исемендәге Күппрофильле лицей архивыннан

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – яңа буынның технологик яктан алга ыргылышы. Без инженерларны үстерәбез, ә инженерлар дөньяны үстерәчәк!

Гөлназ Галиева, Казан шәһәре Совет районының 79 нчы Экология-технология лицее директоры

ПРОЕКТТА – 2024 ЕЛДАН

Фото Казан шәһәренең Экология-технология лицее архивыннан

Лицейда ачылган беренче инженер сыйныфлар югары нәтиҗәләр күрсәтсен һәм башкаларны да инженер белемнәре алырга өндәсен – **БЕЗ ШУҢА ОМТЫЛАБЫЗ**. Укучы балалар төрле компетенцияләрдә югары нәтиҗәләргә ирешсен, профиль буенча һәртөрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда катнашсын, лицеебызның да, республиканың да данын күтәрсен – **БЕЗ ШУҢА ӨМЕТЛӘНӘБЕЗ. БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ**: «Киләчәкне ватан бәрәкәте хакына төзибез!» Техник мөмкинлекләр, мотивация, үз һөнәренең остасы булган кадрлар – болар барысы да илебездә яңа буын перспективалы гражданнарны тәрбияләп үстерү өчен нигез. Үтемле технологик, экологик белем һәм инженер осталыгы алырга әзер булганнарны **БЕЗ КӨТӘБЕЗ**. Булачак һөнәрендә, эшендә үзеннән трендлар кертергә әзерлекле белгечләр чыгарырга **БЕЗ ӘЗЕР**.

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – һөнәри инженер-техник эшчәнлеккә йөз тотучы балаларны барлап, табып алу мөмкинлеге ул.

Аида Халикова, Казан шәһәре Совет районының 174 нче гимназия директоры

ПРОЕКТТА – 2024 ЕЛДАН



Фото Казанның 174 нче гимназиясе архивыннан

Хәзер җәмгыятьтә тамырдан үзгә, яңа төр шәхес тибына йөз тоту формалашып килә: ул алдынгы фикерле, актив тормыш позицияле булырга, әйләнә-тирәдәге катлаулы проблемаларны җиңел генә хәл итәргә тиеш. Шуңа да технологик мәдәниятне үстерер, профильле башлангыч инженер белемнәрне сыйфатлы итеп бирер, алга таба һөнәри белемгә алып чыгар өчен **ШАРТЛАР ТУДЫРАБЫЗ**. Әлеге елның сентябрендә безнең гимназия базасында «Кванториум» мәктәп технопаркы ачылды. Биредә **БЕЗ ӨЙРӘТӘБЕЗ**: инженерлык күнекмәләренә, проект эшләргә, иҗади мәсьәләләрне хәл итү теориясенә, 4К-компетенцияләренә (коммуникация, креативлык, проектларны тормышка ашырганда команда белән эшләү, критик, ягъни тәнкыйди фикер йөртү), остазлар кул астында реаль җитештерү бурычларын үтәргә. **БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ:** «Кеше акылының көченә ышаныч һәм өмет белән алга – киләчәккә!» **БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ:** роботлар, программалаштыру, 3D-модельләштерү, виртуаль һәм өстәлгән чынбарлык, табигый-фәнни лабораторияләр, югары технологияле җиһазлар һәм җайланмалар, чын остазларның һөнәри мәктәбе – бездә яшь хыялыйларга һәм иҗатчыларга кызыклы була алырдай бөтен нәрсә дә бар!

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – киләчәктә инженер-техник эшчәнлек белән шөгыльләнергә теләүче сәләтле балаларны табып, аларны үстерү мөмкинлеге ул.

Фәния Рәшитова, Татарстанның Әгерҗе районы Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры

ПРОЕКТТА – 2024 ЕЛДАН

Фото Кадыбаш урта мәктәбе архивыннан

Технология буенча белем бирүдә, фәнни-техник иҗат юнәлешендә, мәктәп укучыларының тикшеренү потенциалын үстерүдә махсус шартлар тудыра алыр өчен **БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШЫРГА** уйладык. **БЕЗНЕҢ МАКСАТ** – балаларны проект эшләренә өйрәтү, аларга киләчәктә һөнәр сайларга ярдәм итү. «Инженерлар республикасы»ның безгә ярдәме зур: укучыларыбыз математика, физика һәм информатика буенча БДИны яхшы балларга тапшыра, технологияләр буенча даими рәвештә төбәкара бәйгеләрдә призлы урыннар яулый. Остаханәләр, ачык дәресләр – болар бар да яңа буын инженерларын илһамландыра, шуңа аларны даими **УЗДЫРАБЫЗ**. Аларда катнашып, балалар үз проектларын яклый, командада эшләргә өйрәнә. **БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯГЫБЫЗ** – балаларда мәктәп предметларына кызыксыну уяту, алган белемнәрен гамәлдә сынап карарга омтылыш тудыру. **БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ:** монда барысы да кызыклы – алган белемнәр дә, эшләгән проектлар да, үзара аралашу да! **БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ:** «Укы, иҗат ит, уңышка ireш!», белем алу – ул укытучыдан алган мәгълүмат кына түгел, ә хыялларыңны, идеяләреңне чынга ашыру өчен мөмкинлек булуына **ЫШАНАБЫЗ**.

Минем өчен «Инженерлар республикасы» – инженер-техник белем алуны һәм үзләштерүне максат итеп куючы балалар ул.

Илфат Муллануров, Татарстанның Әгерҗе районы Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры

ПРОЕКТТА – 2024 ЕЛДАН

БЕЗ БУ ПРОЕКТТА КАТНАШАБЫЗ, чөнки инженер сыйныфлары – яңа офык, яңа перспективалар дигән сүз, ул укучыларга үсешнең уңышлы юнәлешен күрсәтә. Без олы шәһәрләрдән еракта яшибез, әмма «Инженерлар республикасы» безнең балаларга зур дөньяга тәрәзә ача. Ярты ел эчендә проект бик уңышлы башланып китте һәм дәвам итә. «Инженерларыбыз» үз проектларын яклый, район һәм республика семинарларында, конференцияләрендә катнаша, призлы урыннарга лаек була. **БЕЗНЕҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЯГЫБЫЗ** – уңышка ирешергә омтылучы тату команда. Эшебездә район җитәкчелеге, мәгариф идарәсе һәм, әлбәттә, Казандагы Лицей – инженерлык үзәге **БЕЗГӘ ЯРДӘМ ИТӘ**. Безнең балалар уңышка ирешсен, ә без аларның уңышы белән горурлана алыйк дип **ТЕЛИБЕЗ**. **БЕЗНЕҢ ДЕВИЗ:** «Укучыларыбыз һәрчак алга барсын!» **БЕЗГӘ УКЫРГА КИЛЕГЕЗ**, чөнки бездә укырга кызык, заманча һәм алдынгы белемнәр алып була!

Фото Исәнбай урта мәктәбе архивыннан

«ДИРЕКТОР – БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА ПЕДАГОГ»

Евгения Чеснокова

Халыкара укытучылар көне алдыннан Калугада «Россиянең ел директоры – 2024» конкурсына йомгак ясалды. Абруйлы Бөтенроссия бәйгесенең 30 финалчысы арасында Казанның 179 нчы гимназиясе директоры Эльвира Наумова да бар иде.

«Бу катлаулы һөнәри сынау булды, әмма аны үтү барыннан да бигрәк минем үзем өчен мөһим иде», – дип сөйли ул үзенең яңа тәҗрибәсе турында.

– Эльвира Викторовна, хәзерге заманда Россиядә мәктәп директоры сезнеңчә нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– Бүген директор – педагоглык һәм менеджерлык сыйфатларын берләштергән лидер ул. Әмма беренче чиратта педагог. Ул уку-укыту процессларын яхшы аңлый, педагогик технологияләрне шәп белә, укытучыларны даими һөнәри үсешкә рухландыра, мәктәп культурасының бөтенлеген формалаштыра.

Һәр мәгариф оешмасы – уникаль, ә директор – әлеге тиңдәшсезлекне (кыйммәтләр, принциплар, мәктәпнең миссиясен) чагылдыручы кеше. Шул ук вакытта директорның динамик белем бирү мохитендә үз уку йорты үсеше перспективаларын күрә белүе дә мөһим.

Директор дипломат булырга һәм мәгарифкә социаль партнёрларны җәлеп итә белергә тиеш, чөнки бу балалар өчен яңа мөмкинлекләр ача.



Тагын әле кешеләр белән генә түгел, бәлки академик, финансларга һәм кадрларга кагылышлы, демографик мәгълүматлар белән дә эшли белү зарур... Болардан башка белем бирү процессын нәтиҗәле һәм комплекслы итеп оештырып булмый.

– Яңа уку елында мәктәп тормышында нинди мөһим үзгәрешләр булды?

– Тулаем алганда, үзгәрешләр күп, әмма без аларның йогынтысын әллә ни көчле сизмәгәнбездер, мөгаен, чөнки шактые инде безнең гимназиядә күптән гамәлдә иде. Мәсәлән, без ата-аналар белән күптән килештек – дәресләрдә кесә телефоннарыннан файдаланмыйбыз. Бездә күптәннән үзебезнең матур мәктәп формасы кертелгән. Түгәрәк эше кысаларында гаилә белеме буенча дәресләр үткәрелә иде – хәзер алар һәркем өчен мәҗбүригә әйләнде.

Күпчелек үзгәрешләр тәрбиягә кагыла. Гомум кабул ителгән караш үзгәрә, басым кулланучыдан иҗат итүче, нәрсәдер булдыручы кешегә күчерелә. Без үз төбәгебездәге һәм тулаем илебездәге предприятиеләрнең искиткеч тизлектә үсүен күреп торабыз. Ә менә ил эчендәге барлык кирәкле җитештерүләрне киләчәктә бүгенге мәктәп балаларына көйләргә туры киләчәк. Шуңа күрә без бүген үз көч-куәтен кече һәм олы ватаны өчен сарыф итәргә әзер шәхес формалаштырабыз.

– Россия педагогикасында бүген кадрлар проблемасы иң мөһимнәрдән санала. Сезнеңчә, аны ничек хәл итеп була?

– Бу, чыннан да, көн кадагындагы мәсьәлә. Һәм, минемчә, мәгариф тармагында гына да түгел. Әмма, әлбәттә инде, педагогика өчен кадрлар бигрәк тә мөһим, чөнки без киләчәк буынны тәрбиялибез. Татарстанда яшь педагогларга ярдәм итү ысуллары шактый, әмма шулай да педвуз тәмамлаучыларның барысы да мәктәпкә барырга атлыгып тормый.

Бәлки, бу тәкъдимем бик кыю тоелыр, әмма мин педагогика юнәлешендәге өченче курс студентларының уку планын үзгәртеп, аларны атнасына ике көнгә белем бирү оешмаларына эшкә урнаштырыр идем. Закон моны рөхсәт итә. Бу алар өчен сыйфатлы педагогик практика да булыр, әлеге һөнәрне үзләре теләп сайлаучылар өчен бәһасез тәҗрибәгә дә әйләнер иде.

– Сезнең үз коллегаларыгыз белән уртаклашасыгыз килгән нинди дә булса һөнәри серегез бармы?

– Бу сер түгел, үзем өчен бер кагыйдә сыман. Мин һәрвакытта да мәгарифтәге актуаль вакыйгалар казанында кайнарга омтылам, даими рәвештә яңа белем алырга тырышам, шул исәптән Татарстандагы һәм бөтен Россиядәге коллегаларымнан да гел нәрсәгәдер өйрәнәм.

Тагын бер «сер» үз укытучыларымның бик көчле булуындадыр. Мәсәлән, минем хезмәт кенәгәмне Татарстанның хәзерге мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Һадиуллин ачкан иде. Һәм бу миңа бик зур җаваплылык йөкли. Аңардан гел нәрсәгә булса да өйрәнергә мөмкин! Бу очрактан файдаланып, Илсур Гәрәй улын юбилее белән тәбриклим һәм аңа иң изге теләкләремне юллыйм!

Фото Казанның 179 нчы гимназиясе архивыннан

КЫТАЙЧА ӨЙРӘНМӘСКӘ СӘБӘП ЮК!

Евгения Чеснокова

Кытай телен өйрәнер өчен биш, җиде, ун сәбәп... Безнең көнчыгыш күршеләребез телен белү өстенлекләрен мактаган мәкаләләр Интернетта бик күп. Бүген һәркем яхшы аңлый: алга таба Кытай озак еллар буе безнең партнёрыбыз булачак. Ә инде син партнёр телендә сөйләшәсең икән, эшлекле мөнәсәбәтләрне дә, башка элемтәләрне дә урнаштыру гадирәк һәм җиңелрәк.

Димәк, бүген кытай телен үзләштерү сәбәпләрен түгел, бәлки аны нигә һаман өйрәнмәүне ачыклар вакыт: моның өчен бер генә сәбәп тә юк икән бит! Билгеле ки, теләсә кайсы чит телне уңышлы үзләштерү өчен иң әүвәл бик тәҗрибәле мөгаллим табу зарур. Һәм бу очракта ашыкмау, ялгышмау мөһим. Бүген, мәсәлән, еш кына шундый хәл күзәтелә: телнең нечкәлекләренә әле үзләре дә төшенеп җитмәгән студентлар үзләрен тәҗрибәле укытучы сыйфатында тәкъдим итә. Әлбәттә инде, алар да нәрсәгә булса да өйрәтә ала, тик менә аларның белеме белән генә чынлап торып тел өйрәнеп булмый шул.

Казандагы Mandarin Sun кытай теле һәм мәдәнияте үзәге җитәкчесе Ләйсән Ибәтуллина әйтүенчә, ул үзе университет һәм хәтта инде аспирантура тәмалагач та, кытай телен бик яхшы үзләштерүгә кадәр әле бик ерак булуын яхшы аңлаган. Бик күп стажировка (шул исәптән Пекинда да) үткәннән соң гына, ул үзе дә шәкертләр тупларга җөрьәт иткән.

– Нуленче еллар башында кытайча өйрәнүнең киләчәктә зур файда китерәчәген аңлаучылар әле күп түгел иде, – дип искә ала Ләйсән Хәсән кызы. – Тик инде уңышлы эшкуарлар һәм югары түрәләр ул чакта ук үз балаларын минем дәресләргә йөртә башлады. Беренче шәкертләрем шулай тупланды, аннары инде башкалардан ишетеп килүчеләр күбәйде. Мин кытай теленә түләүле аерым дәресләрдә дә өйрәттем, Казан мәктәпләрендә дә укыттым. Әмма экренләп үз мәктәбемне ачу теләге туды, авторлык методикаларым да эшләнгән иде инде. Шул рәвешле Mandarin Sun үзәге пәйда булды, бүген ул дәүләт лицензиясенә ия.

Үзәккә өч яшьлек сабыйлардан алып абруйлы эшкуарларга кадәр йөри. Әлбәттә инде, аларны өйрәтү алымнары да төрле. Иң кечкенәләр белән уйный-уйный өйрәнәләр, тематик мультфильмнар карыйлар. Mandarin Sun үзәгендә сабыйлар өчен уку-укыту әсбаплары бик күп: җырлый торган робот-пандалардан алып «сөйли торган» каләмгә кадәр бар – язылган сүзгә якын китергәч, каләм аны укып бирә ала.

Мәктәп балалары һәм өлкәннәр өчен башка ысуллар кулланыла, тик бу очракта да үзәк мөгаллимнәре аларны кытайча өйрәтеп кенә калмыйча, Кытай турында төпле белем дә бирергә омтыла.

Mandarin Sun үзәгенә кытай теле буенча олимпиадаларда җиңү турында хыялланган укучылар да килә. Ләйсән Ибәтуллина шәкертләре арасында мондый олимпиадаларда җиңүчеләр яки призлы урыннар алучылар шактый. Сүз уңаеннан, әгәр Mandarin Sun үзәгендә тел өйрәнүче мәктәп балалары киләчәктә укуларын Кытай университетларында дәвам итәргә теләсә (ә бүген әлеге илнең югары уку йортларында уку бөтен дөньяда бик абруйлы санала), аларның хәтта анда барып, үзләрен кызыксындырган барлык сорауларга җавап табу мөмкинлеге дә бар, чөнки үзәктә илнең кайбер вузлары белән бик яхшы элемтәләр урнаштырылган инде.

Кытайча өйрәнергә теләп тә, дәрескә йөрергә вакыты булмаган эшкуарлар исә онлайн да шөгыльләнә ала – үзәктә хәтта Австралиядә яшәүче укучылар да бар... Шул рәвешле, үз кыйбласы итеп «Мандарин Сан – уңышка юл!» шигарен сайлаган Mandarin Sun мәктәбендә уңышка күп төрле юллар белән ирешеп була. Һәм аларның һәркайсында син кытай теленең матурлыгын һәм үзенә бер төрле көйле яңгырашын тоя, иероглифлар белән язу серенә төшенә һәм, ахыр чиктә, Кытайның борынгы мәдәниятенә ихластан гашыйк була аласың.

Mandarin Sun үзәге

Казан ш., Четаев ур., 20

+7 (962) 559-88-86

mandarinschoolkzn@gmail.com

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

БЕРГӘ АТЛАГАНДА ГЫНА!

Руфия Фазылова

Казанның Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе. «Татарстан» журналының әлеге уку йорты турында берничә тапкыр язганы бар. Төп фәннәр дә татарча укытыла торган сирәк мәктәпләрнең берсе ул. Быелгы уку елын белем үзәге бик сөенеп каршы алды: 270 урынга исәпләнгән дүрт катлы яңа бина салынды. Ләкин данлыклы гимназиядәге яңалыклар моның белән генә бетми.

Яңа бина бөтен заман таләпләренә җавап бирә: иң яхшы лабораториясе булган химия-биология кабинеты, спортзал (тренажерлар залы аерым), конференц-зал, заманча җиһазландырылган татар теле кабинеты, чит телләр өйрәнү өчен махсус сыйныфлар, хәтта тавыш яздыру студиясенә кадәр бар. Ләкин мәктәп җитәкчелегенең иң зур горурлыгы – дүртенче катта урнашкан инженер сыйныфлар.

Гимназиядә инженер сыйныфлар дүртенче ел эшли. Математика, физикага сәләте булган укучыларны бер сыйныфка туплап, махсус программа буенча укыталар. Нәкъ менә алар өчен дүртенче катта бөтен мөмкинлекләр дә булдырылган. Информатика, работ техникасы, физикадан лаборатор эшләр, 3D-модельләштерү өчен махсус җиһазлар кайтарылган. Урта сыйныфларга җиткәнче үк, укучылар лазерлы станокта эшләргә өйрәнә.

– Башта укучылар үзләренең проектларын компьютерда эшли, аннан инде аны станокта ясаячак, – дип аңлатты гимназия директоры Рамил Гайнуллин. – Иннополистагы кебек пилотсыз машина йөртергә дә өйрәнәчәкләр.

Мактанып әйтү түгел, әмма Татарстанда иң заманча химия-биология кабинетлары да бездәдер. Көчле микроскоплардан тыш, цифрлаштырылган лабараторияләр дә кайтты. Ә бит әле бер ел элек кенә болай ук булыр дип хыялланмадык та! Узган елның сентябрь аенда безгә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисе Марат Готыф улы Әхмәтов белән ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Һадиуллин килде. Һич көтелмәгән очрашу булды ул. Һәм нәкъ менә шул очрашуда гимназиягә яңа янкорма салу турында сөйләштек. Гаҗәп тә, түгел дә – бер ел эчендә шундый бина сафка басты. Моның өчен җитәкчеләребезгә олы рәхмәтебезне җиткерәбез. Кайчакта үзебездән үзебез көнләшеп куябыз.

Чынлап та, гимназиянең яңа бинасы көнләшерлек, ул башка бер генә белем йортын да кабатламый: тыштан ук милли бизәкләр белән ясалган, үз йөзе булган уку йорты. Тик яңа бина, заманча җиһазландырылган сыйныфлар белән генә булмый, ә анда эшләрлек, әзерлекле укытучылар да кирәк. 2 нче гимназиядә бу мәсьәлә хәл ителгән.

– Беренчедән, яңа кайткан заманча җиһазларда эшләү өчен үзебезнең укытучылар махсус белем алды, – дип дәвам итә директор. – Икенчедән, гимназиягә читтән дә укытучылар җәлеп итәбез. Гимназия тарихында шундый зур адым ясалды – югары уку йортлары һәм «Сириус» федераль белем үзәгенең республикада ачылган төбәк бүлеге белән хезмәттәшлек итәбез. Ягъни безнең укучылар белән «Сириус» мөгаллимнәре, остазлары эшли. Химия, биология буенча олимпиада хәрәкәте оештырылды. Әле бит гимназиядә остазлык мәктәбе дә гамәлдә. Педагогика юнәлешендә белем алучы югары уку йорты студентлары ел дәвамында безгә килеп балалар укыта. Бу да – гимназия өчен яңа бер адым.

Бүген яхшы мәктәпләр бик күп. Казанда гына түгел, республиканың башка шәһәрләрендә заманча белем үзәкләре ачыла. Ләкин 2 нче татар гимназиясе ул бүтән. Биредә укучыларга төрле яклап үсәргә мөмкинлек тудырылган: театр, җыр, бию, көрәш, әлбәттә, телләр, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү... Һәм алар барысы да милли тәрбия белән үрелеп бара.

– Гимназиябезгә карата хәерхаһлы булганнары өчен республика җитәкчелегенә зур рәхмәт, – диде Рамил Рәшит улы. – Әлбәттә, Илсур Гәрәй улын аерып әйтәсе килә. Кайчан гына барсаң да, гозеребезне кире какмый. Хөрмәтле җитәкчебез шушы көннәрдә гомер бәйрәмен билгеләп уза. Ихлас күңелдән нык сәламәтлек, иминлек, авыр, җаваплы хезмәтендә уңышлар телибез! Т

Фото: Ш.Мәрҗани исем. 2 нче татар гимназиясе архивыннан.

РЕКЛАМА

ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ ДӘВАМ ИТЕП...

Руфия Фазылова

Казанның нәкъ үзәгендә Каюм Насыйри исемендәге аерым фәннәр тирәнтен укытыла торган 80 нче татар-рус мәктәбе бар. Белем йортына атаклы татар мәгърифәтчесенең исеме 2021 елда бирелде. (Мәктәптә хәтта Каюм Насыйриның корычтан ясалган сыны да бар.) Хәер, соңгы берничә елда белем йортында башка зур үзгәрешләр дә булган.

Исеме генә түгел, белем үзәгенең җисеме дә үзгәргән – капиталь төзекләндерүдән соң ул өр-яңа кебек! Югары сыйныф укучылары һәр шимбә КФУга барып белем ала. Гомумән, 80 нче татар-рус мәктәбе әлеге югары уку йорты белән тыгыз бәйләнештә: булачак укытучыларның күбесе педагогик практика узарга бирегә килә. КФУ белән уртак бүтән проектлары да күп икән.

Каюм Насыйри музее белән янәшә торган 80 нче татар-рус мәктәбен соңгы биш елда Россиянең атказанган укытучысы, педагогика фәннәре кандидаты Роберт Мияссәр улы Мансуров җитәкли. Мәктәп тормышында зур үзгәрешләр нәкъ менә ул килгәч башланган:

– Директор булып билгеләнгәч тә, мәктәпкә Каюм Насыйри исемен бирүне максат итеп куйдым, – диде җитәкче. – Ни өчен дигәндә, мәктәбебез тарихи җирдә урнашкан. Татарстан белән Тукай урамнары кисешкән бу урында татарның күп зыялылары яшәгән, шул исәптән Каюм Насыйри да. Биредә аның туганы – Мөхәммәдбәдыйк Хөсәеновның йорты булган. Билгеле булганча, мәгърифәтче гомеренең соңгы елларында шунда торган. Димәк, безнең мәктәп урнашкан мәйданда кайчандыр Каюм Насыйри йөргән, иҗат иткән...

80 нче татар-рус мәктәбендә бүген 841 бала укый, асылда 750 урынга исәпләнгән ул. Укучылар саны елдан-ел арта икән. Биредә егерме бер милләт баласы укый! Төп фәннәр рус телендә алып барыла, әмма мәктәпнең тоткан кыйбласы – татарча. Көрәш бәйгеләре, «Татар малае», «Татар кызы», «Тантана» кебек конкурслар, уку елы тәмамлангач уздырыла торган Сабантуй бәйрәме – барысы да милли тәрбиягә йөз тота.

– Мәктәптә традицияләргә дә, укытуга да игътибар зур, – диде Роберт Мияссәрович. – Йөз еллык мәктәбебездә кемнәр генә укымаган, кемнәр генә укытмаган. Зур горурлыгыбыз – Россиянең халык укытучысы Рамил Исмәгыйль улы Хәлиуллин. Ул безнең мәктәптә кырык елдан артык химия фәнен укыткан, фәнни эшчәнлек алып барган. Аның авторлык методик әсбаблары һәм татарчага ул тәрҗемә иткән химия дәреслекләре хәзер дә кулланыла.

Баксаң, Рамил Исмәгыйль улы хәзерге ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Һадиуллиннан да имтихан алган. Эш шунда ки, элек югары уку йортына укырга кергәндә, татар мәктәбен тәмамлаган укучылардан имтихан алу өчен телне белгән мөгаллимнәрне махсус чакырганнар. Рамил Хәлиуллин шундый мөгаллимнәрнең берсе булган. Булачак министр Казан дәүләт педагогика институтына укырга кергәндә химия һәм биология фәннәреннән имтиханны нәкъ менә Рамил Исмәгыйловичка тапшырган. Һәм ике фәннән дә «5» билгесе алган. Россиянең халык укытучысы шул чагында ук Илсур Һадиуллинның белем дәрәҗәсен күргән, бәяләгән һәм ялгышмаган. Ә бүген исә ТР мәгариф һәм фән министры дәрәҗәсенә ирешкән кичәге укучы олпат укытучысы Рамил Хәлиуллинны хөрмәтли. Шул исәптән Каюм Насыйри исемендәге аерым фәннәр тирәнтен укытыла торган 80 нче татар-рус мәктәбенә карата аерым ихтирамы, илтифаты белән дә.

– Мәктәбебезгә Каюм Насыйри исемен бирелүне Илсур Гәрәй улы Һадиуллин хуплады, – дип дәвам итте Роберт Мияссәрович. – Тантаналы рәвештә узган чарага килеп, коллектив алдында чыгыш ясады. Укытучысы Рамил Хәлиуллинга мәртәбәле бүләк тапшырды. Гомумән, Илсур Гәрәй улына карата безнең коллектив бик нык рәхмәтле. Һәр башлангычыбызны хуплап, хәер-фатыйхасын биреп тора. Мин аны чын профессионал буларак та югары бәялим, хөрмәт итәм. Илсур Гәрәй улын ихлас күңелдән күркәм юбилее белән котлыйбыз!

Фото: мәктәп архивыннан. РЕКЛАМА

ИЕРОГЛИФЛАРГА ГАШЫЙК ЗАТ

Дмитрий Сивков

Аңлашылмый торган берәр нәрсә турында бездә «кытайча язылган» диләр. Бу гыйбарәнең килеп чыгышы XVII гасырга барып тоташа. Рус патшасына Кытай императорыннан килгән хатны ярты гасырдан артык укый алмыйлар. Андый тылмач табылмый. Ул заманнардан соң инде күп нәрсә үзгәрде. Бу үзгәрешләрдә шул исәптән Светлана Глушкова кебек кешеләрнең дә катнашы бар.

ХЫЯЛЛАР ХАКЫНА КӨРӘШЕРГӘ БУЛА

«Синьдао» 新道 (яңа юл) дип аталган тел мәктәбен оештыручы зат белән әңгәмәбез көтелмәгән күңел бушатудан башланып китте:

– Дөресен генә әйткәндә, мин япон телен өйрәнергә җыенган идем. Әле мәктәптә укыганда ук иероглифлар белән мавыгып киттем. Аларны язарга ярата идем. Рус телендә орфография куркыта, кагыйдәләрне ятларга туры килә. Ә менә кытай телен мин җиңел өйрәндем, чөнки анда хәрефләр, дөрес язу кагыйдәсе, зат төрләнешләре юк.

Филология фәннәре кандидаты, доценттан мондый сүзләр ишетеп, ничек шаккатмыйсың, ди. Әйтергә кирәк, ул шунда ук Казанда кытай теленә өйрәтүче иң яхшы укытучылар исәбенә кермәгән. Моңа ирешү өчен күп тырышырга туры килә аңа. Иероглифларга гашыйк кызны югары уку йортында төрек төркеменә билгелиләр. Кытай төркеменә эләгү өчен үҗәтлек күрсәтергә кирәк була. Мондый хыяллар хакына көрәшергә дә ярый.

– Ул вакытта, 2000 нче еллар башында, кытай теле бүгенге кебек әле бик популяр түгел иде. Дөресрәге, ул бөтенләй дә популяр түгел иде, – ди Светлана Глушкова. – Без төркемдә барлыгы җиде кеше укыдык. «Нәрсәгә кирәк ул сиңа? Кая барасың?» – дип әйтүчеләр дә булды. Ләкин минем баштан ук шушы телгә күңелем ятты. Аны өйрәнү кызык иде миңа. Ә төрек телен өйрәнәсем килмәде, ул минем өчен бик ансат иде, чөнки татар телен камил беләм. Ансат юлдан йөрергә яратмыйм, никадәр катлаулырак булса, шулкадәр кызыклырак. Мин бу юлдан менә инде егерме бер ел буе атлыйм.

– Тулы бер гомер. Светлана Юрьевна, үзегезнең педагогик эшчәнлегегез дәверендә ничә кешене кытай теленә өйрәттегез?

– Санаганым юк, ләкин меңнән артык иканен төгәл беләм.

«ТЕЛЛӘР ГАДИ ЯКИ КАТЛАУЛЫ БУЛМЫЙ»

– Хәзер бу телне өйрәнергә теләүчеләр күп. Хәтта күптән түгел генә Россия Президенты Владимир Путин да үзенең гаиләсендә кытай телен өйрәнүчеләр барлыгын әйтте. Ә сезнең дәресләргә кемнәр йөри?

– Кытайда ниндидер проектлары булган айтишниклар, инженерлар. Әти-әниләр дә балалары өчен күбрәк кызыксына башлады. Кытай телен белү аларга карьераларында ярдәм итәсен аңлыйлар.

– Өйрәнәсе килеп тә кыенлыклардан курыкканнар өчен нинди киңәш бирер идегез? Ни әйтсәгез дә, «кытай язуы» дигән комплекс безгә тирән сеңгән.

– Телләр гади яки катлаулы булмый, дип әйтә алам. Фәкать система гына бар һәм аны аңларга кирәк. Менә шул. Укытучы әлеге системаны аңларлык итеп төшендерә икән, телне өйрәнү кыен түгел, хәтта кызыклы да. Минем яраткан бер фразам бар: «Бер генә телнең дә әле берәүгә дә комачаулаганы юк». Күп телләр белүгә мин биш куллап риза гына. Үзем инглиз, татар, рус һәм кытай телләрендә сөйләшәм.

Әңгәмә ахырында әлеге материалның авторы әңгәмәдәшенең кытайча «Рәхмәт» дип әйтүен үтенде. Ул әйтте, ләкин аны беренчесеннән түгел, хәтта икенче тапкырдан да отып алу мөмкин түгел. Әле омтылырлык нәрсәләр бар. Бәлки, чынлап та, иероглифларга дикъкать беләнрәк карый башларгадыр?

Инглиз һәм кытай телләреннән беренче бушлай дәрескә язылу:

+7 (843) 204-20-28

xindaoschool.ru

+79969527179

@XINDAOSCHOOL

РЕКЛАМА

Фото Светлана Глушкова архивыннан.

КАРТЛЫКНЫҢ ЯШЬЛЕГЕ, ЯКИ СИКСӘНДӘ НИЧЕК ФОРМАНЫ ЮГАЛТМАСКА?

Руфия Фазылова

Казанның «Крылья Советов» паркы. Кичке сәгать биш. Бер төркем абый-апалар (җитмеш яшьтән өлкәнрәкләр) бергәләшеп физик күнегүләр ясый. Барысы да җыелып беткәч, ике чакрым араны йөгерәчәкләр икән.

– Атнага өч тапкыр шулай җыелабыз, – диде хәрәкәт ясаудан туктамый гына бер абзый.

– Барыгыз да яхшы формада, спорт шулай итәме? – дим.

– Монда шөгыльләнә башлагач, 15 килограмм авырлыктан котылдым, – дип, көр елмайды тәбәнәк гәүдәле апа.

«Мотор» клубында шөгыльләнүче өлкәннәрнең һәркайсы төрле хезмәт юлы узган. Ләкин аларны бер нәрсә – спортны, тормышны ярату берләштерә.

ЛАЕКЛЫ ЯЛДА АКТИВ ТОРМЫШ

Чит илләрдә пенсионерларның спорт белән шөгыльләнүе – гадәти күренеш. Баксаң, безнең өлкәннәр дә калышмый икән. Даими рәвештә физик культура белән шөгыльләнүчеләр Россия буенча бер ел эчендә 1 миллионга арткан. «Демография» илкүләм проектының актив озак яшәү программалары нәтиҗәсендә 6,7 миллионнан артык өлкән яшьтәге ватандашыбыз спорт белән шөгыльләнә» – дип игълан итте РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Татьяна Голикова.

Казан да калышмый. Башкалабызда 2016 елдан бирле «Яшәү яме» проекты эшләп килә. Казанның 33 китапханәсе һәм 7 паркында урнашкан клубларга лаеклы ялдагы кешеләр бушлай дәресләргә йөри. Монда һәр кеше үзен кызыксындырган юнәлешне сайлый: вокалдан башлап, төрле биюләр, театр түгәрәге, сынлы сәнгать, скандинавия йөреше, фитнес,

Фото: Александр Ефремов

йөгерү һәм башкалар. Үзләренең сәләтен, казанышларын алар төрле гомумшәһәр чараларында күрсәтә. Әлмәт, Алабуга, Чаллы, Арча кебек шәһәрләрдә дә абый-апалар өчен мондый мөмкинлекләр бар.

Казанның «Крылья Советов» паркында исә ике клуб эшли. Скандинавия таяклары белән йөрүчеләр 130лап кеше икән, ә «Мотор» йөгерүчеләр клубында 60лап кеше санала. Соңгысында, мөгаен, иң чыдам, иң актив кешеләрдер. Яңгыр, кар, 30 градус салкын, димиләр, атна саен билгеләнгән вакытка килеп, ике (кайчакта өч-дүрт, ун да була) чакрымны йөгерәләр.

«ЗАВОД ЭШЧЕЛӘРЕ ҖЫЕЛДЫК»

«Мотор» клубы 1997 елда барлыкка килә. Аны оештыручыларның берсе – Владимир Батыр улы Максудов. Тик бүген ул йөгерми. Шулай да «Мотор» клубының бер генә тренировкасын да калдырмый. Хәзер ул клубның судьясы – йөгерүчеләргә старт биреп, аларның ничә минутта килгәннәрен санап бара. Чын марафоннардагыча: Владимир Батыровичның авызында микрофон, кулында флаг белән секундомер. Үзе һаман егетләр егәрлеген югалтмаган.



– Гомерем буе – спортта, бүген дә һәр көн физик күнегүләр ясыйм, – диде Владимир Батырович. – Мәктәптә укыганда, аннан соң КАИда белем алганда да гел йөгерүдә булдым. Заводта эшләгәндә дә көн саен йөгердем. Мин хезмәт куйган вертолёт заводының спорт клубы бар иде. 1990 нчы елларда ул таркалды. Үзегез беләсез, илдә ыгы-зыгы башланды. Һәм менә шунда элек йөргән кешеләр кичләрен бергәләшеп чыгып йөгерә башладык. Җәмәгатем заводта спорт инструкторы булып эшләде. Әнә шулай итеп тагын берничә актив кеше белән «Мотор» клубы төзедек. Башта егермеләп кеше йөрде, ярты елдан - утызга, бер елдан кырыкка әйләндек. Күпчелеге 16 нчы заводның эшчеләре монда. Бүген даими йөрүчеләр саны алтмышка тула. Кемдер килә, кемдер китә. Гаиләләре белән йөрүчеләр дә бар.

Беренче карашка, «Мотор» клубы өлкән яшьтәге кешеләр өчен. Ләкин әби-бабайларына ияреп оныклары, балалары да килә икән. Шулай булгач, монда яшькә карап чикләү юк.

– Диванда тик ятарга өйрәнмәгән кеше олыгайгач та актив була, – ди Владимир Батырович. – Биредә гел шундый кешеләр. Кечкенә чагымда йөрәк белән проблемалар бар иде, тумыштан шулай килгән. Табиблар язып биргән даруларны пачкалап эчтем. Тик файдасы булмады. Мәктәптә яхшы укыдым, кызыксынучан бала идем. Үсмер яшькә җиткәч, бу проблеманы үзлегемнән өйрәндем. Акрынлап физик күнегүләр ясадым, йөгерә башладым. Менә шунда үземне яхшырак хис иттем. Һәм гомерлек юлдаш итеп спортны сайладым. Күргәнегезчә, ялгышмаганмын: шушы диагноз белән 73 яшьне тутырдым. Әти 101 яшен тутырды, һаман да – сафта. Сугыш ветераны ул. Әти яшенә җитмәсәм дә, әле яшисем килә. Шуның өчен дә сәламәтлегемне кайгыртам. Гел хәрәкәтләнергә тырышам.

«СТАДИОН ИКЕНЧЕ ӨЕМ КЕБЕК ИДЕ»

«Мотор» клубының бүгенге рәисе – Рөстәм Мөхәммәтҗанов. Февраль аенда 75 яшен тутырган. Рөстәм абый клубның әтисе дә, әнисе дә. Һәрвакыт елмая, бөтен кешене белә, әллә кайдан сәлам бирә. Бик аралашучан.

– Мәктәптә укыганда ук йөгерә идем, – диде Рөстәм абый. – Армиядә дә яраткан бу шөгыльне ташламадым. Хәрби хезмәткә алынганчы 22 нче заводта эшләдем. Кайткач та, хезмәт юлымны шунда дәвам иттем, физрук итеп куйдылар. Ул чагында заводларда тормыш кайнап торды: егетләр белән эшкә кадәр йөгерәбез, ялларда стадионга җыелабыз. Дөресен генә әйткәндә, стадион минем

икенче өем кебек иде. Заводның үз командасын тупладык, ярышларга йөрдек. Бик актив тормыш алып бардык. Менә монда йөрүчеләрнең күбесе шул кешеләр инде.

Рөстәм абый Северный бистәсендә гаиләсе белән үз йортларында гомер итә. «Крылья Советов» паркы җитәкчелегеннән үзләренә аерым бер бүлмә сорап алган. Биредә алар җыелалар, чәй эчәләр. Киенү-чишенү өчен дә аерым бүлмәләре булганга сөенгәннәр.

– Яңа ел, 8 Март бәйрәме, өлкәннәр көне – берсен дә калдырмыйбыз, – ди Рөстәм абый. – Хатын-кызларга чәчәкләр бирәбез. Клубка шундый актив хатын-кызлар килә, сиксән яшендә дә җырлап-биеп йөриләр. «Монда сезнең нинди бәйрәм?» – дип, килеп-килеп сорыйлар. Бу йөгерү клубы гына түгел, монда тормышны яратучы, дөньяга карашлары бер булган шат күңелле кешеләр җыела.

«СИКСӘН ЯШЕМДӘ ШПАГАТКА УТЫРДЫМ»

Чынлап та, Рөстәм абый һич арттырмый. «Мотор» клубындагы хатын-кызларның барысы да – ут. Әле кычкырып көлешәләр, әле биешәләр. Читтән карап торганда бик гаҗәп!

Әнә шундый тиктормас апаларның берсе – Разия Харис кызы Агабекян белән аралашып алдык. Сиксән ике яшь икән үзенә.

– Җәмәгатем милләте буенча әрмән, илле биш ел тату яшибез, – диде Разия апа. – Атнага ике-өч тапкыр «Мотор» клубында йөгерәбез. Һәм атнага ике тапкыр гимнастикага йөрим. Анысы да монда гына, Ленин мәдәният сараенда уза. Сиксәннән узгач, шпагатка утыра башладым. Иң гаҗәбе – яшь чагында да шпагатның нәрсә икәнен белмәдем.

Разия апаның җәмәгате спорттан ерак кеше. Башта ул хатынының болай йөрүенә көлеп кенә караган. Янәсе, берничә тапкыр барыр да туяр. Әмма... Разия апа шахмат уеннары буенча мастер дәрәҗәсенә ирешкән кеше. Димәк, дисциплина, төгәллекнең ни икәнен бик яхшы белә.

– Мин монда килгәндә түм-түгәрәк идем, – дип дәвам итте ул. – Шахматта бит гел утырасың. «Мотор» клубы турында ишеткәч, кызык өчен генә бардым. Өйдә ашыйсың да диван янына барып утырасың. Ә авырлык көннән-көн арта. Буем да бәләкәй булгач, аякларга авыр була башлады. Әнә шулай бер ел эчендә унбиш кило авырлыкны «төшереп аттым». Һәм, беләсезме, шундый җиңеллек сиздем. Әлбәттә, йөгерүдән тыш гимнастика да булышкандыр. Тренерыбыз бик шәп!

«ЙӨГЕРҮ – ЯШӘҮ РӘВЕШЕМ»

Разия апа телгә алган тренер – Әлфия Галимҗан кызы Семёнова. Ленин мәдәният сараенда йога дәресләре алып бара ул. Шулай ук «Мотор» клубында да шөгыльләнә.

– Миңа 74 яшь, – дигәч, башта ышанмадык. Әлфия апа әле ять-яшь!

– Спорт ярдәмендә шулай яшь калдыгызмы? – дим.

– Әйе. Гомер буе йөгердем. Яшь калуның бөтен сере шул. Һәр көн иртән йокыдан торам да көзгегә елмаеп карыйм һәм урманга йөгерергә чыгып китәм.

Әлфия апа – профессиональ спортчы. Башта ул Әлмәт физкультура техникумын, аннан КДПИның физик тәрбия факультетын тәмамлаган. Студент чагында йөгерү буенча Татарстанның җыелма командасында булган. Аннан соң Башкортстан якларына күченеп киткән. Гаилә корган, өч бала тәрбияләп үстергән. Гомер уртасында Казанга күченгән. Башкаланың бер мәктәбендә шактый еллар физкультура дәресләре алып барган.

– Дубравная урамыннан кадәр монда килеп йөрим, – диде Әлфия апа. – Ленин мәдәният сараенда атнага ике тапкыр йога дәресләре алып барам. Яшәгән җиремә якынрак та эш тәкъдим иттеләр, ләкин миңа йөргән кызларны (!) калдырып китә алмыйм. Без биредә бер гаилә кебек: берберебез турында барысын да белеп торабыз. Ә «Мотор» клубына җай чыккан саен киләм. Әлбәттә, мин көн саен йөгерәм, әмма монда – команда, алай күпкә кызыграк!

...Тормыштан зарланып, диваннан да тормыйча өйдә ятарга була. Һәм «Мотор» клубына йөрүче өлкәннәр кебек актив яшәргә дә мөмкин. Әлбәттә, кеше үз тормышын үзе көйли. Тик килешерсез, икенче вариант күпкә файдалырак. Беренче чиратта, өлкән кешенең үзе өчен. Т

«ТИЗ ЙӨРҮ ДӘ ФАЙДАЛЫ!»

«Мотор» клубына йөрүчеләрдән киңәш:

– Бүген күпләр йөгерә белми. Һәм ул сәламәтлек өчен зыян китерә. Аз-азлап йөгерә башларга кирәк. Алайса күпләр беренче тапкырдан ук фәлән чакрымны әйләнәләр. Ә иртәгәсен урыннан тора алмыйлар. Профессионал рәвештә, даими йөгерә башлаганчы организмны әзерләргә, буыннарны акрынлап кына язарга кирәк. Эшне гимнастикадан башларга киңәш итәбез. Бу аеруча өлкәннәр өчен мөһим. Тиз йөрү дә бик файдалы. Пульс 120 гә җиткәнче йөрсәң, организм тулы көченә эшли дигән сүз.

Өлкәннәр көне белән сезне, «Татарстан» ветераннары!

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Мәгариф өлкәсенең реформаторы **кем**

Безнең **кайсыбыз** килмешэк

Василий Демьянов Кытай кухнясын **ничек** үз иткән

Әдәби маршрутлар **кая** сузыла

Дуслык һәм тигезлек **кайда** яши

ШАКИРҖАН ТАҺИРИ – МӨГАЛЛИМ, МЕТОДИСТ, МӘГЪРИФӘТЧЕ

Илдус Заһидуллин

XIX гасырның соңгы чирегендә кайбер татар мәктәп-мәдрәсәләрендә күзәтелгән яңарыш хәрәкәтенә Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган бер төркем яшьләр йогынты ясый башлый. XX гасыр башында аларның иҗтимагый тормышны европалаштыруга һәм милли мәгариф системасын булдыруга тәэсире хәлиткеч була. Шундый мөхтәрәм шәхесләрнең берсе – Казан татар укытучылар мәктәбенең матур язу һәм рәсем укытучысы, педагог, мәгърифәтче һәм методист Шакирҗан Әхмәтҗан улы Таһири. Ул күпкырлы эшчәнлеге белән замандашлары хәтерендә якты эз калдыра.

ШӘКЕРТЛЕК ЕЛЛАРЫ

Шакирҗан Таһири Казан губернасы Зөя өязе Ачасыр авылы мулласы Әхмәтҗан ахун гаиләсендә 1858 елның 28 февралендә (яңача 12 мартта) дөньяга килә. Әхмәтҗан мулла Зөя өязе ахуны вазифасын башкара. Ул төбәк руханилары һәм өяз хакимияте арасындагы мөнәсәбәтләрдә, шулай ук өяз руханиларына кагылышлы мәсьәләләрне Мәхкәмәи шәргыя белән хәл иткәндә төп иҗтимагый шәхес ролен уйнаган. Өяз ахуны итеп, гадәттә, гыйлемле һәм русча сөйләшә белгән мулланы билгеләгәннәр, онытмыйк.

Менә шундый дәрәҗәле гаилә башлыгы яшүсмер улын, өйдә һәм үз мәктәбендә укытканнан соң, Казанга илтә һәм үзе якын күргән һәм хөрмәт иткән шәһәр ахуны Шиһабетдин хәзрәт мәдрәсәсенә урнаштыра.

Әйтергә кирәк, туган авылы мәктәбендә укыган вакытта ук Шакирҗан, дини текстлар ятлаудан тыш, матур һәм пөхтә итеп язуны үзләштерә. Бу елларда мәдрәсәләрдә күпчелек уку китапларын кулъязма әсбаплар тәшкил иткән. Дини трактатлар күчерү белем туплауның аерылгысыз өлеше булып саналган. Шәкертләр дини кулъязмаларның кирәкле өлешләрен күчереп алып, үзләренә уку дәреслекләре булдырганнар. Шакирҗанның китап күчерү осталыгы тагы да артып, сабакташлары арасында дәрәҗәсе үсеп киткән. Бу һөнәре беркадәр акча эшләү мөмкинлеге дә биргән булса кирәк.

Шакирҗан шәкерт мәдрәсәдә дини белем дә үзләштерә, шәһәрдә русча укырга-язарга да өйрәнә. 1876 елда рус-татар мәктәпләренә мөгаллимнәр хәзерләүне максат итеп куйган Казан татар укытучылар мәктәбен (КТУМ) ачуга әзерлек башлана. Аның җитәкчесе (инспекторы) итеп күп еллар дәвамында Казан гимназиясендә татар телен укыткан һәм татар теле дәреслекләре авторы булган мәшһүр каллиграф Мөхәммәтгали Мәхмүтов билгеләнә.

Иң башлап егетнең русча укырга теләге, шул ук вакытта аның хакында кайгырткан өлкәннәрнең телəктәшлеге Шакирҗанны Казан мөселманнарын шаккатырган һәм тетрәткән адым ясауга этәрә: алар шикләнеп-сагаеп караган русча белем бирәчәк уку йортына керергә имтихан тапшыра ул. 18 яшьлек егет, күрше губерналардан килгән 8 яшүсмер белән бергә, КТУМның 1 курсына

ЗИҺЕНЛЕ ШӘКЕРТ МӘДРӘСӘДӘ ДИН ГЫЙЛЕМЕН, ГАРӘП ҺӘМ ФАРСЫ ТЕЛЛӘРЕН ТИРӘНТЕН ҮЗЛӘШТЕРӘ. ЯКТАШЫ КАЮМ НАСЫЙРИ БЕЛӘН АРАЛАША БАШЛЫЙ, БУ АНЫҢ РУС ТЕЛЕ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУЫНА ЗУР ЙОГЫНТЫ ЯСЫЙ.

Фотолар автордан алынды

кабул ителә. Укучылар КТУМның тулай торагында хөкүмәт хисабына яшиләр һәм 3 тапкыр бушка тукланалар.

Яңа уку йортында да Шакирҗанга дин сабагын, гарәп имласында матур язуны, гарәп теле грамматикасын остазы Шиһабетдин Мәрҗани 4 ел дәвамында укыта. Тулай торакта биш вакыт намаз укыр өчен гыйбадәтханә бүлмәсе булдырыла, укучылар һәр җомгада якындагы мәчеткә өйлә намазына баралар, ислам дине бәйрәмнәре көннәрендә ял итәләр.

КТУМда гимнастика дәресләре, китап төпләү һәм агач эшенә өйрәтү дәресләре көннең икенче яртысында үткәрелә торган була. Ә көннең беренче яртысында беренче курста рус теле, математика, дин сабагы, табигать белеме укытыла; икенче курста аларга - география, өченче курста педагогика, дидактика да өстәлә. Матур язу дәресләре 3 ел дәвамында алып барыла.

КТУМда матур язу дәресләрен Мәскәү рәсем сәнгате училищесын тәмамлаган Икенче ирләр гимназиясенең рәсем укытучы Георгий Юрьевич Филиппус алып бара. Шакирҗан укытучысы җитәкчелегендә рәсемнәр дә ясый башлый.

МАТУР ЯЗУ ҺӘМ РӘСЕМ СӘНГАТЕ

Күпсанлы уку йортлары гөрләп эшләгән Казанда КТУМга укытучылар туплау зур кыенлык тудырмый. Шулай да Радловка шәһәр мөселманнары арасында КТУМ турында уңай фикер уяту, укучыларны яңа шартларга җиңелрәк яраклаштыру максатында татардан педагоглар җәлеп итү фикере тынгылык бирми. Ул 1878 елны университетның дүртенче курс студенты Шаһбазгәрәй Әхмәровны - рус телен, ә ветеринария институтын тәмамлаган Ибраһим Терегуловны табигать белеме дәресләрен укытырга эшкә ала.

1880 елда КТУМны биш кешедән торган беренче төркем тәмамлый. Хөкүмәт хисабына укыган бу яшь белгечләр 6 ел мәктәптә эшләргә тиеш була. Радлов Шакирҗанны шул ук елның җәендә шәһәрдәге бер мәдрәсә каршында эшләүче рус классының рус теле укытучысына ярдәмче итеп билгели. Шулай итеп кичәге шәкерт 1881 елның маеннан 1883 елның 1 февраленә кадәр Госманов мәчете каршындагы рус классында рус теле һәм математика укыта.

Филиппус КТУМда укытуын туктаткач, Шакирҗан аның урынына 1881 елның 1 сентябреннән матур язу укытучысы итеп эшкә чакырыла. Таһириның рәсем ясаудагы уңышлары турында хәбәрдар булган Радлов егетне Казан реаль училищесы рәссамы Христофор Григорьевич Пашковский янына аерым дәресләр алырга, шул исәптән натурадан рәсем ясау серләренә төшенергә җибәрә.

1883 елны Казан уку-укыту попечителе Пётр Дмитриевич Шестаков Санкт-Петербург Император сәнгать академиясендә Таһирига өяз училищесы рәсем укытучысы дәрәҗәсен бирүне сорап мөрәҗәгать итә. Хатына Шакирҗанның Казан реаль училищесы педагогик советы әгъзалары күзәтүендә ясаган рәсемнәрен дә терки. 1883 елның 3 октябрендә Сәнгать академиясе Советы Таһирига башлангыч мәктәпләрдә рәсем дәресләрен алып барырга хокук бирүче шәһадәтнамә бирү турында карар кабул итә. Шулай итеп, ул татарлар арасыннан беренче булып рәсем сәнгате буенча белгеч дипломына ия була.

Шакирҗан Таһири КТУМда башта атнага 10 сәгать матур язу, соңрак рәсем һәм сызым дәресләре алып бара. 1888 елны КТУМнан Иске Татар бистәсендә урнашкан рус-татар мәктәбенә мөдир булып күченә, биредә рус теле, арифметика һәм ислам дине дәресләрен укы-

ШАКИРҖАН ТАҺИРИ – БЕР ТӨРКЕМ БУЛАЧАК ТАТАР ИҖАТ ӘҺЕЛЛӘРЕНӘ, ГАЛИМНӘРГӘ ҺӘМ ҖӘМГАТЬ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕНӘ БЕЛЕМ БИРГӘН УКЫТУЧЫ. АЛАР АРАСЫНДА ШАГЫЙРЬ СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ, БУЛАЧАК ГАЛИМНӘР МӨХӘММӘТХАН ФАЗЛУЛЛИН, ГЫЙЛЕМ КАМАЙ, ГЫЙБАД АЛПАРОВ, 2 НЧЕ ҺӘМ 3 НЧЕ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫ ДЕПУТАТЛАРЫ, БАШКА КҮРЕНЕКЛЕ ҖӘМГАТЬ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ БАР.

Суфия һәм Фаик Таһировлар эшләгән «Безнең әлиф» (1929) әсбабы битләре.



Шакирҗан Таһири укыган һәм эшләгән Казан татар укытучылар мәктәбе бинасы.

Шакирҗан Таһири бизәгән «Касыйда-и бөрдә» кульязмасының беренче бите.

Шакирҗан Таһиринның шәхси китапханәсе экслибрисы.

та. Хәттат кабат КТУМга 1896 елда, халык мәгарифе министры тәкъдиме белән кайта һәм гомереңең соңгы көннәренә кадәр эшли.

КТУМ 1902 һәм 1914 еллардагы янгыннарда күп зыян күрә. Бигрәк тә 1902 елда аның китапханәсе, уку әсбаплары, физика, тарих-табигать белеме кабинетлары, архивы янып юкка чыга.

1917 елның 20 июлендә Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 14 июль карары белән КТУМ укытучылар семинариясе итеп үзгәртелә. Таһири яңартылган уку йортында эшләвен дәвам итә.

«Шакирҗан учитель»нең педагогик хезмәтенә 30 ел тулу уңаеннан оештырылган тантаналы утырышта бер төркем элеккеге укучылары һәм коллегалары юбилярны ихлас күңелдән җылы сүзләр әйтеп котлап, аның татар мәгарифе үсешенә керткән күпкырлы хезмәтен бик югары бәяли. 38 кеше кул куйган адреста Мөхетдин Корбангалиев, Ибраһим Терегулов, Гафур Коләхмәтов, Габдулла Юнысов, Сөләйман Аитов, Маһруй Мозаффария кебек күренекле кешеләрнең имзалары була.

Чыннан да, аның педагогик эшчәнлеге һәм активлыгы һәр яктан мактауга лаек. Әйтик, 1901 елда рус-татар мәктәбе, бина булмау сәбәпле, Казаннан Арчага күчерелгәч, уку йортын биналы итү өчен үзеннән акча биреп һәм хезмәттәшләрен иганәчелеккә җәлеп итеп, Таһири 1902 елны уку йортын кабат Казанга кайтаруга ирешә.

1905 елдан башлап ул, төп хезмәтеннән тыш, коммерция училищесында ислам дине һәм каллиграфия дәресләре алып бара, 1915 елдан 1 нче реаль училищеда мөселман балаларына дин сабагы укыта. Шул рәвешле гаилә бюджетын арттыра, әлеге уку йортларында белем алучы уллары өчен түләү күләмен киметә.

1913 елның 27 гыйнварында Казанда мөселман җәмәгатьчелегенең татар гимназиясен оештыруга багышланган җыелышында яңа уку йортын яклап чыгыш ясавы да билгеле.

Шакирҗан Таһирины күмү мәрасиме. 1918 ел, 14 гыйнвар (иске стиль буенча).

КУЛЬЯЗМАЛАРГА ҖАН ӨРЕП...

Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее фондында сакланучы XIX гасырда шәкертләр арасында бик популяр булган урта гасыр гарәп шагыйре Мөхәммәд әл-Бусыйриның «Касыйда-и бөрдә» әсәре кульязмасының күчермәсе – Таһириның зәвыклы һәм оста рәссам-хәттат булуын раслаучы бердәнбер чыганак.

XIX гасырның беренче яртысында татарлар тарафыннан күчерелгән кульязмалар бик гади һәм беркадәр генә бизәлеп эшләнә торган булса, хәттат китапның һәр битен төсле рамкага алып, текстның хәрефләрен нәсех һәм тәгъликъ язу төрләренең синтезын тәшкил итүче язу белән башкарган.

Сәнгать өлкәсендә эшләүче галимнәр фикеренчә, рәссам кульязманы Урта Азия китап бизәү традициясен үзгәртеп һәм татар халкының зәвыгын исәпкә алып бизәгән. Таһири китапның декорындагы унванны мөселман гыйбадәтханәләренең фасады схемасы рәвешендә ясаган. Унванның өске өлешен үсемлек орнаменты белән бизәлгән мәчет гөмбәзе рәвешендә сурәтләп, астына мөселманнар Коръән укыр һәм эшкә керешер алдыннан әйтә торган «Фатиха» сурәсенең беренче сүзләрен («Бисмиллаһ ир-рахман ир-рәхим») язып, аларны бербөтен итүче бизәкле кысага алган. Сакланып калган кульязма битләрендә кыса читендәге авыш сызыкларга билгесез автор тарафыннан кайсыбер гарәп сүзләренең тәрҗемәсе язылган.

1918 елда йортында булган янгында хәттатның хезмәтләре юкка чыккан дип санала. Шул сәбәпле рәссамның башка эшләре безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. Әмма үз чорында аның күпкырлы эшчәнлеге татар китабы бизәлешенә һәм, гомумән, татарларда рәсем сәнгате үсешенә зур йогынты ясаганы шиксез.

ӘТИЛӘРЕ ЮЛЫННАН...

1883 елны Шакирҗан 25 яшендә Казан дары заводы бухгалтеры Садыйк Курманаевның 19 яшьлек кызы Гөлчәһрәбануга өйләнә. Гаилә башлыгы 1899 елны Карл Фукс урамында каенатасының өе белән янәшә ике катлы агач йорт төзи. Бу никахтан бер-бер артлы 14 бала дөньяга килә, шуларның икесе - кечкенә вакытта, бер кызлары 15 яшьтә вафат була. Таһири балаларына яхшы белем бирергә тырыша.

Улларын һәм кызларын өй шартларында берничә ел үзе татарча һәм русча укыта. Аннары кызларын рус уку йортларына түгел, татар мәктәбенә бирә. Кызлары Зөһрә, Суфия, Зәйнәп, Өммә-Сәлма Ләбибә Хөсәеннованың кызлар мәктәбен тәмамлый, укытучы булып эшли. 1920 нче елларда Суфия татар библиографиясе буенча китаплар әзерләп бастыра. Зөһрә 1917 елның апрелендә I Бөтенроссия мөселман хатын кызлары съездында катнаша.

Таһири улларын рус һөнәри мәктәпләренә урнаштыра. Әтиләреннән дәрес алган,

шул исәптән дин сабагын укыган Әхмәтсолтан һәм Җәвад – Казандагы 1 нче реаль училищены, Мидхәд һәм Әхмәтзәки – коммерция училищесын, Йосыф сәнәгать училищесын тәмамлый. Таһириның төпчек улларына, өйдә этиләреннән тыш, укытучы булып эшләүче өлкән апалары да татарча укыта, аннары Ривгат Көнчыгыш педагогика институтына укырга керә, озак еллар Казан педагогика институтында белем бирә, профессор дәрәҗәсенә ирешә. Фаик исә, этисе юлыннан китеп, 1920 нче елларда рәссам-конструктивист булып танылa, 1930 елда Югары сәнгать-техника остаханәсенең полиграфия факультетын тәмамлый, китаплар бизи һәм төрле телләрдәге шрифтлар эшләү белән дә шөгыльләнә.

МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНЕҢ РЕФОРМАТОРЫ

КТУМда укыган һәм укыткан вакытта Таһири заманча белем бирү, укырга һәм язарга өйрәтү методикаларын тирәнтен үзләштерә. Каллиграф хезмәттәшләренә методик ярдәмлек итеп рус хәрефләрен язарга өйрәтү өчен зур табаклы кәгазьдә дүрт биттән торган «Матур язу» әсбабы бастыра.

Таһири, үзенең педагогик тәҗрибәсенә таянып һәм рус мәктәпләрендә кулланылган аваз методын кулланып, 1893 елда «Бадьэ әл-тәгълим нам мөкәммәл әлифба» («Укырга өйрәнүчеләр өчен камил әлифба») нәшер итә. Автор синтетик аваз методының мәшһүр рус педагогы Константин Дмитриевич Ушинский тәкъдим иткән язу-уку төрен яклый.

Каюм Насыйриның телебездә 10 төрле тавыш хәрефләре бардыр дигән фикеренә нигезләнеп, методист үз әлифбасында гарәп хәрефләренең я өстенә, я астына өстәмә билгеләр куеп, у, ү, о, ө, а, ә сузыклары һәм г, н тартыклары өчен аерым хәрефләр куллана, шуның белән уку-язу техникасын җиңеләйтерә. Замандашлары Таһириның бу хезмәтен реформа ясау дип бәялиләр. Әлеге яңалыкка руханилар гарәп әлифбасын (Коръән хәрефләрен) бозу дип караганнар, һәм беренче вакытта аваз ысулы белән язу танырга өйрәтү беркадәр кыенлыклар да китереп чыгарган дип уйларга кирәк. 1917 елга кадәр әлифбаның күп тапкыр нәшер ителүе аның җәдит мәктәпләрендә киң таралуын раслый.

Бу уку әсбабының тагын бер өстенлеге һәм яңалыгы була: аның ахырында татар басма китабында беренче тапкыр «Мифтах бадьэ әл-тәгълим» («Башлап укытырга өйрәтү ачкычы») дигән укытучыларга атап язылган методик кулланма урнаштырыла. Соңыннан бу методик кулланма ике тапкыр аерым китап булып та басылып чыга. Бер үк вакытта әлифбада төрки сүзләрдән соң (27 дәрес) гарәп сүзләрен укырга-язарга өйрәтү (16 дәрес) карала, шуның белән укучылар әдәби телдә гарәпчә сүзләрне дөрес укырга һәм әйтергә, дөрес язарга күнегә торган була.

1914 елда 48 битлек «Рәсемле әлифба» нәшер итә. Мөхәммәтхан Фазлуллин фикеренчә, бу әсбап татар телендә дөньяви әлифбаны рәсемнәр белән бирүдә беренче тәҗрибә булып тора. (Беренче рәсемле әлифба Хәбибрахман Зәбири тарафыннан 1907 елда бастырыла).

Таһири 1905 елда нәшер иткән гарәп теле морфологиясе дәреслеге шәкертләр һәм хәлфәләр арасында зур уңыш казана.

Безгә шулай ук Таһириның өй шартларында балаларын укытуны һәм шәкертләрне өйрәтүне күздә тотып язылган өч дини хезмәте билгеле: тәһарәт һәм намаз турында китабы, башлап өйрәнүчеләр өчен сорау һәм җавап кебек төзелгән кыскача Коръәнне дөрес уку кагыйдәләре әсбабы һәм «Тарих исламнан хәлифәи Рәшидетдин заманы» китабы.

Гомеренең соңгы елларында Таһири тагын дүрт уку әсбабы төзи: башлангыч мәктәпләр өчен «Тәгълимат хисаб» («Хисап өйрәтү»), гарәп хәрефләре белән язарга өйрәтү буенча «Матур язу» китабы, «Башлангыч мәктәптә геометрия» һәм урта мәктәп өчен гарәп грамматикасы – синтаксис дәреслеге. Ләкин илдә башланган кискен иҗтимагый үзгәрешләр аларны бастырырга мөмкинлек бирми: совет хөкүмәте яшь буынны тәрбияләү һәм уку-укыту мәсьәләләрен үз кулына ала башлый.

Күпьеллык хезмәтләре өчен Таһири патша хөкүмәте тарафыннан III дәрәҗә Изге Анна, III дәрәҗә кылычлы изге Станислав орденнары, «Тырышлык өчен» көмеш медале белән бүләкләнә.

Октябрь инкыйлабыннан соң да педагогик эшен дәвам иттерә. Казанда һәм Чистайда педагогика курслары оештыра һәм укыта. 1918 елның 27 гыйнварында 59 яшендә вафат була. Казан халкы аны зур ихтирам һәм тантана белән соңгы юлга озата.

Сулдан фото: Таһириның хатыны Гөлчәһрәбану (уртада), кызлары (уңнан сулга) Суфия, Зәйнәп, Өммә-Сәлма һәм Зөһрә. 1914 ел.
Уң яктагы фото: Таһириның уллары. Беренче рәттә (уңнан сулга): Йосыф, Ривгат, Фаик; икенче рәттә (уңнан сулга): Җәвад, Мидхәд, Әхмәтзәки һәм Әхмәтсолтан. 1914 ел.

ТАҺИРИ ӘСБАПЛАРЫНЫҢ СЫЙФАТЛЫ ҺӘМ УҢАЙЛЫ БУЛУЫ ӨЕНДӘ АЛАР БУЕНЧА БАШТА БАЛАЛАРЫН УКЫТЫП КАРАВЫ БЕЛӘН ДӘ АҢЛАТЫЛА. БЕР ӘЛИФБАСЫНЫҢ ТИТУЛ БИТЕНӘ УЛ: «МОНЫ ЯЗДЫМ КЫЗЫМ ЗӨҺРӘ ӨЧЕН, НӘШЕР ӘЙЛӘДЕМ ЗАМАН ГАЛИМНӘРЕ ҮТЕНГӘН ӨЧЕН», ДИП ЯЗЫП КУЙГАН.

РАДИК КУДОЯРОВНЫҢ «КАРА УРМАН»Ы

Татьяна Вафина

Казанда «Кара урман» фильмын күрсәттеләр. Фильм татар шагыйре Муса Җәлил турында. Иҗатын герой-шагыйрьнең батырлыгын, язмышын ачыклауга багышлаган язучы Рафаэль Мостафин озак еллар «Татарстан» журналында баш мөхәррир һәм бүлек мөхәррире булып эшләде, шуңа күрә без бу картинага битараф кала алмадык: бөтен редакциябез белән кино карарга бардык. Алай гына да түгел, бер-беребезгә сораулар бирә-бирә, фильмның режиссёры Радик Кудояров белән кызыклы әңгәмә дә эшләдек.

КАЙСЫБЫЗ КИЛМЕШӘК?

– Ни өчендер фильмны караганнан соң күпләр мине килмешәклектә гаепләде. Сез журналистлардан шуны сорыйсым килә: мондый фильмнан соң иң мөһиме шул борчырга тиешме? Җәлилчеләргә (яки кормашлыларга – болай да, тегеләй дә дөрес дип саныйм) карагыз – бу унбер егет илнең төрле почмакларында туып-үскән. Өчесе – Казахстаннан, берсе – Үзбәкстаннан, кемдер Башкортстаннан, Казаннан, Мәскәүдән. Ә Муса Җәлил үзе - тумышы белән Оренбург өлкәсе Мостафа авылыннан. Аларның кайсысы килмешәк? Кайсыбыз килмешәк?

– Я берсе дә килмешәк түгел, я бөтенесе дә.

– Нәкъ шулай.

ТУЛЫ МЕТРАЖ НИЧЕК ЭШЛӘНДЕ

– Чирек гасыр диярлек документаль кинода, өстәвенә, аның шактый катлаулы өлешендә эшләгән кешегә, баштанаяк шул фактурага, тарихи документларга күмелеп утырганнан соң, аларны читкә этәреп, уен киносына күчүнең никадәр авыр булуын беләсезме?

– Чамалый гына алабыз...

– Ягъни мин үземне үзем документалистикадан тартып чыгардым. Ә моны эшләү җиңел түгел. Мин эксперимент үткәрдем. «Тулы метраж»га кадәр мин тест рәвешендә ике «кыска метраж» эшләдем. 2020 елда беренче «Подарок» фильмын төшердем, пандемиягә дә карамастан, ул бик уңышлы килеп чыкты. Бу уен киносы дөньясына беренче адымым булды, ул булган хәлгә корылган иде. Икенчесе «Аттракцион» фильмы булды. Шул рәвешле «тулы метраж»га якынлаштым. Ягъни бу уен киносына бөтенләй типик булмаган күчеш юлы.

– Ә типик булганы нинди?

– Гадәттә кинематографист үз проектына күп акча сорый. Акча бирелә, әгәр фильм тиешле нәтиҗәгә ирешә алмаса, режиссёр акчаны «үзенә калдырган» булып чыга. Ләкин хәтта уен киносының танылган остасы Вуди Аллен да, хәзер үзем теләгән кадәр финанслау ала алмыйм, дип ышандыра.

Фотолар: Александр Ефремов; Радик Кудояровның шәхси архивыннан

ФИЛЬМДАГЫ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ КҮРЕНЕШНЕҢ ЧЫГАНАГЫН АТЫЙ АЛАМ

– Мине фильмда безгә таныш Җәлилнең булмавында гаеплиләр. «Кара урман» – нәфис фильм, ләкин вакыйгалар барысы да реаль, булган хәл. Бу тарихны яза башлаганда һәм тагын да элегрәк, «Подарок» һәм «Аттракцион»ны төшергәндә, миңа берничә тапкыр җәзалау урынына барырга туры килде, Берлин һәм Шарлоттенбургта да булдым. Шулай ук Маутхаузенга* бардым һәм бу вакыйгалар булган урыннарны карадым, шул исәптән концлагерь белән җитәкчелек иткән штандартенфюрер Цайрес гаиләсе яшәгән йортны да.

Күп еллар элек мин Нюрнберг процессы турында документаль фильм төшердем, һәм минем бу вакыйгага багышланган ике картинам бар, шуның берсе тәмамланмаган. Икенче картинаны төшергәндә процесста турыдан-туры катнашкан төрле кешеләр белән очраштым. Алар арасында мин шәхсән белгән Ричард Зонненфельд, Мишель Данц һәм Маркус Вольф бар иде. Алар барысы да инглизчә иркен сөйләшә, ә Маркус гомумән рус телен дә, инглиз телен дә бик яхшы белә.

Маркус – радиожурналист, ә Ричард Зонненфельд Америка прокуратурасы тәрҗемәчеләре төркеме җитәкчесе иде. Ул җинаятьчеләрдән беренче сорау алуларны тәрҗемә итә, шул исәптән 1945 елда Герингтан беренче тапкыр сорау алуны да. Һәм аларның һәркайсы миңа Нюрнберг турында, матбугатка чыгарылмаган хәлләр турында сөйләде. Реаль вакыйгаларга нигезләнгән картина пәйда булды.

Маутхаузен җитәкчесе тарихын миңа Ричард сөйләде. Фильмның антагонисты тарихы шуннан башланды. Әгәр төп геройлар турында азмы-күпме аңлау туса, антагонистның килеп чыгышы миңа калса шулай ук кызыклыдыр.

– Фильмда явызлар турында күбрәк күрсәтелмиме?

– Калькулятор алып, фильмда ул күренгән секундларны саный аласыз. Бу явыз – җыелма образ. Ни өчен аның исеме Рудольф Фляйшманмы (сүз уңаеннан, фамилиясе «итче» дип тәрҗемә ителә)? Чөнки нәкъ менә шундый исем-фамилияле судья 1944 елның 7 февралендә бөтен төркемгә хөкем карары чыгара. Прагада табылган документта аның фамилиясе генә тора. Тикшерүчеләр аның фамилиясен генә күрә, алга таба беркем дә бернәрсә дә белми. Мин бу судьяны эзләү белән шөгыльләндем. Рудольф Фляйшман 1939 елдан 1945 елга кадәр Германия суд палатасының гади хезмәткәре була. Сугыштан соң 1953 елга кадәр кайдадыр күзгә чалынмый, тыныч кына утыра. Һәм 1953 елда кинәт пәйда була һәм Германиянең көнбатышындагы Бонн шәһәрендә эшли, шәхси адвокатлык практикасы белән шөгыльләнә.

Антагонистның җыелма образын тулыландырган тагын бер персонаж – Германиянең суд палатасы җитәкчесе Роланд Фрейслер. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында ул рус әсирлегенә эләгә, РКП (б) әгъзасы була һәм Советлар Союзына килә, анда 1921 елга кадәр продразверсткада эшли. Фильмда антагонист Мусага: «Мин сезнең революциягезнең бәясен беләм, продразверстка отрядында хезмәт иттем», – ди икән, бу Фрейслер биографиясенең абсолют төгәл өлеше. Соңыннан ул, Германиягә кайтып, нацист булып китә. Шул рәвешле ул Өченче рейхта юстиция җитәкчеләренең берсенә кадәр үсә.

Берничә реаль антагонист бер флешкага җыелган. Бу алымны тәнкыйтьләргә була, шуңа күрә фильмны карыйсы урынга, тырнак астыннан кер эзләргә дә мөмкин…

Бу фильмдагы барлык вакыйгалар кадрда без күрмәгән персонажлар белән дә бәйләнгән. Мәсәлән, боткага кагылышлы хәл – ачтан интеккән әсирләр боткага ташлана һәм ашап үлә. Бу вакыйганы миңа үзе лагерьда утырган туганым сөйләде. Аны доктор коткарып кала. Бу ботканы безнекеләргә чыннан да ашаталар, һәм әсирләр бер-бер артлы үлә.

Яисә Әхмәтнең әле ГУЛАГта ук өшеткән аякларын ачып җибәрүе турындагы күренеш... Бу да уйлап чыгарылган әйбер түгел. Бу Леонид Броневойның туганы сөйләгән вакыйга, ул да, минем фильмдагы героем кебек, бу хәлләрне 30 нчы елларда кичергән.

Мин үз фильмымдагы теләсә кайсы күренешнең чыганагын атый алам.

– Ачтан интеккән әсирләргә ботка китерәләр, алар боткага ташлана һәм ашап үлә. Боткага кагылышлы тарихны миңа үзе лагерьда утырган туганым сөйләде. Аны доктор коткарып калган.



* Маутхаузен – 1938–1945 елларда Маутхаузен (Австрия) шәһәре янындагы немец концлагере. Иң баштан лагерь җинаятьчеләрне, «раса буларак» туры килмәгән гомосексуалистларны тотар өчен төзелә. 1939 елның маенда сәяси тоткыннарга дип үзгәртелә. Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, Маутхаузенга хәрби әсирләр дә китерелә башлый. Биредә 120 меңнән артык кеше җәзалаулардан, күтәрә алмаслык эштән, ачлыктан үлә.. Маутхаузен корбаннары арасында – 30 меңнән артык совет кешесе. Генерал Карбышев та шунда үлә. Лагерь 1945 елның 5 маенда Америка гаскәрләре тарафыннан азат ителә. 1947 елның июнендә элекке концлагерь биредә мемориаль комплекс ачу шарты белән Австрия хакимиятенә тапшырыла. 1949 елның язында Маутхаузен мемориаль комплексының ачылышы уза.

– Яхшылык белән яманлык арасындагы көрәш турындагы тарих универсаль. Мәсәл, гыйбрәтле хикәя. Әгәр барлык бу персонажларны җыеп, аларны Христос туган вакытка яки 2000 елга алга күчерсәк тә, алар арасындагы бәйләнешләрнең асылы үзгәрмәячәк. Аларны теләсә нинди костюмнарга киендерергә була, әмма үзәге, асылы элеккечә калачак. Шуңа күрә бу тарихны гыйбрәтле хикәя буларак аңларга кирәк.

ШИГЫРЬЛӘРНЕ ТӨРМӘДӘН НИЧЕК ЧЫГАРЫРГА?

– Ләкин шулай да фильм ике сәгать ярымлык…

– Фильм озынрак, дип әйтәсегез киләме? Мин биш сәгатьлек фильм төшерергә теләр идем. Миңа картинадан ябыштырылган 30 минутлык материалны кисәргә туры килде! Күз алдына китерә аласызмы?

– Китерәбез. Үзебез дә гел озын текстларны кыскарту белән мәшгуль.

– Юк, бу бөтенләй башка. 21 эш сменасында мин өч сәгатьлек файдалы материал төшердем. Сез күргән сыйфатта. Антагонист белән Муса арасындагы сөйләшү 15 минут дәвам итә. Ә ул сезгә озын булып тоелдымы? Ә анда нәрсә бар? Анда кешенең проблеманы ничек тә булса хәл итәргә тырышуы чагыла – аңа шигырьләрен төрмәдән чыгарырга кирәк, чөнки ул үзенең инде исән кала алмаячагын аңлый. Аның моннан котылырга мөмкинлеге юк, әхлакый яктан да, физик яктан та. Ягъни ул хыянәт итәргә әзер түгел. Ә Фляйшманның бурычы – хөкем карары чыккан булса да, Җәлилне хыянәткә күндерү, чөнки бу башка урыннарда икенче бурычларны хәл итәргә булышыр иде.

Әйтик, Мусаны үз ягына аудару өчен ул нәрсәләр куллана? Төрле психологик алымнарны. Башта ачыктан-ачык, ихлас булырга чакыра. Аннары үзе өчен иң кадерле әйберләрне – коллекциясендәге сирәк китапларны күрсәтә.

Ә арыган, йончыган, инде үлемгә хөкем ителгән Муса барлык бу психологик тәэсирләр вакытында, бәлки, моның ничек тә булса, кемнәрдер аша шигырьләрен төрмәдән чыгаруның бердәнбер юлы булуы турында да уйлагандыр.

Бу турыда өч минут эчендә ничек сөйләп өлгерергә? Бу бит мөмкин түгел. Һәм мондый психологизмнарны экранга ябыштырып куеп булмый бит. Аларны ничектер кертеп җибәрергә кирәк. Актёр да моны уйнарга тиеш. Озак, тиз түгел. Һәм, Аллаһка шөкер, моңа ирештек.

МӘСӘЛМЕ, БОЕВИКМЫ?

– Бу күренештә күпләр Понтий Пилат белән охшашлык күрә…

– Әйе, әмма шулай диюләре бик сәер. Мин Михаил Афанасьевич Булгаковны, аның иҗатын бик яратам. Әмма яхшылык белән яманлыкны Илаһыбыз дөньяга, ким дигәндә, Адәм белән Һава яратылганнан соң ук китергән, дөресме? Шуңа күрә Михаил Афанасьевич сәбәпче түгел, ул бу турыда үзенчә сөйли. Һәм мин – үземчә. Шулаймы? Ә ни өчен? Чөнки яхшылык белән яманлык арасындагы көрәш турындагы тарих универсаль. Мәсәл, гыйбрәтле хикәя. Әгәр барлык бу персонажларны җыеп, аларны Христос туган вакытка яки 2000 елга алга күчерсәк тә, алар арасындагы бәйләнешләрнең асылы үзгәрмәячәк. Аларны теләсә нинди костюмнарга киендерергә була, әмма үзәге, асылы элеккечә калачак. Шуңа күрә бу тарих гыйбрәтле хикәя буларак аңлашылырга мөмкин.

Кайберәүләр фильмда «Тайна вечеря» белән охшашлык күрде, тик мин бу турыда уйламадым. Персонажлар Муса тирәсенә җыела торган кадр турында да. Бу кино магиясе, бары без төзегән локация генә. Әгәр мин, татар халкының бөтен кайгы-сагышын чагылдырырга омтылып, боевик төшергән булсам, фильм бүгенге фактурасында күңелсез булыр иде, дип уйлыйм. Зур фильм күзлегеннән караганда.



– Антагонист белән Муса арасындагы сөйләшү 15 минут дәвам итә. Ә ул сезгә озын булып тоелдымы? Ә анда нәрсә бар? Анда кешенең проблеманы ничек тә булса хәл итәргә тырышуы чагыла – аңа шигырьләрен төрмәдән чыгарырга кирәк, чөнки ул үзенең инде исән кала алмаячагын аңлый.



– Нюрнбергта төп хәрби җинаятьчеләрне җәзалаганда, аларга махсус сюрпризлар оештырганнар. Люк бераз кыскартылган, ә бау алай ук озын булмаган. Бу булган хәл, тик аның турында рәсми рәвештә беркайчан да сөйләмәгәннәр.

НИ ӨЧЕН БЕРӘҮ ДӘ БУ ЕЛЛАР ЭЧЕНДӘ ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ФИЛЬМ ТӨШЕРМӘГӘН?

– Ә хәзер барлык тәнкыйтьчеләргә сорау: Бөек Ватан сугышы тәмамланганга 80 елга якын вакыт узды, ни өчен моңа кадәр беркем дә бу темага бернәрсә дә эшләмәгән? Бу бит сөрелмәгән кыр! Мин әлеге кырга якын килдем – һәм сөрә генә башладым. Шуңа күрә мин моңа тотындым да. Хәзер бездә каз тәне чыгара торган фильм бар. Һәм бу бик яхшы.

СЕЗ КУРКЫНЫЧ ФИЛЬМНАР КАРЫЙСЫЗМЫ?

– Куркыныч фильмдагы кебек каз тәннәре чыгара торган фильм...

– Сез куркыныч фильмнар карыйсызмы?

– Юк.

– Һәм дөрес эшлисез, мин дә карамыйм. Чөнки куркыныч фильмнар – ул коточкыч әйбер, әйеме? Безнең прокатта ничә куркыныч фильм бар? Бихисап. Һәм экранда кан һәм куркыныч күренешләрнең күп булуы беркемне дә борчымый.

Әмма минем фильмда натурализм юк. Мин документаль кинода күп эшләдем һәм төрле әйберләр күрдем. Мәсәлән, кешене асканда, моның ничек эшләнүе турында экспертлар тасвирламасын укыганым бар. Бу чыннан да куркыныч. Әгәр мин мондый фильм төшерергә уйласам, бу бик хәтәр булыр иде. Чөнки берсенең бите яралардан канга баткан, икенчесенеке чалшайган, ә өченчесенең йөзе шабыр тирдә. Менә бу натурализм. Ә сез минем фильмда күргән нәрсәләр – бу бары тик тарих.

Нюрнбергта төп хәрби җинаятьчеләрне җәзалаганда, аларга махсус сюрпризлар оештырганнар. Люк бераз кыскартылган, ә бау алай ук озын булмаган. Бу булган хәл, тик аның турында рәсми рәвештә беркайчан да сөйләмәгәннәр.

Ә БУ КИРӘКМЕ?

– Кайбер әйберләр, бигрәк тә җәзалау күренешләре кирәкми, артыграк кебек...

– Артык шәфкатьсезме? Һәм менә фильмда француз журналисты үзенең инглиз дустына бу нәрсәләрнең артыграк тоелуы турында әйтә... Һәм тамашачылар: «Мөгаен, шулайдыр», – ди. Ә фильм буеннан буена ни өчен кирәкмәве турындагы сорауга җавап бирә. Чөнки бу кешелексез адәмнәр коточкыч җинаятьләр кыла, кеше белән нинди генә кансызлыклар эшләми. Шуңа күрә без: «Егетләр, менә карагыз – менә бу бөтен тарих – ул артык шәфкатьсезлек түгелме?» – дибез. Муса һәм аның иптәшләренең язмышы шундый түгелме? Минемчә, шундый. Дөресме? Менә сезгә җавап.

Ә актёрның йөзенә бераз күбрәк «кан» ягу – нормаль күренеш. Булгалый. Ә башкача ничек эшләргә? Бу бит кино. Әгәр мин бу «канны» күбрәк якмаган булсам яки гримёрым үз эшен җиренә җиткереп эшләмәсә, сез геройга аттылар, ә аның йөзе шул килеш калды дип әйтер идегез. Ул чагында мин профессиональ яктан ялгыш ясаган булыр идем. Ә сезнең куркуыгыз яхшы. Бу бит кино.

Зурлар киносы, балалар киносы түгел. 18+. Минем уйлавымча, Казанда балалар киносын төшерергә теләгән режиссёрлар бихисап. Аларга ярдәм итәргә кирәк, һәм алар Җәлил тарихын балалар өчен дә төшерсеннәр. Мин шатланырмын гына.

НИ ӨЧЕН МИН БУ ТЕМАГА АЛЫНДЫММЫ?

– Безнең шартларда моның шактый проблемалы булачагын белеп, ни өчен мин бу темага алындыммы? Чөнки яткан таш мүкләнә, шуңа күрә бу ташны кузгатырга кирәк. Минемчә, Җәлил–Кормаш төркеме турында гына түгел, алар тирәсендәге хәлләр турында да кызыклы мәгълүмат җыярга мөмкин булыр иде. Чөнки аларга кадәр дә ниндидер вакыйгалар булган, соңрак та. Фильмда мин легионны Франциягә күчергәннәр, дип сөйлим. Ә анда татар легионерлары Каршылык күрсәтү ягында сугышканнар һәм француз хәрби бүлекләре белән бүлекләнгәннәр. Бу «Нормандия-Неман» түгел, юк, киресенчә: француз очучылары безнең якта булганнар, легионнан качкан татарлар да немецларга каршы сугышканнар. Минемчә, бу кызык.

НИ ӨЧЕН ҖӘЛИЛ?

– Беләсезме, ни өчен Җәлилгә алындым? Гаиләбезнең Җәлил белән турыдан-туры бәйләнештә булуын белдем. Мин Мусаның безгә килгәнен ишеткәнем бар иде, ләкин сәбәбен белми идем. Архивта сакланган хатларында торак пункты һәм аның монда нәрсә белән шөгыльләнүе күрсәтелгән. Фильмның барлык версияләрен эшләп бетергәч, мин аның бездә бер генә түгел, ә ике тапкыр – 1930 һәм 1936 елларда булуын белдем.

Тагын бер мөһим момент бар: бәлки, бу фильмны карагач, 18–20 яшьлекләр дә Җәлил лирикасы белән кызыксыныр. Аның бит сугыш чорындагы шигырьләре генә түгел, мәхәббәт лирикасы, шулай ук Ватанга багышланган әсәрләре бар. Җәлил кебек шагыйрьнең безнең гаилә дусты булуы зур горурлык.

– Фильм буеннан буена ни өчен шулай күрсәтелүе турындагы сорауга җавап бирә. Чөнки бу кешелексез адәмнәр коточкыч җинаятьләр кыла, кеше белән нинди генә кансызлыклар эшләми. Шуңа күрә без: «Егетләр, менә карагыз: бу бөтен тарих артык шәфкатьсезлек түгелме?» – дибез. **Муса һәм аның иптәшләренең язмышы шундый түгелме? Минемчә, шундый. Дөресме? Менә сезгә җавап.**

ФИЛЬМ ТУРЫНДА ФИЛЬМ БУЛАЧАКМЫ?

– Фильм турында фильм өчен дә материалларым бар. Төшерү вакытында махсус кеше бөтен бэкстейджны төшереп барды. Фильм турында фильм булырмы – анысын белмим. Дөресен генә әйткәндә, тамашачының фильмга мөнәсәбәтеннән бераз күңелем кайтты. Ничектер сәер. Картина төшерелде – рәхмәт кенә әйтегез. Шул җитә.

Минем 2005 елда Маккартни турында фильм төшерү тарихы бар («Алиби для Пола Маккартни». – Ред.иск.). Лондонда һәм Америкада бу вакыйгада турыдан-туры катнашкан кешеләр катнашында төшердем. Маккартнины, имеш, автокатастрофага эләккәч, аңа охшаган кеше белән алыштырганнар. Киң таралган уйдырма. Мин бу имеш-мимешне уйлап тапкан, бөтен материалны җыйган кешеләрне дә белә идем. Маккартни үзе дә моның бары тик легенда гына булуы турында бер кешегә сөйләгән. Ул кешене дә белә идем. Һәм фильмга мин боларның барысын да керттем. Һәм бу әлегә кадәр эшләнгән барлык фильмнарым арасында иң яратканым. Мин бу темага мюзикл төшерергә телим.

Радик Кудояров Әхмәт һәм Циклоп белән фильм төшерү арасындагы тәнәфестә.

Ләкин фанат кайда да фанат. Һәр фанатның үз герое бар – Пол Маккартни, Рудольф Нуриев, башкалар... Мин бу фанатлар бандасы белән бөтен дөнья буйлап таныш. Һәм алар: «Гомумән нәрсә бу? Тагын нәрсә төшергән? Җыен юкбарныдыр инде», – диләр. Алар үз форумнарын оештырганнар, миңа да яздылар, ачуланып, мыскыллып. Тик арадан берсе: «Дуслар, туктагыз! Әйдәгез, безгә фильм төшергәне өчен бу кешегә рәхмәт әйтик, ул безне яңадан яраткан темабызга кайтарды. Без шул турыда кызып-кызып фикер алышабыз бит», – диде. Минемчә, бер генә шундый комментарий өчен дә фильм төшерергә була. Аңлыйсызмы?

– Ни өчен фильм начар кабул ителде дип уйлыйсыз?

– Мин үземнең социаль челтәрләремне күзәтәм, тәнкыйть укыйм, тискәре бәяләмәләрне күрәм, гәрчә алар реаль вазгыятьне чагылдыра дип санамасам да. Фильмның начар булуын теләмәдем, мин аны булдырырга гына тырыштым. Уен киносы төшерүче кешеләрне дә беләм, алар тәнкыйтькә битараф карый. Тик миңа барыбер түгел. Минем белән очрашырга, миңа шалтыратырга яки язарга мөмкин – һәрвакыт нәрсәдер сорарга була. Мин җавап бирәм, аңлатам. Ә нигезсез тәнкыйть – дөрес түгел. Тәнкыйтьләгәнче, алар бераз гына булса да шуңа охшаган әйбер эшләп карасыннар иде.

УЕН КИНОСЫ БУЛАЧАКМЫ?

– Уен киносы – зур җаваплылык. Карарга җиңел. Ә төшерү авыр. Тагын төшерерменме – белмим... Чөнки бу тоташ контроль дигән сүз, аңлыйсызмы? Идеядән алып җитештерүгә кадәр – барысын да контрольдә тотарга кирәк. Һәм хәтта сез төшерергә акча алгач та, бу юлның башы гына әле. Хәзер сезгә үзегез уйлап тапкан нәрсәләрне җитештерүне оештырырга кирәк. Ә бу җиңел әйбер түгел.

Үземнең әзер икәнлегемне аңламыйча, мондый фильмнарны төшерергә башка алынмас идем. Барысын да үзең аша үткәрү һәм башка

Радик Кудояров фильны төшерү вакытында артистлар белән. Муса төркемен «җәзалаучылар» белән. Унда - палач Йоханн Райнхарт прототибы.

кешеләрнең язмышы өчен җаваплылыкны үз өстеңә алу – бу үтә катлаулы.

Фильмда Маутхаузен башлыгының ничек күңел ачканын күрсәтергә тырышып карадым. Ул кешеләрне кыядан таш чыгара торган упкынга ыргыткан. Беренче корбаннар 1940 елда ук булган, безнең ил әле сугышка кушылмаган чакта, ә Британия парашютчылары үз илләре өчен сугышканнар инде. Аларны оккупацияләнгән Голландия территориясендә шул илнең добровольцлары белән бергә тоткарлыйлар һәм кыяга алып киләләр. Бу урын «парашютчылар стенасы» дип телгә кереп кала.

Һәм менә син шунда, шушы стена янына киләсең, әмма теге штандартенфюрердан аның моны ни өчен эшләгәнен сорый алмыйсың. Ләкин аның кыяда булганын төгәл беләсең. Корбаннар булганын да төгәл беләсең: Британия парашютчылары, аннары безнекеләр. Тик хәзер монда беркем дә юк, тынлык, ә сиңа диалог язарга кирәк, кино бит телсез түгел. Аларның шул вакытта нәрсә хис итүләрен, кичерешләрен күз алдына китерергә кирәк. Һәм син шушы таш чыга торган җирдә басып торасың, синең өстә шул ук кыя – боларның барысын да күз алдына китерергә, шунда «яшәп карарга» һәм экранда күрсәтергә кирәк. Минем яраткан операторым, мәрхүм Сергей Воронцов, экран һәрвакыт җитешсезлекләрне күрсәтә, дия торган иде. Шуңа күрә барысы да югары дәрәҗәдә эшләнергә тиеш.

МИН ЯРАТКАН КИНО

– Барысы да югары дәрәҗәдә эшләнгән яраткан киногыз?

– Мин киноны хәзер сирәк карыйм. Балалар белән кинога бара идем, әмма алар да инде үсеп җитте... Кайчак иске фильмнарны яңадан карыйм, алар чыннан да сыйфатлы. Яраткан фильмнарым турында күп сөйли алам. Михаил Казаков фильмнарын яратам. Миңа Костолевский укытучы ролен уйнаган «Безымянная звезда» ошый. Еш кына «Покровские ворота»ны яңадан карый алам. Броневойны бөтен гаиләсе белән яратабыз.

БЕР МИЗГЕЛ КҮПМЕ ТОРА?

– Гомеребезнең бер мизгелен күпмегә бәялибез?

– Андый валюта юк шул.

– Ул бәһасез, дөресме? Мин бу картинаны төшерү өчен дүрт елга сузылган кыйммәтле секундларымны сарыф иттем, әзерлекне һәм ике тест рәвешендәге «кыска метраж»ны да кертеп. Гадәттә бездә алай эшләмиләр: беркем дә тулы метражлы фильмнарны сынап карамый.

Минем максат реаль фаҗигалəр фонында нуар белән чиктәш диярлек алымнарны куллану кызыклы һәм аңлаешлы булырмы икәнен аңлау иде. Минем моның, әйтик, чит ил тамашачысына кызык булырмы-юкмы икәнлеген дә беләсем килде. Шуңа күрә мин фестивальләрдә тест рәвешендәге фильмнарым белән катнаштым, ләкин җиңүчеләр исемлегенә эләгү һәм стенага тагын бер диплом элеп кую өчен түгел. Иң мөһиме – профессионалларның һәм гади тамашачының картинага реакциясен күрү. Фестивальгә килеп, тамашачы мәхәббәте призын алу формаль нәрсә түгел. Тамашачы чыннан да тавыш бирә, үз белгесен куя, һәм бу чын бүләк.

«Кара урман»ны чит илләрдәге дусларыма һәм танышларыма җибәрдем. Алар аны кызыксынып карый. Ачыктан-ачык әйтүем өчен гафу, ләкин битараф кешеләр юк. Шуңа күрә без куркыныч фильм төшермәдек. Без аны тагын да фаҗигалерәк булган чынбарлыкка якынлашып төшердек. Күңелләрне артык актартмасын өчен, мин натурализмны булдыра алган кадәр киметтем. Ләкин миңа тамашачының немец хәрби җинаятьчеләренә карата ни өчен шундый рәхимсез мөнәсәбәт күрсәтүләре турында уйлануына ирешергә кирәк иде. Чөнки Муса һәм бу унбер егетнең язмышы – төрле илләрдә нацизм китергән миллионлаган корбанның бик аз өлеше генә. Һәркемнең үз тарихы, һәм һәр корбан нindидер бер гаилә өчен иң якын һәм иң фаҗигале язмышка әйләнә. Ә бу асылган унбер (шулай ук унбер!) фашист җинаятьчесенең бу фаҗигаләргә турыдан-туры катнашы булган.

Миңа тамашачының немец хәрби җинаятьчеләренә карата ни өчен шундый рәхимсез мөнәсәбәт күрсәтүләре турында уйлануына ирешергә кирәк иде. **Чөнки Муса һәм бу унбер егетнең язмышы – төрле илләрдә нацизм китергән миллионлаган корбанның бик аз өлеше генә.** Һәркемнең үз тарихы, һәм һәр корбан нindидер бер гаилә өчен иң якын һәм иң фаҗигале язмышка әйләнә. Ә бу асылган унбер (шулай ук унбер!) фашист җинаятьчесенең бу фаҗигаләргә турыдан-туры катнашы булган.

ИҢ МӨҺИМЕ

– Тормышта иң мөһиме нәрсә икәнен беләсезме? Безнең тормышта иң мөһиме кайсы милләттән булуыбыз, үзебез өчен үзебез уйлап тапкан нәрсәләр түгел. Иң мөһиме – бу тормышта кылган гамәлләребезгә хисап бирү. Чөнки бу үзебез белән алып китәчәк бердәнбер әйбер. Шуңа күрә әйдәгез тарихны онытмыйк – ул нинди булса, шундый. Яки әйдәгез без онытырга теләгән темаларның исемлеген язьйк: революция, ачлык, Гражданнар сугышы, репрессияләр. Әйдәгез ак биттән башлыйкмы? Шәп булыр иде. Ләкин тарих яңадан язылмый, ә аны бозып күрсәтергә тырышу – көчсезләр яки ярaклашырга тырышучылар гамәле. Шуңа күрә тарихка хөрмәт белән карыйк, үзебез кичергән тәҗрибәгә таянып, киләчәктә хаталар кылмыйк.

редакция кухнясы

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

ВАСИЛИЙ ДЕМЬЯНОВТАН КЫТАЙ ПИЛМӘННӘРЕ

Николай Крушинин

БРИКС якыная барган саен, берәр «БРИКС»лырак ризык – Бразилия, Эфиопия, Һиндстан, Иран сыен ныграк татып карыйсы килә. Кытай пилмәннәре нәкъ менә шундый шартка туры килә. Өстәвенә, аларны авыз итәргә «Китайская пельменная» рестораны идарәчесе Василий Демьянов чакыра.

БЕРКАЙЧАН ДА «АЛАЙ БУЛМАЯЧАК» ДИМӘ

– Ресторан бизнесы белән шөгыльләнермен дип һич уйламаган идем, кытай ресторанын әйтсәс дә юк, – ди ихластан Василий Иванович, «Татарстан» алъяпкычын япкан арада. – Гомеремнең күп өлешен Татарстанның Экология министрлыгында хезмәт куйдым, уңышлы карьера ясадым, пенсиягә чыкканчы диярлек шунда эшләдем.

Ләкин мин энергияле кеше, беркайчан да эшсез утыра белмәдем. Эш миңа һәрвакыт көч-дәрт бирә, һәм менә хәзер берәр яңа нәрсәне сынап карарга вакыт дигән карарга килдем.

Берничә ел элек киявем Казан үзәгендә үзенең беренче «Китайский дворик» ресторанын ачты, һәм бу сыйханә Кытай кухнясын яратучылар арасында бик популяр булып чыкты. Аннары «Китайская утка» дип аталган тагын бер ресторан ачылды, аңа да мактау сүзләре күп әйтелде. Күпмедер вакыттан соң мин дә үземне бу юнәлештә сынап карарга булдым, ә тәҗрибә, минемчә, бары тик эш барышында гына туплана.

КЫТАЙ ОСТАЛАРЫ ГЫНА ПЕШЕРӘ!

– Хәзер Казан үзәгендә сезнең кытай ресторанныарының тулы бер челтәре эшли! Кытай кухнясы белгечләрен каян табып бетердегез? Кытайның үзенә калдырдыгызмы соң?

– Һәр эштәге кебек үк, башта үз кыенлыклары булды. Барысы да чын оста булган профессиональ ашчылар эзләүдән башланды. Кайсы гына ресторанны алма, уңышы нәкъ менә ашчының осталыгына бәйле бит. Без нәкъ шундыйларны таба алдык! Һәм алар ярдәме, тырышлыгы белән сыйханәләребез челтәрен киңәйтүгә ирештек.

Безнең ресторанннарны челтәр дип санау дөрес түгел, чөнки аларның һәркайсының үзенчәлеге, анык йөзен билгеләгән ризыклары һәм билгеле бер концепциясе бар. «Китайский дворик»та, мәсәлән, зур компания белән вакыт үткәрергә һәм кытайларның кунакчыллыгын тулысынча тоеп, бай кытай кухнясының бик күп затлы да, гади дә ризыкларын татып карарга була.

«Лапшичная» дигәнендә гомерне озынайтырга сәләтле токмач белән тиз генә тамак ялгап алырга, ә «Китайская пельменная» дип аталганында шулпалы кытай пилмәнен авыз итәргә мөмкин.

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН

«ТОКМАЧЛЫ ЭКВИЛИБРИСТИКА» МОГҖИЗАЛАРЫ

Һәм без шулай эшлибез дә. Башта «Лапшичная»га юл тотабыз, андагы аш-су остасы Лю безгә «токмачлы эквилибристика» могҗизаларын күрсәтә: токмач буласы камыр Василий Иванович әмерен ишетүгә, «токмач остасы» кулында оча, сузыла-тартыла башлый. Ә бу тамашаны шаккатып күзәткәннән соң, «Синьхуа» мәгълүмат агентлыгының Азия-Европа бюросы баш мөхәрриренең беренче урынбасары, Казанга БРИКС саммитын әзерләү өчен килеп, «Лапшичная»га тамак ялгарга кереп чыккан Лю Кай белән әңгәмә коргач, Кытай пилмәннәрен пешерергә өйрәнер өчен, «Китайская пильменная»га юнәләбез.

ПИЛМӘН ФӘЛСӘФӘСЕ

Юлда чакта Василий Ивановичтан кытай мәдәниятендә бу ризыкларның әһәмияте һәм кыйммәте турында бик күп нәрсәләр белдек.

– Без һәр ресторанныбыз белән әнә шул кытай ризыклары арасында ныклы ассоциация булдырырга телибез, – ди ул. – Кытайда Ланчжоу ламянь токмачы иң популяр өч фастфуд ризыгының берсе санала, аның бик күп вариацияләре бар, бу – тулы бер кулинар концепция, алай гына да түгел – ашауэчү культурасы!

Кытай пилмәннәрен әзерләүнең дә, үз чиратында, аерым бер фәлсәфәсе бар – кытайлар һәрнәрсәгә сакраль мәгънә бирергә ярата: мәсәлән, Кытайда пилмәннәр гаиләне берләштерә, ныгыта дип санныйлар. Гаилә – әйтерсең, ризыктагы сыман «эчлек» ул, ә эчлек, беләсез, төрле булырга мөмкин, ләкин камырга салынган фарш кебек, бер түбә астында җыелырга тиеш. Биредә тәкъдим ителгән күп төрле эчлекләр арасыннан без үзебезгә якын булган суганлы сыер ите пилмәннәрен сайладык.

Пилмән остасы Ван күз иярмәс тизлектә уклавы белән берьюлы 5 түгәрәк җәя! Һәм без Василий Иванович белән аһ-ваһ килеп классик пилмән ясаган арада, ул кабырчыкка охшаган бер контейнерны пилмәннәр белән тутырып та куя.

Моны күргәч, кулларыбызны юабыз да «Оста барда кулың тый, белгән барда телең тый» мәкален искә төшерәбез.

КӨНДӘШЛЕКМЕ ЯИСӘ «КӘГАЗЬ БОТКАСЫ»МЫ

Һәм кытай «кабырчыклары» пешкән арада, Кытайда ресторан бизнесының Россиядәгедән ни белән аерылуы турында сөйләшәбез.

– Кытайда ресторан бизнесын алып бару тәҗрибәм беркайчан да булмады, – ди Василий Иванович. – Әмма Кытайда көндәшлеккә бәйле бик зур кыенлыклар бар, дип әйтә алам. Ә Россиядә рестораннар үз чиратында күпсанлы «кәгазь боткасы» һәм персоналның тотрыксызлыгы кебек проблемалар белән очраша.

Чит ил ашчылары эшли торган оешма хуҗалары үз өстенә өстәмә бурычлар ала, җаваплылык та, һичшиксез, икеләтә арта. Әмма мондый сыйханәләрнең үзенчәлеге чит ил профессионалларын җәлеп итү ихтыяҗын тудыра. Башка чара юк.

КЛИЕНТ ИХТЫЯҖЫНА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫРГА КИРӘК

– Кафе-рестораннарыгызның клиентлары кемнәр – кытайлармы? Россия кешеләреме? Татарстанлылар кытай кухнясы белән нинди ризыклар аша таныша?

– Безнең рестораннарга килүчеләр арасында кытайлар да, россиялеләр дә аз түгел. Кытайлар өчен алар – үзеңне өйдәге кебек хис итү мөмкинлеге, ә россиялеләр үзләре өчен яңа гастрономик офыклар ачарга, ниндидер гадәти булмаган нәрсә татып карарга тели. Кытай кухнясында сез һичшиксез тагын-тагын ашап карарга теләгән ризык табачаксыз.

Россиялеләр, мәсәлән, еш кына ашамлык бик борычлы булырга мөмкин, дип курка. Бу һәрвакытта да алай түгел – хезмәткәрләребез кунакларга ашамлыкның борычлы булуы турында кисәтә, «яндыру дәрәҗәсе»н алар теләгәнчә киметергә тырыша. Бездәге халыкта пекинча үрдәк һәм гобаожоу чебие аеруча популяр.

– Сезнеңчә, Россиядә мондый бизнес уңышка ирешергә мөмкинме?

– Әгәр барысын да җентекләп уйлап эшләсәң, ник булмасын, ди. Әлбәттә, абынусөртенүсез бармас, әмма бизнес ул һәрвакыт тәвәккәллек сорый. Клиентның ихтыяҗына игътибарлы булырга кирәк, безнең эш шуңа нигезләнә дә инде.

Сулдан уңга: «Китайская пельменная» ресторанны идарәчесе Василий Демьяновтан классик пилмән, баш ашчы Ваннан кабырчыксыман кытай пилмәне, «Татарстан» журналының баш мөхәррире Татьяна Вафинадан сырлап-бизәп ясаган пилмән.

КИЛӘЧӘККӘ ПЛАННАР

Кайнар пилмәннәр табынга килгән арада, киләчәккә планнар турында сөйләшеп алабыз.

– Һичшиксез, киңәю-зураю турында уйлабыз, – ди Василий Иванович. – Без киләсе сыйханәнең яңа концепциясен төзү юнәлешендә актив эшлибез, күпләр яратып өлгергән рестораннарыбызның абруен сакларга тырышабыз.

Кытай кухнясы шулкадәр бай һәм күптөрле ки, илебез халкының күңелен яңа урында нинди ризык белән яуларга икәнен билгеләү шактый авыр мәсьәләгә әйләнә ала. Шулай ук квалификацияле һәм оста ашчылар да сайлау зарур, бу бик җиңел түгел – кунакларыбызга тугры калырга кирәк, чөнки алар да безне яратып килә бит!

Кытайда пилмәннәр гаиләне берләштерә, ныгыта дип саныйлар. Гаилә – әйтерсең, ризыктагы сыман «эчлек» ул, ә эчлек, беләсез, төрле булырга мөмкин, ләкин камырга салынган фарш кебек, бер түбә астында җыелырга тиеш.

ПИЛМӘНСЕЗ БУЛМЫЙ!

– Василий Иванович, ә үзегез кытай ризыкларын яратасызмы? Аеруча яраткан ризыгыгыз бармы?

– Әлбәттә, яратам! Кытай кухнясы шулкадәр күптөрле, хуш исләргә һәм тәмнәргә шулкадәр бай, кайчак күнеккән ризыгыбызга кире кучү авыр да була. Маринадланган чеби дисеңме, пекинча пешерелгән итме, кыздырылган токмачмы– бик борычлы булмаса, мин барысын да диярлек яратам, һәм, әлбәттә, пилмән – ансыз була димени!

– Үзегез берәр кытай ризыгын әзерли аласызмы?

– Була! Әлбәттә, сүз берәр гади нәрсә турында бара, мәсәлән, пилмәнне җиңел генә ясап, пешереп бирә алам! Кытай остасы кебек тиз булмаса да. Минә үзем ясаган пилмән әлэкте! Ә калган ризыкларга килгәндә, ашчыларыбыз белән ярышу авырга туры киләчәк. Ә менә татар ризыкларын бик ансат әзерләр идем! Ләкин миңа бу бик сирәк эләгә.

МИЛЛӘТАРА АРАЛАШУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

– Ашчылар белән ничек сөйләшәсез соң? Кытайча беләсезме?

– Хезмәткәрләрем мине бик яхшы аңлый – күбесе шушы еллар эчендә русча сукалый башлады, шуңа күрә миңа кытай телен өйрәнүнең әллә ни кирәге юк. Әлбәттә, егетләр миңа кайбер кытайча гыйбарәләрне өйрәттеләр. Алар белән мөнәсәбәтләребез бик җылы, бик якын. Гомумән, бу халык белән танышлыгым бик күптәннән килә. Беренче кытай кешесе белән тормыш мине армиядә чакта ук очраштырды, Маньчжурия чигендә хезмәт иткән чагым иде... Шуннан бирле күпме сулар акты. Бу кешеләр белән көн саен аралашу мөмкинлегеннән чыгып, мин аларның гаҗәеп акыллы һәм хезмәт сөючән булуын әйтә алам. Моны бүген дә күреп торам. Мин барлык халыкларга һәм аларның мәдәниятләренә, шул исәптән кытайларныкына да, һәрвакыт тирән хөрмәт белән карыйм.

Җәябез

Эчлек салабыз

Бөрәбез



Пешерәбез

ЯҢА ГЫНА ЭШЛИ БАШЛАГАН РЕСТОРАТОРЛАРГА ВАСИЛИЙ ДЕМЬЯНОВТАН КИҢӘШ:

– Эш башларга курыкмагыз! Әйткәнемчә, тәҗрибә процесс барышында туплана. Тәвәккәл һәм рациональ булу да җитә. Сынап караудан курыкмаска кирәк – бу бүген генә уйлап чыгарылган кагыйдә түгел.

Соңгы вакытта бизнесның кайсы да җиңелләрдән саналмый, әмма сез намуслы һәм үз эшегезне яратасыз икән, юлыгызда очраган барлык кыенлыклар өстәмә тәҗрибә генә булачак.

ӘДӘБИ МАРШРУТЛАР, ЯКИ КЕШЕДӘГЕ КЕШЕ ҺӘМ ИМАН ХАКЫНА

Луиза Янсуар

Көз – басулардан гына түгел, ә мәдәният кырларыннан да уңыш җыеп алу вакыты. Әйтик, Нобель комитеты октябрь аенда, традиция буенча, быелгы әдәби премиягә кем лаек булуын игълан итә. Аңа кадәр букмекерлар инде фаворитлар исемлеген туплаган, фаразлар корып өлгергән була. Көзен шулай ук Россиянең мәртәбәле премиясе – «Ясная Поляна» җиңүчеләре дә игълан ителә. Җиңүчеләр арасында безнең китап киштәсендә китапларына күзәтү ясалган авторлар да бар.

ДАИМИ ҺӘМ ЯҢА ФАВОРИТЛАР

Нобель премиясенең бирелүе, аңлашыла ки, ничек кенә «ирекле» саналмасын, һәрчак сәяси һәм иҗтимагый агымнар, үзгәрешләр, дөнья аренасындагы вакыйгалар куемтысы белән бәйле булды. Бер гасырдан артык гомер эчендә рус әдәбияты вәкилләреннән, ягъни Россия һәм СССР авторларыннан, советлардан соңгы чор язучыларыннан аны 6 кеше алды: Иван Бунин, Борис Пастернак, Михаил Шолохов, Александр Солженицын, Иосиф Бродский, Светлана Алексиевич. Сәясәт тә, вазгыять тә үзгәреп тора, әмма әдәби өлкәдә нинди генә спекуляцияләр, манипуляцияләр булмасын – бер нәрсә үзгәрешсез кала бирә: чын әдәбиятны вакыт та, без – адәм балаларының чикләүләре, читләүләре дә юкка чыгара алмый.

Быелгы букмекерлар исемлегендә киң катлам русча укый торган укучыга бөтенләй билгеле булмаган, шулай ук еллар дәвамында исемлектән төшмәгән язучылар да бар иде. 20 дөньякүләм актив яза торган авторлардан төзелгән ул. Әйтергә кирәк, язучының чын-чынлап шәп автор икәнен, «бөеклеген» билгеләми Нобель, аны алмаган гаҗәеп язучылар бихисап. Әмма ул, һичшиксез, дөньядагы агымнарның, маршрутларның нинди юнәлеш алуын, безгә карашыбызны бу юлы глобустагы кайсы почмакка юнәлтәсен күрсәтә.

2024 ел исемлеген ачып җибәргән автор – Австралиядән отшельник-язучы Джеральд

Фото: goodfon.ru, godliterature.ru, livelib.ru

Марнейн. Ул бу исемлектә моңарчы да күренгәләде. Кызганыч, рус теленә әле тәрҗемә ителмәгән, аны инглиз телендә укырга була.

Икенче урында – Кытай язучысы, альтернатив, экспериментал проза вәкиле Цань Сюэ *(чын исеме Дэн Сяохуа)*. Нәкъ менә аңа ставкалар зурдан иде. КХР да туып үскән бу авторның язмышы аяныч һәм гыйбрәтле. Әтисе, марксизм тарафдары, «Яңа Хунань» газетасының баш мөхәррире әнисе корректоры була, кыз зыялы гаиләдә туып үсә. Әмма «уң элементларга каршы кампания» башлангач, әти-әнисен кулга алалар, төзәтү эшләренә озаталар. Балалар, әбиләре карамагына калып, ул үлгәч, ачлыкка чыдый алмыйча, үлән сабаклары, тамырлар, хәтта өйләрендә калган иске пәлтәләрне сүтеп ашап көн күрә. Белем алырга мөмкинлеге булмаган Дэн Сяохуа, башлангыч мәктәптән соң, заводка эшкә керә, «китаплар укыр өчен» үзлегеннән инглиз телен өйрәнә, лицензиясез «яланаяклы табиб» булып эшли, балалар укыта. Ахыр чиктә, тегү цехы ачып җибәрә.

Әдәбиятка 80 нче елларда килә. Иҗатына зур йогынтыны Толстой, Шекспир, Данте һәм Кафка ясады, дип исәпли. Йөзләп китап авторы, әсәрләре инглиз, француз, немец, итальян, япон телләренә тәрҗемә ителгән. Пекинда яши.

Рус теленә тәрҗемәдә кечкенә генә хикәясе бар. 2015 елда «Последний любовник» романы «иң яхшы тәрҗемә әсәре» буларак таныла, ә «Любовь в новом тысячелетии» романы белән «Я живу в трущобах» хикәяләр җыентыгы өчен, Халыкара Букер премиясенә тәкъдим ителә.

Быелгы фаворитлардан өченче урындагы автор – шулай ук Австралиядән, Алексис Райт исемле язучы. Ул материкның тамыр цивилизациясе һәм мәдәнияте вәкиле – әнисе Ваани аборигеннары ыруыннан. Райт нәкъ менә тамырлар һәм экспансия, тартып алынган җирләр турында яза да. Русчага бөтенләй тәрҗемә ителмәгән.

ИСЕМЛЕКТӘ ЕЛЛАР БУЕ ЙӨРИ ҺӘМ, ЛЕОНАРДО ДИ КАПРИО «ОСКАР»ГА ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ-ИТЕЛӘ МЕМГА ӘЙЛӘНГӘНДӘЙ, ИНДЕ ЕЛМАЮ УЯТА ТОРГАН ИСЕМНӘР ДӘ БАР: ХАРУКИ МУРАКАМИ, ТОМАС ПИНЧОН, МИШЕЛЬ УЭЛЬБЕК, САЛМАН РУШДИ, МӘСӘЛӘН.

Узган ел Нобельне Норвегия язучысы Юн Фоссе алды. Быелгы исемлектә, аеруча беренче өчлектә, Нобель комитеты яраткан темалар һәм шартлар, факторлар өстә үк калкып яткан авторлар бар. Бигрәк тә Цань Сюэ бу шартларга туры килә кебек. Сәяси яктан да, биография детальләре белән дә, Кытайның бүгенге халыкара аренадагы фокусы ягыннан да.

Әмма Нобель комитеты, шаккаттырмаса, Нобель комитеты булмас иде. Быел ул, көтмәгәндә-уйламаганда, фаворитлар исемлегендә бөтенләй күренмәгән (гәрчә Букер Нобельгә юлны ача дип исәпләнсә дә), фаразланмаган Көньяк Корея язучысын, чагыштырмача яшь авторны (53 яшь), «ак булмаган» хатын-кызны сайлады һәм игълан итте.

«ТЫГЫЗ ШИГЪРИ ПРОЗА, ТАРИХИ ҖӘРӘХӘТЛӘРГӘ КАРШЫ ТОРУ ҺӘМ КЕШЕ ГОМЕРЕНЕҢ УАЛУЧАН КАДЕРЕН СУРӘТЛӘҮ ӨЧЕН»

Әнә шундый Хан Ган иҗатына Нобель комитетының билгеләмәсе. Новаторлыгы белән экспериментал өслүбе турында да искә ала Нобель экспертлары. Ә иң мөһиме – бу прозаның иске кануннар белән яшәмәскә, әзләнүчән, таралучан, агучан, башка логикага корылучан булырга мөмкинлеген, яңарышка хокуклы икәнен тану.

Әйтергә кирәк, атна-ун көн эчендә маркетплейслар белән китап платформаларында Хан Ган китапларын кырып диярлек заказ биреп алып бетерделәр. 2017 елда беренче мәртәбә рус телендә басылып чыккан романы – «Вегетарианка»ны бигрәк тә. Без аның турында русча басылып чыккан елны ук киштәдә язган идек (табып укырга мөмкин).

Хан Ган – күренекле язучылар гаиләсеннән, әтисе белән абыйсы да яза. Бүгенге Корея әдәбиятындагы иң күренекле вәкилләрнең берсе. Карап торышка, үтә тыйнак, сабыр, тыныч холыклы күренгән бу мөлаем ханым тудырган әсәрләр бөтенләй икенче – аларда гыйсъян да, золым да, кан да, көрәш тә, хәсрәт тә, системалар белән кануннарга каршы тору көче дә бар. Үз илендә әсәрләре бигрәк тә зур тәэсир итү көченә ия, диләр: гаҗәеп шигъри,

ХАН ГАН – НОБЕЛЬ ПРЕМИЯСЕНӘ ИЯ БУЛГАН ТАРИХТАГЫ 18 НЧЕ ХАТЫН-КЫЗ. БУ ПРЕМИЯ, ӘЛБӘТТӘ, ДӨНЬЯКҮЛӘМ ТРЕНДНЫ АЕРМАЧЫК КҮРСӘТЕП ТОРА: АЗИЯ ӘДӘБИЯТЫНА БУЛГАН КЫЗЫКСЫНУНЫ ДА, XXI ГАСЫРДА, НИҺАЯТЬ, ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ ДӨНЬЯНЫ НИЧЕК КҮЗАЛЛАВЫ, СУРӘТЛӘВЕНӘ ЙӨЗ БЕЛӘН БОРЫЛУНЫ ДА, ХАТЫН-КЫЗЛАРГА КАРАТА БУЛГАН БАСЫМ, ҖӘБЕР, КӨЧ КУЛЛАНУ ТЕМАСЫННАН КАЧМАСКА ӨНДӘҮНЕ ДӘ.



лирик, сыгылмалы, йә булмаса махсус коры, сынык, саран тел белән Хан Ган коточкыч вәхшилекләрне һәм травмаларны сурәтли, кеше тормышын сындыра-вата торганнарны да, тулы бер илләрне, дәүләтләрне җимерә, харап итә торганнарны да. «Лирик шәфкатьсезлек» дип тә атыйлар Хан Ган стилен.

1970 елда Кванджу шәһәрендә дөньяга килә ул. Ёнсе университетында Корея әдәбиятын өйрәнә. Шигырьләрдән башлый, аннары прозага күчә. 2013 елдан Сеул сәнгать институтында язучылык буенча курслар алып бара.

2007 елда басылып чыккан «Вегетарианка» язучылык карьерасындагы иң атаклы әсәре. Аны «бомба»га тиңлиләр: хатын-кыз язучы кинәт кенә патриархаль конфуцианлык хөкем сөргән җәмгыятьтә тән һәм аның ихтыяҗлары бунты, гаиләдә психологик һәм физик көч куллану, җәмгыятьтәге каршылык һәм череп барган кануннарның мәгънәсезлеге турында яза. Кызыл җеп булып «Кешеләр, сез нигә шулкадәр кансыз соң?» дигән сорау сузыла. «Уңайсыз» роман зур бәхәсләр тудыра, ләкин нәкъ менә шушы романнан соң аны чын-чынлап ябырылып укый башлыйлар. Чит телләргә тәрҗемә итә дә. Букерны да, инглиз теленә Дебора Смит тәрҗемә итеп, «Вегетарианка» өчен ала Хан Ган. Рус теленә турыдан-туры корея теленнән романны Петербургта яшәүче Ли Сан Юн тәрҗемә итә.

2010 елда Хан Ган күләмле, катлаулы «Дует ветер, иди» әсәрен тәмамлый. 2014 елда иң әрнеткеч һәм авыр әсәрләренең берсен язып бастыра – рус теленә тәрҗемәдә ул «Человеческие поступки» атамасы белән билгеле, оригиналда исеме – «Мальчик приходит», яки «Приходящий мальчик». 2017 елда «Белый» романы басыла. Иң соңгы дөнья күргән романы – 2021 елда чыккан «Мы не прощаемся».

КЕШЕ ГАМӘЛЛӘРЕ, ҺӘМ «МАЛАЙЛАР» ФАҖИГАСЕ

Хан Ган өчен әсәрләренең һәрберсе аша кистереп үтә, җәрәхәте йомылмый торган тема – 1980 елның 18–27 маенда Көньяк Кореяда узган канлы Кванджу фетнәсе. Китапларын укыганда шундый тойгы уяна: әйтерсең, ярты гасыр узмаган, без һаман да ул чактагы сабый кыз белән шунда – кан коеш уртасында басып торабыз.

Чон Ду Хван идарәсе вакытында Кванджу вакыйгалары прокоммунистик фетнә дип каралса, соңыннан демократия урнаштыру омтылышы буларак бәяләнә башлый. Дәүләт баш күтәрүләрне рәхимсез бастырганы өчен халкы алдында гафу үтенә. Корбаннар өчен зират комплексы да корып куела. Аларның саны хәзергәчә төгәл билгеләнмәгән. Алтынчы Республика тарафыннан рәсми тикшеренү буенча, нибары 207 кеше һәлак булган диелә. Каты яраланганнар һәм «башка төр югалтулар»ны исәпкә алып, 987 кешене дә исәплиләр. Британия компаниясенең ВВС өчен отчётында бу саннар нык киметелгән, диелә. Ирекле тикшерүчеләр якынча гына да 2000 һәм аннан да ары кеше үтерелде дигән карашта тора.

Сюжет буенча, студентлар фетнәсе вакытында Тонхо исемле малай һәлак була. Аның белән бәйле кешеләрнең истәлекләре аша Хан Ган безгә тулы бер эпоха сурәтен йомарлап бирә, аның һаман да сыкрап торган чи яра булуын күрсәтә. «Человеческие поступки» бик коры һәм кискен язылган әсәр, әмма ул тәүбә итү форматына якын. Автор бик күп архив материалларына нигезләнә, аларда сакланып, теркәлеп калган вәхшилекне һәм кешеләрнең кешеләргә карата кылган ерткычлыкларын детальләп, тайчанмыйча сурәтли.

Тәрҗемәче Ли Сан Юн китапның рус телендәге атамасына бәйле болай ди: «Мин ахыргача «И он приходит» варианты өчен көрәштем, әмма нәшрият үзенчә хәл итте». Әлбәттә, сату өчен нәшрият сайлаган исем кулайрак булырга мөмкин, әмма автор белән тәрҗемәче вариантлары, миңа калса, үтемлерәк. Хан Ган әсәрендә мистик, символик кинаяләр дә бар, алар кеше кансызлыгының бокра буйлап баруын, бүген бер урында, иртәгә икенче урында кабатлануын ассызыклый.

«Вегетарианка» «Ясная Поляна»ның озын исемлегендә дә булды. Быелгы премия лауреатлары арасында Корея язучысы Ким Чухе бар. Мәскәүгә килеп, премиясен генә алып калмады ул, ә Зур театрның Бетховен залында, иң беренче эш итеп, ватандашын Нобель премиясен алуы белән тәбрикләде. Балачак кумирлары, тәрбиячеләре арасында һәрчак кешелек кыйммәтләрен яклап чыккан Достоевский, Булгаков, Гоголь, Чехов, Толстой, Ахматова торуын әйтте.

Бәлки, әдәбият, чыннан да, җир каннуннарыннан югарырак маршрутлар буенча хәрәкәтен дәвам итәр дә «кеше гамәлләрен» төзәтә, үзгәртә алыр, диярг генә кала.

– Кванджу фетнәсе дөрләп киткәндә миңа 9 яшь иде. Без аңа кадәр 4 ай алдан Сеулга күчеп урнаштык. Озак еллар дәвамында гаиләдә кычкырып әйтелмәгән газаплы гаеп тойгысы яшәде, әйтерсең, үзебез дә сизмичә, уйламыйча, махсус рәвештә бу хәвефтән качып киткәнбез. Без үскәндә чын дөреслекне беркем дә ахыргача белми иде. Балачактан минем тире астына курку кереп урнашты: кеше бит ерткычтан да яманрак икән, ә мин – шулай ук кеше.

Материаллар туплаганда, коточкыч нәрсәләр белән очраштым. Чәчләрем үрә торып, тарихи-массачыл үтерешләр турында күпләп укырга керештем: Освенцим, Босния, Камбоджа, Нанкин... Бу аздан гына минем кешелеккә булган фундаменталь ышанычымны какшатмый калды.

Сорауларга җавап таба алмыйча, озак тилмердем. Ә аннары, ул фетнә эчендә калган кешеләрнең коточкыч вакыйгалар уртасында кешелеген һәм иманын сакларга тырышканын абайлап алдым. Нәрсә хакына көрәшкәнен ваемладым. Шуннан соң гына, кулга каләм алып, әнә шул кешедәге кеше һәм иман хакына язарга кирәк, дип, көч таптым.

Хан Ган белән әңгәмәдән

БУЛДЫРУ СӘЛӘТЕ

Илсур Һадиуллинга һәм Татарстанның ул җитәкләгән фән һәм мәгариф министрлыгына йөкләнгән күпсанлы глобаль мәсьәләләр арасында икътисадның төрле тармакларын үстерү өчен белгечләр әзерләү мәсьәләсе аерым урынны алып тора дисәм, ялгышмам, мөгаен. Әлеге мәсьәләне хәл иткәндә Илсур Гәрәевич һәм аның командасына хас булган эзлеклелек һәм системалылык – профессиональлек, стратегик фикер йөртү һәм җитәкченең алга карап эш итүенә иң яхшы дәлил.

Эдвард Абдуллаҗанов,
КДЭУ ректоры,
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты

Нәтиҗәлелеге күзгә күренеп торган конкрет проектлар арасында – заманча җиһазлар белән корылган 43 ресурслы үзәк, республикада югары уку йортлары базасында булдырылган профильле класслар, белгечләрне мәктәп эскәмиясеннән үк әзерләү өчен, педагог коллективларының предприятиеләр белән хезмәттәшлеге, яшь буын арасында һөнәри юнәлеш буенча алып барылган эш... һәм, әлбәттә инде, Татарстан шәһәрләрендә һәм районнарында инженер класслары ачу кебек колачлы һәм киләчәге булган проект.

Бер әңгәмәсендә Илсур Гәрәевич болай дигән иде: «Кешеләр аңлый башлады: үсә торган икътисад өчен инженерлык фәннәре, яшьләрнең инженер белгечлекләренә укырга керүе бик мөһим. Илгә икътисадчылар, юристлар һәм программистлар гына түгел, инженерлар да кирәк». Министр һәм аның командасының бурычларны билгеләп кенә калмавы, ә аны хәл итүнең күппланлы программасын да тормышка ашыруы бик күңелле. Менә шуның өчен дә без чын күңелебездән Илсур Һадиуллинны безне алга әйди торган министрлыкның җитәкчесе итеп кенә түгел, ә эшлекле партнёрыбыз һәм коллегабыз дип тә саныйбыз. Без аның белән уртак эш башкарабыз – илебезнең икътисады өчен квалификацияле кадрлар әзерлибез.

– Хөрмәтле Илсур Гәрәевич!

Сез, һич арттырусыз, үзендә югары профессиональлек һәм таләпчәнлек белән бергә, игътибарлылык һәм кешеләрнең тоткан вазыйфасына, статусына карамастан, аларга чып-чын җылы мөнәсәбәт күрсәтү сыйфатларына ия булган сирәк җитәкчеләр категориясенә керәсез. Бар белемегезне һәм сәләтегезне туган Татарстаныбызга багышлыйсыз. Татарстанда үсеп килгән яңа буын үзләренә кадәргеләр башлаган эшне намуслы дәвам итсен, икътисадта, социаль өлкәдә һәм мәдәнияттә яңа үрләр яуласын өчен, мөмкин булганның барысын да эшлисез.

Казан дәүләт энергетика университеты коллективы исеменнән Сезне чын йөрәктән юбилеегыз белән тәбриклим! Барлык планнарыгыз да чынга ашсын, ә Сез туплаган зур тәҗрибә белән белем республикабызга хезмәт итсен. Сезгә саулык-сәламәтлек һәм күп елларга сузылган иҗади гомер телим!

Фото КДЭУ архивыннан алынды, Алсу Шакирова

МИНЕРАЛЬ СУ ҺӘМ СИХӘТЛЕ ЛӘМ

«Васильевский» шифаханәсе – Татарстандагы иң атаклы сихәтләнү урыннарының берсе. Дәвалый торган ләм, минераль су һәм табигатьнең гаҗәеп энергетикасы – татарстанлылар өчен болар барысы да күп еллар дәвамында, әйтерсең, үзенә тартып тора торган магнит. «Васильевский» күпсанлы бүләкләргә лаек, ул аларны әле дә алып тора.

Мисал өчен, июнь аенда шифаханә «Здравница – 2024» XXIII Бөтенроссия форумында берьюлы өч номинациядә җиңү яулады. Шуннан соң, озак та үтми, «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары белән хезмәтләре» бәйгесендә «Халык өчен хезмәт күрсәтү» номинациясендә җиңде, «Россиянең 100 иң яхшы товары» бәйгесенең федераль этабына чыкты. Сентябрь аенда «Васильевский» ел саен уза торган «Сәламәт илне үстерүгә инвестицияләр. Саннар. Фактлар. Мөмкинлекләр – 2024» форумы кысаларында «Клиентларга йөз тоту буенча 5 иң яхшы шифаханә» Бөтенроссия бәйгесендә лидерлар бишлегенә керде. Санаторий «Иң яхшы медицина бүлеге» номинациясендә җиңү яулады.

«Васильевский» – заман таләпләренә җавап бирә торган шифаханә. Биредә бар да бер максатка хезмәт итә – олылар белән балаларны савыктыру, аларга тулы канлы ял итү мөмкинлеге бирү. Шифаханәнең төп юнәлеше – гаилә белән сәламәтләнү һәм ял итү.

Глэмпинглар югары ихтыяҗга ия. Күл буенда урнашкан уңайлы һәм зәвыклы әлеге йортларда йокы бүлмәсе, ял бүлмәсе, юыну бүлмәсе, бәләкәй генә аш бүлмәсе, терраса бар, табигатьтә ял итәр өчен бөтенесе дә каралган.

Кунакларның теләгенә бәйле рәвештә, дүрт торак комплексының берсен сайларга мөмкин. Номерлар категориясе – люкстан алып стандартка кадәр, әмма аларның һәммәсе дә бик уңайлы.

29 декабрьдән 2 гыйнварга кадәр «Васильевский» үзендә Яңа ел каршыларга чакыра (0+). Кунакларны шеф-пешекчедән бәйрәм табыны, ә алып баручы тылсымчыдан Яңа ел

Фотолар «Васильевский» шифаханәсеннән алынды. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



программасы белән сюрпризлар, табигатьтә спорт чаралары, концертлар, биюләр көтә.

«Васильевский» күппрофильле шифаханәләр рәтенә керә. Биредә йөрәк-кан тамырлары, нерв системасы, гастроэнтерология, пульмонология һ.б. юнәлешләрдә дәвалау каралган. Шифаханә территориясендә бальнопроцедуралар һәм эчәр өчен минераль су да чыгарыла.

2007 елда ачылган минераль су чыганагы сульфатлы-хлоридлы-натрийлы төргә карый, ул ортобор кислотасына бай һәм бик күп төрле авыруларны дәваларга ярдәм итә.

Кунакларга минераль, ылыс-энҗеле, ылыслы, кәстәнәле, радонлы, күкертле, скипидарлы ванналар тәкъдим ителә, шулай ук – пантлар (Алтай маралларының мөгезеннән алынган экстратлар) белән процедура да. Исемлектә бик күп төрле душлар да каралган, шул исәптән – су асты душы да.

Массаж – канның микроциркуляциясен яхшырту һәм тукымалардагы лимфодренажны тәртипкә китерү ысулы. Күп кенә очракларда ул савыктыруның гаҗәеп нәтиҗәләрен бирә. Биредә аның җаның теләгән сайларга була: тайныкы да, аюрведа юнәлешенә караганы да, целлюлитка каршы булганы да, лифмаларны дренажлый торганы да, абдоминаль, роллинг-массаж һәм экспресс-массаж дигәннәре дә.

«Васильевский»ның тагын бер атаклы дәвалау юнәлеше – O2ONE барокамераларындагы гипербарийлы оксигенотерапия ысулы. Кислородлы камера гипоксия белән көрәшергә булыша, күпсанлы патология һәм хроник авыруларны җиңәргә ярдәм итә. Физик форманы яхшы тотар өчен, юкка гына углекислоталы ванналарны спортчыларга билгеләмиләр.

Процедуралардан тыш, кунаклар буш вакытларында саунага, бассейнга бара ала, теннис уйнарга мөмкин. Тренажер залы бар – анда йөрергә атлыгып торучылар да шактый. Гүзәл затларга «Васильевский» косметология буенча бик яхшы процедуралар тәкъдим итә ала. Ә кичләрен кунакларны шифаханә территориясендәге уңайлы һәм тәмле кафе көтә.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

КИРОВ АВЫЛЫ: ХӨРМӘТ ЯШӘГӘН ҖИРДӘ...

КИРОВ



Фото: Александр Ефремов

Көзге юл буйлап машинабыз Актанышка таба оча. Инде агачлар төсле күлмәген кигән. Октябрь башы шул, шагыйрь әйтмешли, «күп калмады инде кышка да».

Озак барылды. Әле ярый кышкы юл түгел, дип сөйләшәбез… Биш сәгать дигәндә Киров авылына барып җиттек. Шаккаттык: авыл урман уртасында утыра. Кешеләрнең арт бакчасына терәлеп имән агачлары үсә. Җиләк, гөмбә җыю өчен өеңнән биш-ун метр читкә китү дә җитә. Мондый авылны беренче очратуыбыз!

Руфия Фазылова

РЕСПУБЛИКАДА БЕРЕНЧЕ!

Киров исемендәге совхоз: заманында районның иң атаклы авылы булган ул. Бистә статусы бирелгән аңа. Хәер, бүген дә кировлыларны Актаныштa яхшы беләләр, чөнки иң актив, иң бердәм халык яши биредә. Әмма инде көчле совхозның исеме дә, җисеме дә калмаган.

Авылга әле йөз яшь тә юк. Урман аланында беренче землянка казучылар – төрле сәбәпләр аркасында туган җиреннән сөрелгән берничә гаилә була. Алар акрынлап җир эшкәртеп, үз көннәрен үзләре күрә башлый. Соңрак биредә Киров исемендәге совхоз оеша. Нәтиҗәдә авыл күзгә күренеп үсә, күрше авыллардан да халык эшкә дип килә. Берьюлы алты «Фордзон» тракторы гына кайта.

Дөлфирә апа Каһирова да заманында күрше Усы авылыннан монда эшкә дип килгән, комсомол путёвкасы белән дип тә өстәргә кирәк. Килгән һәм төпләнеп тә калган. 1961 елда Шамил исемле егеткә кияүгә чыгып, үрнәк гаилә корганнар. Тормыш иптәше мәрхүм инде, алты бала тәрбияләп үстергәннәр. Дөлфирә апа егерме яшендә Ленин ордены алган кеше!

– Унбиш яшемнән дуңгызлар карадым, – диде Дөлфирә апа. – Бик тырышып эшләдем. Дуңгызларны нормадан тыш яхшы симерткән өчен

Егерме яшендә Ленин ордены алган Дәлфирә Каһирова.

гел мактыйлар иде. 1960 елның 7 мартында тантаналы рәвештә Ленин ордены тапшырдылар.

– Бик сөендегезме?

– Ничек кенә! Иң дәрәҗәле бүләк санала иде ул. 1975 елда мине 9 нчы чакырылыш Татарстан Югары Советы депутаты итеп тә сайладылар. Соңрак «Хезмәт ветераны» исемен бирделәр.

Дәлфирә апа 84 яшен тутырган, бүген ялгызы яши. Дөрес, балалары атна саен кайтып йөри. Зур чараларда катнашкан, чыгыш ясаган кеше ул. Сөйләм теле, үз-үзен тотышы буенча колхозчы димәссең.

– Укытучы буласым килгән иде, мәктәптә бик яхшы укыдым, – дип дәвам итте Дәлфирә апа. – Әмма укырга мөмкинлек булмады. Хәер, үкенмим, лаеклы тормыш юлы үттем. Совхозда эшләгән чакларны әле дә сагынып искә алам. Район, республика буенча төрле семинарларга да йөрдек. «О, Киров исемендәге совхоз», – дияләр иде безгә. Республика буенча гел беренче булдык.

– Кайсы күрсәткечләр буенча? – дим.

– Бөтен яктан да: игенчелек, терлекчелек... Хезмәт хакын өч йөз сумга кадәр алып эшләүчеләр булды. Хезмәт кешесенең бәясе бик югары иде. Авылда бер генә колхозчы да начар яшәмәде. Шуның өчен дә Киров күзгә күренеп үсте. 1979 елда 1302 кеше яши дип истә калган.

Ни кызганыч, шундый атаклы совхоз да үзгәртеп кору җилләренә каршы тора алмаган. 2000 нче елларда ул таркалган. Хәзер авылның җирләре «Әнәк» агрофирмасына карый.

МӘКТӘП: КИЛӘЧӘГЕ ӨМЕТЛЕМЕ?

Авылда бүген 851 кеше яши, 357 хуҗалык исәпләнә. Социаль объектлардан барысы да бар: мәдәният йорты, ФАП, кибетләр, ә иң мөһиме – урта мәктәп эшли. Яңа уку елына 82 укучы белән кергәннәр. Әле ике ел элек кенә укучылар саны 102 булган. Мәктәпнең хәзерге өч катлы бинасы 1984 елда салынган, 360 урынга исәпләнгән ул. 2016 елда белем йортына капиталь төзекләндерү уздырылган.

– Алдагы елларда бала саны бик кимемәскә тиеш, – диде мәктәп директоры Даниал Гарипов. – 2027 елга 72 бала күренеп тора. Унберенче сыйныфны быел өч кыз тәмамлый, унынчы сыйныфта исә дүрт укучы – бер егет, өч кыз килде. Имтиханнарны ел саен уңышлы гына тапшыралар. Математика, рус теле буенча уңышлар аеруча зур, БДИ нәтиҗәләре район күрсәткечләреннән алдарак та була.

Киров урта мәктәбендә укыту татарча бара. Дөрес, югары сыйныфларда төп фәннәрне русча да өйрәнә башлыйлар. Әлеге дә баягы, имти–

Химия, биология дәресләрен укучылар аеруча ярата.

Мәктәпнең хәзерге өч катлы бинасы 1984 елда салынган.

хан бирәсе бар бит. Имтихан дигәннән, химия, биология, рус теле, математика укытучылары белән аралашып алдык: БДИны укучылар өчен уңай дип саныйлар. Чыгарылыш сыйныф укучылары белән дәрестән соң да шөгыльләнәләр икән.

– Өйгә кайтып ял итәләр дә, кичке якка тагын мәктәпкә киләләр – имтиханнарга әзерләнәбез, – диде Киров урта мәктәбенең математика укытучысы Рузилә Имамова.

– Репетитор кебекме? – дим.

– Юк инде, авыл җирендә нинди репетитор. Безнең өчен иң мөһиме – баланың имтиханны югары баллга бирүе. Алар өчен борчылып, үзебезне җаваплы хис итәбез. Унынчы сыйныфка максатчан рәвештә югары уку йортына барырга теләүчеләр килә. Инде алар бюджет урынына да эләксә, тырышлык бушка китмәгән дигән сүз.

– Бюджет урыннарына керәләрме соң? – дим.

– Керәләр. Медицина университетында түләүсез укучыларыбыз бар. Казан дәүләт аграр университетында укучылар да шактый.

Эш шунда ки, Киров урта мәктәбендә 2021 елдан бирле агрокласслар ачылган. Белем йорты белән КДАУ арасында килешү төзелгән. Җиденче класстан башлап, укучылар онлайн платформа аша дәресләр укый. Казан дәүләт аграр университеты укытучылары килеп практик дәресләр үткәрә. Шушы югары уку йорты оештырган бәйгеләрдә катнашалар, төрле тәҗрибәләр үткәрәләр.

– Укучылар өчен бер дигән мөмкинлек бу, – диде мәктәп директоры Даниал Гарипов. – Беренчедән, балалар белемнәрен арттыра, икенчедән, бу түләүсез югары белем алу мөмкинлеге бирә.

Киров мәктәбенең авыл хуҗалыгы тармагы белән кызыксынганы күренеп тора: белем йортының бакчасы ялт иткән. Анда нинди генә культуралар үсми.

ДУСЛЫКНЫҢ МИЛЛӘТЕ ЮК

Инде әйткәнемчә, Киров совхозына читтән килеп урнашучылар күп булган. Шуның өчен дә ул күпмилләтле авыл саналган. Бүген исә нигездә татар авылы булып калган. Дөрес, мари, рус, әрмән, үзбәк милләтеннән булган гаиләләр әле дә бар.

Мария түти Алимбаева милләте буенча мари. Тик инде гомер буе татар авылында яшәп, туган телен оныта да башлаган. Алай да безгә ана телендә берничә җөмлә әйтеп күрсәтте.

– Марича берәр җыр җырлап бирмисезме? – дидем.

– Кызым, татарча җыр беләм, ә менә марича юк, – диде.

Мария түти Актаныш районының Терпеле авылында туып-үскән. 1960 нчы елны Кировка күченеп килгән – Миңнегол исемле мари егетенә кияүгә чыккан. Мәрхүм җәмәгате белән биш бала үстергәннәр.

– Гомерем буе совхозда эшләдем – дуңгыз карадым, – диде әбекәй. – Кул хезмәте күп иде, менә шул бик истә калган. Ә Кировның чәчәк атуын үз күзләрем белән күрдем. Мин килен булып килгәндә, авылда башлангыч мәктәп кенә иде, аннан җиде сыйныфлы иттеләр. Соңрак инде урта мәктәп булды. Тату яшәдек. Син мари, син рус, дип, аралап берәү дә әйтмәде. Инде мин үзем дә татарга әйләндем: ислам динен кабул иттем. Догалар укыйм. Аллаһ каршына барасы була бит...

Рус милләтеннән булган Валентина Егорованың да татарчасы бер дигән. Без кергәндә ул сәйләннән гарәп язулы картина ясап утыра иде. Бик яраткан шөгыле икән.

– Кияүнең туган көне җитә, аңа дип эшлим, – диде көр тавыш белән әбекәй.

– Киявегез мөселманмы? – дим.

– Әйе, улым, кызым да, оныклар да ислам динендә.

– Ә үзегез кайсы диндә? – дим.

– Аллаһ бер инде ул. Догалар укымыйм, татарча Аллаһтан саулык, ил-көннәргә тынычлык сорыйм. Кылган изгелекләрем җәннәтле итәр әле. Бер кешегә дә начарлык эшләгәнем юк.

– Кировның чәчәк атуын үз күзләрем белән күрдем, – ди Мария Алимбаева.

Рус милләтеннән булган Валентина Егорованың да татарчасы бик яхшы.

– Татарчагыз камил икән? – дим.

– Соң, без бит татар мәктәбен тәмамладык. Кировта барлык милләт балалары да татарча укыды.

– Ничек алай ул?

– Укытучылар татар иде, шуның өчендер дип уйлыйм.

Валентина түтинең гаиләсе Кировка 1942 елны күченгән. Ул бала вакытын яхшы хәтерли. Төрле милләт вәкилләре бездә бик дус яшәде, ди.

– Без үскәндә авылда землянкалар күп иде, – дип дәвам итте Валентина түти. – Сугыштан соң да землянкаларда яшәүче гаиләләр күп булды. Дөрес, аның инде стенасы агачтан иде. Җир астын казып шулай эшләделәр. Ә түбәсе чыбык-чабыктан була. Түбәдән бер бәләкәй генә тишек – морҗа чыгып тора. Ә идәне юк, ягъни җир. Хәтта мунчаларны да шулай җир астын казып ясыйлар иде.

Валентина түтигә 84 яшь. Кызы белән кияве яңа йорт салып биргән. Атна саен кайтып йөриләр икән. Тагын ике улы бар. Берсе гаиләсе белән Кировта яши, икенчесе махсус хәрби операция зонасында. Әни кеше көн саен Аллаһтан аның саулыгын сорый...

– Гомер буе совхозда эшләдем, – ди әбекәй. – Сыер да саудым, ат та җиктем, аннан бригадир булдым. Кырык ел эшләдем. Тик минә зарым бар, сезгә әйтим әле: безне хәзер бер күрүче кеше юк. Совхоз таркалганнан соң, әйтерсең, без эшләмәгән дә. Ник елга бер килеп хәлне белсеннәр. Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне була, шунда бер уч конфет белән чәй кыстырып: «Валя түти, хәлең әйбәтме?» – дисәләр була бит. Олы кешенең күңеле булыр иде.

Гомер буе совхозда эшләгән татар апасы белән дә таныштык – Вәсилә Әмирова. Тиздән үзенә 88 яшь тула икән. Шулай ук ялгызы яши. Әбекәйнең йортына аяк баскач та чигүле мендәр, япкычларга күз төште. Иң гаҗәбе – әле дә чигә, бәйли.

– Бүген генә бер башмак бәйләп аттым, – дип елмайды Вәсилә апа. – Күзлек кигәч була, җеп тә саплыйм. Элек әле тегә дә идем. Соңгы елларда машинага утырганым юк. Ә менә чигү белән бәйләүне ташламыйм, ул миңа рәхәтлек бирә. Сәламәтлегемнән зарланмыйм, колак кына начар ишетә. Безнең әнкәй 101 яшенә җитте. Соңгы көннәренә кадәр аягында йөрде. Аллаһ боерса, мин дә әни яшенә җитәм әле!

Вәсилә апа Кировка шулай ук әти-әнисе белән күченеп килгән. Ул вакытта сигез яшендә булган. Әтисе сугыштан исән-имин әйләнеп кайткач та, яхшы тормыш эзләп, Кировка чыгып киткән. Дүрт класс тәмамлагач, Вәсилә апа инде совхозда эшли башлаган. Башта бәрәңге, чөгендер үстерү кебек эшләрдә йөргән, ә унбиш яшеннән фермага сыер саварга кергән. Аннан кияүгә чыккан, балалар тапкан. Тик җәмәгате генә иртә вафат булган.

– Бу өйне, ирем үлгәч, 1975 елда салдым, – диде Вәсилә апа. – Янымда биш бала, аларны аякка бастырырга кирәк бит. Әткәйләр дә булышты, рәхмәт. Үзем дә тырыш булдым, кызым. Малын да асрадык, эшкә дә бардык. Аллаһка шөкер, балаларым да үзем кебек уңган.

Вәсилә апа белән Мария түти күршеләр. Көн дә бер-берсенең хәлен белешәләр, ризык пешерсәләр дә уртак икән.

– Вәсиләнең уты булмаса да кереп җитәм, – диде Мария түти. – Гомер буе фермада бергә эшләдек. Хәзер дә туганнар кебек яшибез.

Гомере буе совхозда эшләгән татар апасы белән дә таныштык – Вәсилә Әмирова.

«ТӘРБИЯГӘ БАЛА АЛАМ ДИП ХЫЯЛЛАНДЫМ»

Кировта яшәүче Сабитовлар гаиләсен якын-тирәдә белмәүче юк. Өч балалары үсеп беткәч, тәрбиягә ун бала алган Алмас абый белән Венера апаны мин дә шактыйдан беләм. Социаль челтәрләр аша аларның актив тормышларын күреп сокланам.

Тәрбиягә бала алу Венера апаның хыялы була. Башта ул бу хакта җәмәгатенә әйтергә дә базмый. Сүз иярә сүз киткәч, гаилә башлыгының да балаларга каршы булмавы ачыклана.

– Яшьтән хыялый идем, – диде Венера апа. – Кечкенәдән күп балалы әни буласым килде. Алай гына да түгел, ул балаларны тәрбиягә алам дип хыялландым. Үзем дә үсмер чактан әнисез калган, әтисез үскән бала... Сөт җыючы булып эшләгәндә Куҗәкә авылында бер гаилә белән таныштым: тәрбиягә балалар алган иде алар. Менә аларга карагач, янә теге күңелдәге хыял тынгылык бирми башлады. Аллаһның рәхмәте, бала алырга иремне күндердем. Үзебезнең фамилияне бирәбез дип сөйләштек. Яшел Үзән районының Норлат балалар йортында яшәүче

бертуганнар – Руслан белән Алинә турында ишеттек. Документлар тутырдык. Әле аннан соң да алты ай көттек. Шул вакыт эчендә күңелем гел алар белән булды. Беренче очрашу гел истә: балалар йортына килгәч тә, сабыйларга уенчыклар, тәм-том тараттым. Ә берничә бала безгә ияреп директор бүлмәсенә керде. Ул да түгел, берсе алдыма ук менеп утырды.

– Русланмы әллә бу? – дип сорадым. Директор баш какты.

Русланга инде 20 яшь, КФУ да укый.

– Безнең горурлыгыбыз, – ди аның турында Венера апа. – Чиста, пөхтә, мәктәптә яхшы укыды. Ачуланганда да «эх» дип тә әйткәне булмады. Сеңлесе Алинәгә генә түгел, бүтән балаларыбызга да үрнәк абый ул. Руслан белән Алинәдән соң Лилия белән Лианабыз кайтты. Лилия ун айлык, ә Лианага унөч яшь иде. Әнә шулай итеп балаларыбыз унга җитте. Бүген инде ике кызыбыз Актаныш көллиятендә укый – пешекче булачаклар. Калганнары – яныбызда, Киров урта мәктәбендә укыйлар.

Балаларның һәркайсы белән аралашып алдык – бик ачыклар, рәхәтләнеп сөйләшәләр. Һәм барысы да матурлар!

– Бу балаларны әллә сайлап алдыгызмы? – дидек.

– Юк, әлбәттә. Аллаһы Тәгалә аларны үзе безгә сайлап бирде, – дип елмайды Алмас абый. Һәм балаларына назлап карады. Балалар да эти дип кенә тора.

Шуны әйтми кала алмыйм: Венера апа авылда төрле бәйрәмнәр оештыручы кеше дә. Август аенда бик зурлап «Авыл көне»н үткәргәннәр. Сентябрьдә исә «Көзге ярминкә» узган. Фото, видеоларны күреп ис китте: район масштабындагы чаралар булган. Күрше Башкортстаннан да кунаклар килгән!

...Бу авыл бик озак хәтердә сакланыр, ахрысы. Аеруча сөйкемле апалары истә калды. Шулкадәр күп, ихлас теләкләрне әле ишеткәнебез юк иде. Югыйсә төрле җирләрдән җыелган халык: ничек шулай барысы да кече күңелле, ачык йөзле булды икән? Әллә суы шундый булган, әллә урман һавасы шундый иткән...

Кировта яшәүче Сабитовлар гаиләсен якын-тирәдә бөтен кеше белә.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– 1931 елның ноябрендә Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы карары белән Яңа Әлем авылы янында «201 номерлы Актаныш итчелек-сөтчелек совхозы» оеша. Берничә айдан, ул Иске Сәфәр авылына күчерелә. Бу чорда «Сәфәр» совхозы дип йөртелә. Тагын берничә айдан совхоз хәзерге Киров авылы урынына китерелә. Ул вакытта монда төрле җирләрдән сөрелгән берничә гаилә яшәгән. Совхоз тиз арада үсеп, эшчеләр өчен бараклар салынган. 1935 елда совхозга революционер, хөкүмәт эшлеклесе Сергей Миронович Киров исеме бирелә. Тик шуннан соң да ул шактый вакыт халык телендә «Сәфәр» совхозы дип йөртелә. Тора-бара совхоз исемен төшереп калдырып, авылны «Киров» дип кенә йөртә башлыйлар.

Венера Сабитова, авыл активисты

ТАТАР ЭПОСЫ ДӨНЬЯ ГИЗӘ

ТУГАН БАТЫР СӘХНӘЛӘРНЕ, ЭКРАННАРНЫ ҺӘМ ЙӨРӘКЛӘРНЕ НИЧЕК ЯУЛАП АЛА

Татарстанда оешкан команда искиткеч нәтиҗәләргә ирешә: алар яңа әдәби герой һәм аның галәмен булдырып кына калмыйча, тылсымлы тарихын чынбарлыкка да әйләндерде. Өч елдан да кимрәк вакыт эчендә «Туган батыр» китабыннан башланган эш халыкара дәрәҗәдәге күпкырлы проектка әверелде.

– Безнең төп идеябез балаларыбызга үрнәк булырлык, балалар аңа охшарга теләрлек яңа әкияти милли герой булдыру иде. Авторы халык язучысы Зөлфәт Хәким булган «Туган батыр» китапларына без милли мәдәниятебезнең төп кыйммәтләрен һәм мотивларын керттек, – дип билгеләп үтте «Туган батыр» проектының авторы һәм аны уйлап табучы, «Туган Авылым» милли комплексын гамәлгә куючы эшмәкәр, хәйрияче **Радик Абдрахманов**. – Без шунда ук өч нәрсәне аңлап алдык. Беренчесе: балалар аудиториясенә якын булыр өчен, алар игътибары юнәлгән урынга – кино һәм телеэкраннарга, гаджетларга, виртуаль чынбарлыкка юл тотарга кирәк. Икенчесе: «Туган батыр» әләме астында без балалар һәм өлкәннәр аудиториясе өчен татар мәдәниятен үстерүгә юнәлтелгән чаралар уздыра алабыз. Өченчесе: безнең проект белем-мәгърифәт тарату гына түгел, берләштерү вазыйфасын дә үти ала, чөнки ул төрки дөньяның һәр вәкиле өчен мөһим кыйммәтләргә игътибар юнәлтә һәм аларга карата кызыксыну уята.

МОҢАРЧЫ ТИҢЕ БУЛМАГАН ТАМАША

Спорт һәм хәйриячелек кебек милли традицияләргә хөрмәт йөзеннән, «Туган батыр»ны дөньяга чыгаручылар Алабугада колачлы этнофестиваль – меңнәрчә тамашачыны һәм йөзләгән катнашучыны җыя торган, тарихи реконструкция элементлары булган Бөтенроссия ук ату турнирын оештыралар һәм даими рәвештә уздырып торалар, шулай ук спорт көрәше буенча республика турниры һәм «Балачак» халыкара җыр конкурсы да үткәрәләр. Киләсе елда китап геройларын яратып өлгергән татарстанлыларны күңелле яңалык көтә: режиссёр Айдар Җәббаров Казанның Г. Камал театры сәхнәсендә «Туган батыр» интерактив гаилә тамашасын куячак.

– «Туган батыр» командасы һәм аларның эше белән танышкач, мин шаккаттым. Мондый төрле төсмерләргә бай, мавыктыргыч, эчтәлекле сюжетның бездә булганы юк иде. Без инде кастинг уздырдык һәм хәзер театрыбызның яңа бинасына бик ярашлы булачак спектакль әзерлибез, – ди Айдар Җәббаров.

Фотолар «Туган батыр» проекты матбугат хезмәтеннән алынды. 6+. РЕКЛАМА

РӘСЕМНӘР ҖАНЛАНА

«Туган батыр» әкияти бәяннан аудитория өчен генә түгел, инвесторлар өчен дә кызыклы динамик проектка әверелә. Аларның матди кертемнәре һәм Татарстанның грант ярдәме белән проект авторлары анимацион сериал ясау эшен башлап җибәрә. Сериалны илебезнең алдынгы студиясе ясый. Бу студиядә күпләрнең күңелен яулаган «Фиксиклар», «Смешариклар» һәм башка персонажлар дөньяга чыккан. 52 сериядән торган беренче сезонның премьерасы бик тиздән булачак. Стриминг сервисларына сериал рус һәм татар телләрендә чыгачак. Мультфильмның тизеры ВЭФ, KazanForum («Казанфорум»), ПМЭФ, «Россия – Африка», Kazan Digital Week («Казанда саннар атналыгы»), «РОСТКИ» форумнары, Дубайда узган кино күргәзмәсе кебек дәрәҗәле урыннарда тәкъдим ителгән инде.

СӘЯХӘТ ДӘВАМ ИТӘ

«Туган батыр белән Гөлчәчәк кайчан өйләнешәчәк соң?» – дип сорау бирә проект авторларына Туган батыр һәм аның дусларының маҗаралары турындагы китапларны бик яраткан бер кыз басманың яңа, өченче өлешен тәкъдим итү кичәсендә. Тамашачылар тып-тын кала: китапның романтик линиясе алга таба ничек дәвам итәчәге һәркемгә кызык. Һәм Татарстанда гына түгел! Әсәр инглиз, төрек, гарәп, кытай телләренә тәрҗемә ителгән. Проектны тәкъдим итү бәйрәме һәм шулай ук «Туган батыр» Сабан туе да Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә һәм Төркиядә узган инде. Повестьның өченче өлешендә вакыйгалар Төркиядә бара, ноябрь аенда бу китап та Истанбулда тәкъдим ителәчәк.

Әмма дөнья буйлап сәяхәт иткәндә, проект төрки телле илләр белән генә чикләнми.

– Бүген «Туган батыр» – халыкара бренд ул, аның миссиясе – татар халкының мәдәни һәм рухи кыйммәтләрен саклау һәм үстерү. Без күп кенә перспектив идеяләрне чынга ашыру юнәлешендә эшлибез, – ди Радик Абдрахманов. – Безнең проект БРИКС илләрен Татарстан белән тоташтырып тора торган буын булыр дип өметләнәбез һәм бу бәйләнешне ныгытырга тырышачакбыз.

Ерлан Искаков, Казахстанның Казандагы Генераль консулы:

– Бик шәп, кызыклы проект! Өченче китапта вакыйгалар Төркиядә бара. Башка юлы геройлар Казахстанга юнәлсә, тагын да мавыктыргычрак булыр. Чит илләрдәге татар диаспоралары арасында сан ягыннан Казахстанныкылар икенче урында тора. Бездә «Күчмә халык уеннары» кебек күп кенә уникаль милли традицияләр сакланып калган. Аларны да Туган батыр турындагы китап битләренә кертергә була!

Зөлфәт Хәким, халык язучысы, «Туган батыр» маҗаралары турында китапларның авторы:

– Мин үсеп килгән буынның рухи һәм әхлакый сафлык, кыюлык, җаваплылык, үз халкының мәдәниятен һәм телен ярату кебек чын кыйммәтләргә тартылу мөмкинлеген саклап калу өчен барысын да эшләргә телим. Һәм «Туган батыр» – бу эштә минем төп ярдәмчем.

Угур Йылмаз, Төркиянең Казандагы Генераль консулы:

– Китапны тәкъдим итү уңаеннан Казанда үткәрелгән чарада катнашуыма бик сөендем һәм бу вакыйганың Истанбулда узачагын түземсезлек белән көтәм. Әлеге проект мәдәниятебез өчен бик мөһим.

Реклама. ИП Мустаева О.Н. ОГРНИП 311168919600013